Безнең Мирас

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

12
декабрь 2017
ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ДИЛӘРӘ НӘҮРУЗОВА. «БӘК КЫЗЫ»

VIII ГАБДЕЛХАК САМАТОВ УКУЛАРЫ

16 ноябрьдә Казанның Россия ислам институтында VIII Габделхак Саматов укулары үтте. Әлеге чара кысаларында дини-милли эшчәнлек алып барулары белән аерылып торган шәхесләргә Г.Саматов исемендәге «Рухи мирас» премиясе тапшырылып килә. Быел бу премиягә Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районы хакимияте башлыгы Эдуард Әнвәр улы Ганиев лаек булды.

Фотолар islam-today.ru һәм tatar-inform.ru сайтларыннан алынды

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең Мирас

12 +

12 (288)

декабрь 2017

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

104

18 БИБӘҺА ХӘЗИНӘ

67 ӘБИЛӘР ЧУАГЫ. *Хәйдәр*

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Миргазиян Юныс

ТАРИХИ МИРАС

4 «Гыйлем Хакка илтер». *Р.Мәрданов*
9 «Дошман атка атланганыңны көтми...» *Л.Мөхәммәтҗанова*
11 Чура батыр. *Р.Баязит*
14 «Бу эшебез нигез ташы булсын...» *Р.Шәрәфәиева*
18 Бибәһа хәзинә
22 Исемең һәм җисемең. *Ә.Сибгатуллина*
27 Җанлы байлык. *Э.Шәрифуллина*
30 Фазыл Туйкә туплаган җырлар
31 Керәшен татарларының туй йолалары. *Г.Золина*

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

36 Тел мәсьәләсе. *Г.Тирешкави*

ТАТАР ГАМЕ

40 «Шыгырдан төене»н чишкәндә. *Ф.Кутлу*
44 Ерактагы якын милләттәш. *С.Гарифуллина*
48 Егет күрке дан белән... *А.Әхмәтгалиева*

ДИНИ МИРАС

52 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
58 2018 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр

ӘДӘБИ МИРАС

60 Галимнең атыннан чәчрәгән пычрак
61 Тормыш. Иҗат. Хәтер. *Э.Нигъмәтуллин*
67 Әбиләр чуагы. *Хәйдәр*
73 Тохар оныгы. *Л.Лерон*

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

77 Милләтнең олуг галимәсе (Р.Ганиева). *Л.Лерон*

СУГЫШ КАЙТАВАЗЫ

82 Безнең иң үткен һәм иң көчле корал. *Ә.Шамова*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Ленар Гобәйдуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР мәгариф һәм фән министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Васил Шәйхразыев
Ирек Шәрипов
Лотфулла Шәфигуллин

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррирләре
Марат Закиров
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-92)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН

86 **С.Рахманколый, Д.Гобәйди, Ш.Фидаи, Н.Думави, Я.Кәрим**

ХӘТЕР САНДЫГЫ

89 **Почтада Яңа ел**
90 **Латәкә.** *М.Кәримов*
94 **Имтихан яки Нефтьче язмалары.** *Л.Фазлыев*

СӘНГАТИ МИРАС

110 **Скрипка татарныкымы?** *Э.Каюмова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

102 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*
104 **Борынгы татар йолалары.** *Р.Батулла*

ХӘТЕР САГЫНДА

108 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1917 елның декабрь ае.**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Декабрь*

Заказ №А-2974. Тираж – 1600 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 23.11.2017
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Бәк кызы» ***Д.Нәүрузова.***
Р.Бохараевның «Аксак Тимер күләгәсе» поэмасына иллюстрация. 2016 ел.

МИРГАЗИЯН ЮНЫС
(1927-2014)

***

Тел эчендә милләтнең җаны, аның иманы, соңгы чиктә, аның язмышы ята.

***

Японнар телне саклау буенча башка халыклар арасында беренче урында тора. Ярлыландырылган телгә яңалык кертүе кыен икән ул, японнарга исә һәр яңалык үзеннән-үзе агылып тора. Чөнки искелек исән...

***

Туган телне саклау бүгенге көндә кешелек экологиясен саклау дәрәҗәсендә тора. Тел – кеше рухының формасы, эчтәлеге һәм аның яшәү шарты. Тел – рухи экология. Туган телдә – мең еллар буена гореф-гадәтләр хәзинәсенең сөземтәсе, әдәп һәм әхлак кануннары, мең еллар туктаусыз язылып торган тарихның хакыйкый эчтәлеге.

***

Әдәби әсәр, тарихны, бүгенгене, киләчәкне бергә тоташтырып, ялган белән хакыйкать арасындагы яшеренеп торган эзне күрсәтә.

***

Талант мохиткә җайлаша алмый.

***

Үткән заман тарихын аңлау киләчәккә бару өчен кирәк. Узгандагы ялгышларны белү киләчәктә аларны кабатламас өчен мөһим. Үзең яшәгән чорны бәяләү өчен дә тарихны белү яхшы.

***

Бәхетле буласы килү тормышны катлауландыра.

***

Сүзне төрлечә әйтеп була. Бер үк сүзгә, теләсәң – шатлык, теләсәң – кайгы, кирәк чакта ихтирам яисә нәфрәт сыйдырып була. Сүз – шул үк, ә аның тәэсире тулысынча үзгә. Искиткеч нәрсә ул – сүз.

Текстны ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

«ГЫЙЛЕМ ХАККА ИЛТЕР»

*(Мөхәммәтәминнең яңа табылган әсәре турында)**

Раиф Мәрданов

Татар әдәбиятының моңарчы билгесез борынгы җәүһәрләре һаман да табылып тора. XVIII гасыр башында күчерелгән кульязмаларның берсендә кызыклы шигъри әсәргә юлыктык. Шигъри истәлекнең битләре җуелганлыктан, исеме билгесез. Ләкин әсәрнең төп мәгънәсен бирердәй һәм текстында еш кабатланган «Гыйлем Хакка илтер» дигән гыйбарә аңа шартлы исем итеп куярга яраклы.

Бу әсәр эчтәлеге, тел һәм стиль үзенчәлекләре белән Казан ханлыгы чорының әдәби истәлекләренә бик якын. Тәфсилләп тикшергәч, шигъри әсәрне 1515 елда язып төгәлләнгән «Могҗизнамә» белән «Кыйссаи Мансур» поэмасын (елы билгесез) язган автор иҗат иткәнлегендә шигебез калмады. Әлеге өч әсәрнең тел һәм стиль уртаклыгы, тематик яктан якынлыгы, бертөрле үк сүзтезмәләр һәм рифмаларның еш кулланылуы – бер үк автор иҗаты икәнлекләрен раслый. Өчесенең дә кульязма күчермәләре безнең татар җирлегендә сакланып калу факты аларның авторы татар икәнлегенә нигезле дәлил булып тора.

Әсәрнең башында ук язылган гыйлемнең мәгънәсе суфыйчылык тәгълиматында кешенең үзен-үзе белүенә бәйле. Ә үзен белгән – Аллаһны таныр, дип аңлатыла. «Гыйлем» сүзе һәм аның тамырдаш мәгънәләре Коръәннең төрле сүрәләрендә якынча 750 мәртәбә язылган булуы – Ислам динендә гыйлемнең никадәр әһәмиятле булганын раслый. Коръән һәм Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәр хәдисләрендә «гыйлем» дигәндә беренче нәүбәттә, Коръәнне һәм хәдисләрне өйрәнү, шулар буенча гамәл кылу шарт ителгән. Гыйлем төшенчәсе мөселман дини әдәбиятында тәфсир һәм шәригать фәннәре, Ислам дине тарихы кебек белемнәрне дә күздә тоткан. *«Гыйлемне Кытайга барып булса да алыгыз, чөнки гыйлем өйрәнү һәр мөселманга фарыз»*, дигән хәдис һәр иманлы бәндәгә турыдан-туры күрсәтмә рәвешендә яңгыраган.

«Гыйлем Хакка илтер» әсәрендә тасвирланган акыл иясе хәзрәти Гали (Гали ибне Талиб, 661 елда вафат) – Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең кияве, агасы Әбү Талибның улы, ислам динен кабул иткән беренче дүрт кешенең берсе. Ул, башка күркәм сыйфат-

* Әсәрнең хәзерге татар язуына күчерелмәсе белән beznenmiras.ru сайтында танышырга мөмкин.

«Гыйлем хакка илтер» әсәренең бер бите


قل ان الفضل بيد الله يؤتيه من يشاء

лары белән бергә, гыйлеме белән танылган. Тәсаувыфта Галинең аерым урыны бар, ул суфыйларның юл күрсәтүчесе һәм имамы дип саналган.

Хәзрәти Галинең *«Байлык таралса – бетә, гыйлем таралса – арта»*, мәгънәсендәге канатлы гыйбарәсе халык арасында һәм әдәбиятта хәдис дәрәҗәсендә таралыш алган. Ул Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәргә нисбәт ителгән ялган хәдисләрнең берсе буларак та мәгълүм. Татарлар арасында элек иң күп укылган борынгы хикәятләрнең берсе – «Мәликә китабы»нда да шул ук гыйбарә телгә алынган.

Әсәрдәге хәзрәти Галигә нисбәт ителгән гыйлемнең байлыктан өстенрәк булуы турындагы фикер чынлап та Гали ибне Әбү Талибныкы. Ул бер нәсыйхәтендә, гыйлемне байлык белән чагыштырып, болай дигән: *«Гыйлем байлыктан өстен. Гыйлем сине саклый, ә байлыкны үзең саклыйсың. Гыйлем гамәлләргә күрә арта, ә байлыкны таратсаң – ул кими. Гыйлем – үзе идарә итә, байлык исә кемнеңдер идарәсендә була. Байлык беткән саен үзенең йогынтысын югалта, ә кешеләр динне яратканга галимне дә яраталар. Гыйлем галимгә исән чагында итагать һәм үлеменнән соң аның турында яхшы фикер китерә. Галимнәр мәңгелеккә кала (үзләре булмаса да, алар кешеләрнең йөрәкләрендә яши), ә байлык җыючылар исән чакларында ук үле»*.

Безнең мирас №12 декабрь 2017

«МАЛ ТҮГЕП, ГЫЙЛЕМ ЮЛЫНА ОМТЫЛЫЙК»

Шигъри әсәрнең сакланган өлеше нәкъ шул мәсьәлә белән – берәүнең хәзрәти Гали янына килеп: «*Бу гыйлемме йек дорыр, йухса ки маль?*» (гыйлем өстенрәкме, әллә байлыкмы) – дигән соравыннан башлана. Тексттан аңлашылуынча, бу кеше шундый сорау белән мөрәҗәгать итүчеләрнең икенчесе. Хәзрәти Галигә ул мәсьәлә белән барлыгы җиде кеше мөрәҗәгать иткән.

Сораучыга мөэминнәр әмире Гали хәзрәт: «Дөнья малы тиң түгел Хак гыйлеменә», – дип җавап биргән. Теге исә: «*Дәлиле нәрсә, ни өчен гыйлем өстен, ә байлык хурлыклы?* – дип төпченә. – *Шуны аңлат, мал түгеп, гыйлем юлына омтылыйк*», – ди.

Ул Гали әйтде ки: «Малы һәр заман
Исси бикләр, исси улыр пасибан».

Ягъни байлыкны аң бикләп куяр һәм акыл саклар.

«Бу гыйлемдер ки, саклар иясени,
Дере тотар дин-ү һәм дөньясыни.

Бәс, гыйлем йекдер бу малдан мотләка,
Мал кире куар шәхсы, гыйлем илтәр Хакка».

Менә бу соңгы икеюллык әсәрдә хәзрәти Галинең һәр җавабы ахырында кабатланган. Димәк, **мал-байлык кешене түбәнгә – ягъни Аллаһтан ерагаюга тартса, гыйлем Аллаһы Тәгаләгә якынаюга сәбәп.**

Аннан соң өченче кеше килеп шул ук сорауны биргәч, хәзрәти Гали хикмәтле сүз белән

Әйтде: «Малы хәрҗ идичәк – әкселер,
Гыйльме хәрҗ итдекчә – артар, ачылыр».

Ягъни **байлыгын таратучы фәкыйрьләнер, ә гыйлемне тараткан саен – ул артыр, күбәер.**

Дүртенче, бишенче, алтынчы һәм җиденче кешеләр дә, гыйлемнең өстенлеге нәрсәдә булу белән кызыксынып, төпле җаваплар алган. Хәзрәти Гали бишенче кешегә биргән җавабында, гыйлемнең өстенлегенә дәлил итеп, **кеше үлгәч, аның малы башкага кала, ә гыйлемле кешенең белеме мәңгелек дөньяда да иясенә кирәк**, ди. Алтынчы кешегә Гали хәзрәт:

«...мал – бу дөнья дәүләте, ә
Гыйлем илә дөнья-у гокба алынур,
Икесендә гыйзз-ү дәүләт булынур»,

– дип җавап бирә. Ягъни **гыйлемле кеше дөньяда да, ахирәттә дә хөрмәткә лаек**. Соңгы мөрәҗәгать итүчегә дә ул:

«Җан-күңел бу гыйлем илә рәүшан улыр,
Бакдыгы йир күзенә гөлшан улыр»,

– дип җавап бирә.

Әсәрнең шул урынында, кульъязманың бер бите төшкәнлектән, текстка өзеклек кергән. Аннан соң хәзрәти Галигә мөнәсәбәтле сүзләр булмаса да, гыйлемне данлаган гыйбарәләр дәвам иткән.

«ИҢ МӨҺИМЕ – ҖАН БЕЛӘН ИШЕТҮ»

Алга таба әсәрдә лирик геройның Аллаһка юнәлүе тасвирлана. Автор кешенең әгъзалары турындагы бер китапны бәян итә. Ул китап аерым бүлек-бабларга бүленгән, имеш: беренче баб – колак, икенче баб – күз, өченче баб – борын, дүртенче баб – авыз, бишенче баб – кул, алтынчы баб аякка багышланган. Менә бу әгъзалар кешенең

тәне һәм җисеме вазыйфаларыннан бигрәк, җанга – кешенең эчке дөньясына бәйләп, Аллаһны танып белүгә турыдан-туры бер чара һәм кодрәт иясенең биргән нигъмәте буларак тасвирланган. Мәсәлән, колакның эше – ишетү (төрле гыйлем, хикмәт, сүз, көй, наз һ.б.). Һәр ишеткән нәрсәдә мәгънәләр бихисап, тик **иң мөһиме – җан белән ишетү, ә имансызлар һәм кяферләр җан колагы белән ишетүдән мәхрүм**, диелә.

«Бу китабың Күз – икенче бабыдыр,
Күрдеге җөмлә аның әсбабыдыр».

Күз бабында аның күргән нәрсәләрен җан белән кабул итәргә кирәклеге, һәр күргән нәрсәдә Аллаһның рәхмәте чагылуы, аларда бик күп мәгънәләр булуы, җанга илаһи нур күздән ирешүе әйтелә. Һәрбер әгъза турында язылганнан соң, Аллаһы Тәгаләнең кяфер-имансызларга җан белән тоемлауны насыйп итмәгәнлеге кабатланып бара.

Һәр сулыш борын аша тән һәм җанга яшәеш бирү белән бергә, җанга аң һәм илаһи изгелек тә ирешә. Авыз һәм телнең хасиятләре дә төрле җәһәттән сурәтләнгән:

«Гыйлем эчендә былбыл улыб әйтдеке,
Ул – әсәрдәндер Хакы зикер итдеке».

Кул белән эшләнгән эшнең һәрберсендә яшерен йөз мең сере бар, диелгән. Аяк бабында да яшерен мәгънәләр бик күп дип:

«Күр – бу Аякдан нәчә эшләр кубар!
Ничәләр бу аягы ятып үбәр, –

рәвешендәге хикмәтле сүзләр әйтелгән.

АЛЛАҺКА МӘХӘББӘТ

Бу урында кулъязманың тагын бер бите төшкән һәм берникадәр күләмдәге текст безгә тагын билгесез кала. Өзеклектән соң текстта суфыйчылык сәфәрендәге илаһи гашыйкның тарикать баскычларын (мәнзил, мәкам) бер-бер артлы үтеп, Аллаһы Тәгалә белән тәмам кушылуга юл тотуы тасвирланган. Ул Аллаһның үзенә гыйшык бирүен һәм илаһи әмер белән аңа омтылышын бәян итә. Бу хәлләр шагыйранә тел белән, *«бер заман җирдә яшәдем, һичкайчан җир йөзен ташламам, дигән идем, уйламаганда гыйшык алды да китте»*, дип сурәтләнгән. Инде хәзер әсәрнең лирик герое, баг-бакчалар, тау һәм далаларны онытып, дөньялыктан аерылу һәм Аллаһ белән кушылуга юл тота, «горбәт» һәм «корбәт» мәкамнәрен кичә. Аллаһы Тәгаләнең чиксез кодрәтләрен күреп ялвара, Аллаһка ирешү өчен, Аңардан үзен җитәкләвен үтенә. Аллаһ гыйшкы моны «хәйрәт»кә ыргыта. Хәйрәт – суфыйчылыкның нәүбәттәге баскычы. Бу дәрәҗәгә ирешкән суфый бик зур газаплар кичереп, фанилыктан аерыла һәм Хак Тәгалә белән кушыла.

«Восләт мөлке»ндә (ягъни Аллаһы Тәгалә белән тәмам кушылу баскычында) әсәр авторы, Аллаһның рәхмәте һәм нуры белән яктырдым, дип, аның кодрәтенә дан җырлый. Аллаһның бөеклеге, ә бәндәнең исә берни түгеллеге тасвирлангач, Коръәннең «Ихлас» сүрәсе, ярымтәрҗемә сыйфатында, әсәрнең шигъри юлларына бик уңышлы кушылган:

«Ул дорур Ул «Куль: Һу Аллаһу Әхәд»,
Һәм сыйфат һәм ады «Аллаһус-Самәд»!

Кемсә Андан тугмады, Ул – кемсәдән.
Нә сурәт вар Анда, нә җисм, нә бәдән!»

Әдәбият теориясе фәнендә әсәр текстына Коръән сүрәләрен һәм пәйгамбәр (с.г.в.) хәдисләрен катнаштыру алымы «тәлмих» дип атала. «Касас» сүрәсенең 88 нче аятендәге «Аллаһы Тәгаләдән башка һәрнәрсә һәлак була», дигән юллар да текстка үрелеп бирелгән.

Аллаһ белән кушылып бетүне автор тантаналы итеп тасвирлый:

«Күр ки, җөмлә дел Аныңдыр, сүз – Аның.
Күренән – Ул, күрән – Улдыр, күз – Аның».

Автор, Аллаһы Тәгаләнең күркәм исемнәрен һәм мактаулы сыйфатларын тезеп, гаять шагыйранә дәвам итә:

«Җөмлә әмер Ул Әмирә кәлде йәнә,
Әүвәл – Ул иде, Ахир – Ул калды йәнә.

Әүвәл – Улдыр, Ахир – Улдыр, Даим – Ул,
Заһир – Улдыр, Батыйн – Улдыр, Каим – Ул!»

Бу юллардан соң, Коръәннең «әл-Хәдид» сүрәсендәге 3 нче аяте язылган: *«Ул (Аллаһ) Беренче һәм Ахыргы, аның барлыгы – ачык, белә алмаслык дәрәҗәдәге яшерен. Ул бөтен нәрсәне белүче өстен зат».*

ТӨП МӘГЪНӘ – БЕРЛӘШҮ

«Гыйлем Хакка илтер» әсәренең төп мәгънәсе тулаем Аллаһы Тәгалә юлына бирелүне, аңа ирешү өчен тарикатьне, илаһи гыйлемнәр өйрәнүне, вакытлы (фани) дөньяга алданмаска кирәклекне аңлатудан гыйбарәт. Әсәрнең иҗат ителгән чорына (XVI гасыр башына) күрә, Аллаһы Тәгаләгә иманны ныгыту максаты белән халыкны туплау һәм ханлык-дәүләтнең рухи бердәмлеген көчәйтү күздә тотылган, дип әйтә алабыз. Шул ук авторның «Кыйссаи Мансур» әсәрендә дә төп мәгънә берләшү һәм бердәмлектән гыйбарәт. Алтын Урда чоры әдибе Ибраһим исемле шагыйрь 1382 елда иҗат иткән әсәрдә һәм шуңа нәзыйрә рәвешендә Казан ханлыгы заманында язылган «Кыз хикәяте»ндә дә гыйлемнең фани дөнья байлыкларыннан өстенрәк булуы бәйан ителгән.

Шунысы кызыклы, «Гыйлем Хакка илтер» әсәренең кайбер икеюллыклары Габдерәхим Утыз Имәни иҗатында кулланылган икән. Аның «Әбйате төрки фи фазыйләте гыйлем» (Гыйлемнең өстенлеге турында төркичә бәйтләр) дип исемләнгән, 150 юлдан торган күләмле шигырендә «Гыйлем Хакка илтер» текстының ун юлы (биш бәйте) урын алган. Ягъни алар, кайбер сүзләре генә алыштырылган хәлдә, Г.Утыз Имәни шигыренең башында (унбишенче юлдан алып) рәттән язылган. Бу факт – борынгы әдәбияттан аеруча хәбәрдарлыгы белән мәшһүр Габдерәхим Утыз Имәнинең әлеге әсәрне дә яхшы белгәненә дәлил. Утыз Имәнинең шул ук әсәрендәге 30 шигъри юл төрекмән шагыйре Вафаи тарафыннан 1464–1465 нче елларда иҗат ителгән «Рауна-кыль-Ислам» китабының галимнәрне һәм гыйлемне мактаган бүлегеннән алынганын да искәртергә кирәк. Тик Г.Утыз Имәнинең моңарчы чыккан китапларында ул хакта әйтелмәгән. Габдерәхим Утыз Имәни бу әсәрендә, күрәсең, элекке шагыйрьләрнең фикерләрен туплаган һәм аларны куәтләп үзе өстәп язган, чөнки Шәрык һәм төрки-татар әдәбияты тарихында элеккерәк шагыйрьләрнең танылган шигъри юлларын соңгырак чор авторлары үз әсәрләренә кертү алымы киң таралганлыгы мәгълүм.

«Гыйлем Хакка илтер» әсәрендә кеше әгъзаларының Аллаһны танып белү һәм гыйбадәт кылу өчен яратылганына охшаш тасвирлар XVII гасыр суфый шагыйре Мәүла Колый иҗатында да бар. Мәсәлән, аның берничә хикмәтендә (шигырьләрендә) баш, йөрәк, күз, колак, тел, борын, кул, аяк һәм башка әгъзалар турында язылып, *«бу әгъзалар Хакка тагать кыйлмак өчүн»,* дип билдерелгән.

Бу әсәрнең киләчәктә, ихтимал, бүтән кулъязма нөсхәләре дә табылыр. Андый очракта, әлбәттә, эчтәлеге дә тулаем күзалланыр иде, шулай ук исеме, авторы, иҗат ителгән датасы кебек күп нәрсәләргә ачыклык керүе дә мөмкин. ■

«ДОШМАН АТКА АТЛАНГАНЫҢНЫ КӨТМИ...»

(Янә «Чура батыр» дастаны турында)

Лилия Мөхәммәтҗанова

Татар халкында Чура батырга багышланган әсәрләр берничә. Алар бер-берсеннән күләме, сюжеты, хәтта төрле жанрга каравы белән аерылып тора. Башка төрки халыклар эпосы белән аваздаш күләмле дастан һәм аның вариантлары, тарихи бәет һәм риваятьләр – һәммәсе дә бу образны халык каһарманы буларак тасвирлый.

Сүзебез Чура батырга багышланган тагын бер дастан турында. Ул «Ак юл» журналының 1916 елгы 5 нче санында Рәхим Баязит тарафыннан бастырылган. Автор үзе әсәрне «кыргыз риваятеннән» дип күрсәтә. Әле XX йөз башында да «казакъ» этнонимы «кыргыз» яки «каракыргыз» исеме белән параллель кулланылган, шуңа күрә узган гасыр башында басылган бу текстның астөшермәсендәге «кыргыз» сүзе «казакъ» мәгънәсендә кулланылуы аңлашыла. Шактый күләмле, гарәп язуында 4 битне тәшкил итә торган әлеге әсәр вакыйгалар үстерелеше җәһәтеннән, чыннан да, казакъ версиясендәге бер вариантка якын. Әмма текстны өйрәнә башлауга шул ачыклана: бу ияреп язу да, тәрҗемә дә түгел, ә мөстәкыйль әсәр. Мондый үрнәктә язу, ягъни билгеле сюжетны эшкәртеп, татар телле яңа бер иҗат җимеше барлыкка китерү – XIX йөз ахыры-XX йөз башында Казан татарлары иҗатына хас күренеш. Тугандаш халыклар фольклорына мөрәҗәгать итеп, уртак сюжетка татарча текстлар төзеп бастыру бу чорда аеруча популяр булган. Рәхим Баязит бастырган татар телле «Чура батыр»ны да хаклы рәвештә шушындый әсәрләр рәтендә карарга кирәк.

Татар әкиятләрендәге яисә риваятьләрендәге кебек, «күптән-күптән, инде

монннан ничә йөз еллар элек» дип башланып киткән дастанның беренче юлларында Ак кала исемле шәһәрдә Айрактан һәм Тәмән дигән кабиләләрнең яшәгән булуы турында хәбәр ителә. Әсәр алга таба күчмә феодаль тормыш рәвешен тасвирлый, ике кабилә арасында барган ызгыш-талашлар турында сөйли. Шундый керештән соң, дастанга Нарык образы килеп керә. Чурага багышланган дастаннарда бу исемнең вариантлары күп: Нарык, Наррәң, Нарәң, Нәрек, әлеге текстта исә «Нарик» дигән вариантта бирелгән. Башка төрки версияләр, шул

исәптән И.Березин варианты Нарыкның тормыш юлын көтү көтү, ханга хезмәт итүдән башласа, Р.Баязитта ул – «игечиге булмаган дәүләте аркасында бөтен тир-юньдә мәшһүр бер бай».

Тикшерелә торган вариантта Нарык, балалары булуны сорап, изгеләр каберенә бара, корбаннар чала. Чура батырга багышланган дастаннарның казакъ вариантында Нарык белән аның хатыны Бабай-Тукты-Чәч каберлеген зиярәт иткәннән соң, ир белән хатынның теләге тормышка аша. «Алпамыш»ның югарыда телгә алынган вариантында да, Шаһимәрдән каберлегеннән бер өн чыгып, Байбүре белән Байсарыга аларның теләкләре кабул булачагын әйтә. Р.Баязитта исә культка табынуның файдасызлыгы ап-ачык итеп ассызыкланган. Бу да – дастанга татар авторы керткән төзәтмә. Изгеләр каберенә барып ялварганы өчен түгел, ә *«Алланың рәхмәте белән көннәрдән беркөнне Нарыкның хатыны дөньяга ир бала китерә»*.

Балага исемне Чура дип кушалар. Казакъ дастанына нигезләнсә дә, Р.Баязит исем вариантын татарча яңгыраште алган, юкса казакълар Чура димиләр, аларда – Шора. Төрки халыкларның героик эпосы каһарманы туганда ук, хәтта туганчы ук кем булачагын белгертә, тугач исә гадәттән тыш тиз үсә, көче-куәте, зирәклеге белән дә аерылып тора. Р.Баязит вариантында да әлеге кагыйдәләр төгәл үтәлгән. Чура тиз үсә, дөньяга килүенә кырык көн дигәндә көлә һәм ата-анасын ят кешеләрдән аера башлый; бер яшьтә ул үзенең матурлыгы белән халыкны таң калдыра. Дүрт яшендә укый башлап, ун яшендә *«шул замандагы бөтен укуларны тәмам итә»*. Каһарманның гадәттән тышлыгын тасвирлаганда автор уртак мотивны нигез итеп алган, әмма традицион булмаган үз сурәте сизелә. Чураның белем алуы турында хәбәр, кырым татарлары версиясеннән кала, башка дастаннарда очрамый.

Геройның тышкы кыяфәтен сурәтләгәндә эпик әсәр игътибарны аның физик сыйфатларына юнәлтә. Казакъларның Кобланды батыры, мәсәлән, киң ишектәй күкрәккә, калкандай нык иңнәргә, чүкечтәй авыр йодрыкларга ия. Р.Баязитның «Чура батыр»ында да герой *«уникe яшенә җиткәндә әкиятләрдә генә сөйләнә торган зур бәдәнле, киң күкрәкле, гайрәтле бер батыр»* булып әверелә. Ниһаять, кырык өйле тәмәннәр кабиләсендә чын баһадир үсеп җитеп, аларга карата дошман булган айрактаннарны тар-мар итә башлый.

Сугышчан чаптар аты Чурага һәрвакыт ярдәмгә килә. Чура батырга багышланган төрки дастаннарда Гали би (Али би яисә бәй), каһарманның ата-анасын рәнҗетеп, малларын суеп, иң шәп атын алып киткән була, атасы Нарыкның яхшы аты Тасмалы Керне (Тасмагер) Чура Гали би белән каты орышта кире кайтаруга ирешә. Биредә исә Чура батыр атасыннан *«судагы балык кебек, һавада очкан кош кебек, җилдән дә тизрәк йөри торган»* яхшы ат сорап ала. Бу атның җитезлеген сурәтләүдә дастанның тел-стиленә җете чагыштырулар хас: *«Тулпарның чабуы шулкадәр шәп була ки, хәтта күлдәге су аның җиленнән дулкынланып кала, шунда күл читендә утырган кошлар аның аяк астыннан очып чыгарга өлгерми тапталып калалар»*. Беркемгә баш бирмәс тулпарны иярләүгә ирешеп, Чура Гали бинең улы Занминнәткә каршы көрәшергә китә. Занминнәтне, Айрактан кабиләсеннән булган башка яшьтәшләрен җиңеп, аларның барчасын кырып бетергәч, Чура батыр Гали бинең коралланган гаскәренә каршы китә. Гали би, – югарыда әйтелгәнчә, Чураның ата-анасына һәм бөтен ыру-кабиләгә көн күрсәтмәүче чит кабилә җитәкчесе. Күчмә халыкларда җир мәсьәләсендә кабиләара көрәш халык иҗатында шул рәвешле чагылыш тапкан.

Гадәттәгечә, биредә дә Чураның язмышы Казан каласы белән бәйләнә: алдагы җиңүләрне эзләп, Чура Ак Каладан Казанга, *«Казан ханына хезмәт итәргә дип»*, юлга чыгып китә. Әсәр шушы урында тәмам була. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2017

ЧУРА БАТЫР

Рәхим Баязит

Күбдән-күбдән инде, мондан әллә ничә йөз еллар элек Ак кала исемле бер шәһәрдә Айрактан һәм Тәмән исемле ике кабилә торган. Айрактан кабиләсе шул йирнең халкы булып һәм үзләренең ханлыгы булганлыкдан, алар анда үз йортларына хуҗа булган кебек бөтен тирә-юньгә хуҗа булып торганлар. Кырык өйле тәмәнләр тик соңгы вакытда гына анда күчеп килгәнлекдән, ул хәдле бик иркенли алмаганлар һәм айрактанларга ясак түләп, күб маллар биреб торганлар. Айрактанлар күб булганлыкдан һәм шул йирнең хуҗасы булганлыкдан, бу кырык өйле тәмәнләрне һаман җәберлиләр вә теләгән хәдле алардан мал алалар икән. Шуңа күрә тәмәнләргә тормыш бу йирдә бик авыр, бик кысырыклы булган. Үзләрене сакларлык бер куәтләре булмаганлыкдан, алар һаман тегеләргә баш игәнләр, һаман аларның дигәнен эшләгәнләр, һаман аларның сораганларын биргәнләр.

Шул кырык өйле тәмәнләр арасында кырык беренче өй Нарик байныкы булган. Нарик бай, үзенең иге-чиге булмаган дәүләте аркасында, бөтен тирә-юньдә мәшһүр бер байлардан хисабланган. Аның шул хисабсыз малы арасында, кышкы салкын кара төндә йөз меңләрчә йолдызлар арасында берсе генә ялтыраган кебек, бердәнбер кап-кара тулпары булган. Ул тулпарны күргән кеше исе китә икән, чөнки аның кебек матур һәм гайрәтле ат булса да тик хәзрәт Галинең дөлдөле генә булгандыр, диләр!..

Нарик бай үзенең янында булган тәмәнләргә һәрвакыт ярдәмләшә: өе югына өй салып бирә, малы югына мал бирә икән. Кыскасы, Нарик бик бай булган, маллы булган, шөһрәтле булган; ләкин аның тик бер йире генә йитмәгән! Ул да (булса) картайган көнендә үзенә бер терәк булырлык баласы булмаган. Кырык өйдә кырык бала булганда тик бер Нарик бай гына баласыз булу, әлбәттә, күңелле эш түгел. Нихәдле корбаннар чалып, Аллаһдан бала теләгән, нихәдле әүлиялар каберенә барып, зиярәт итеп, шунда кунып, итене фәкыйрьләргә өләшеп, догалар кыйлган. Ләкин бала булмаган да булмаган...

Көнләрнең бер көнендә, төнләрнең бер төнендә, Аллаһның рәхмәте аркасында, Нарик байның хатыны дөньяга бер ир бала китерә һәм исемене Чура кушалар...

Чура бик тиз арада үсә: дөньяга килгәненә кырык көн тулганда ул көлә һәм ата-анасыны ят кешеләрдән аера! Бер яшь тулганда ул үзенең матурлыгы белән бөтен халыкның исене китәрә; дүрт яшендә укый башлап, ун яшендә шул замандагы бөтен укуны тәмам итә; унбер яшендә ул бик матур бер җегет була һәм унике яшенә йиткәндә әкиятләрдә генә сөйләнә торган зур бәдәнле, киң күкрәкле гайрәтле бер батыр кебек була.

Юлаучылар аны күреб гаҗәпләнәләр иде, әмма дәшмәнләр, гайрәтле арысланны күреб, куркалар, тетриләр иде...

Чура үзенең яшь йөрәгенең тибүенә, яшь тамырларында саркыган канына чыдый алмый, аның зур бәдәнендәге көче ашкына, чыгарга омтыла.

Ул бөтен йир шарын бер кулына күтәреб, бармагындагы йөзек кебек әйләндерәсе килә. Аңа бундый тыныч тормыш ошамый. Ул күңелсезләнә.

Шуңа күрә ул көнләрдән беркөн атасындан үзенә бик яхшы, судагы балык кебек, һавадагы очкан кош кебек, җилдән дә тизрәк йөри торган ат сорый һәм үзенең шул атка атланып, арысланлар ауларга чыгасы килгәнен һәм айрактанлардан аталарының үчене аласы килгәнен белдерә. Ләкин атасы углының айрактанлар белән сугыш ачыб,

үзләренә әллә нинди һәлакәтләр китерүендән куркыб, әүвәлрәк ат бирергә риза булмый, ләкин улы бик үтенеб сорагач кына үзенең җылкы өерендән бер ат сайлап алырга рөхсәт итә.

Чура кулына корык тотыб, кырга ат өерләрене эзләб чыгыб китә. Юлдан бер читдә бик күб уйнаб йөргән Айрактан балалары күренә һәм алардан читдәрәк Кырык тәмән балалары күренә. Чура, тәмәнләр янына барыб:

– Нигә сез теге күб балалар белән уйнамыйсыз? Әллә алар сезне җәберлиләрме? – диб сорый.

– Сез сорамагыз, без әйтмик инде... – дип җавап кайтаралар балалар. – Әнә шул күб бала – алар барысы да Айрактан балалары. Аларның башлыгы – Гали бәйнең баласы Занминнәт; аның усаллыгына һич чыдар хәл юк. Ул безнең күзебезне ачырмый һаман җәберли. Алар бар чакта безгә рәтле урын юк, рәтле йир юк...

Чурага бу сүзләр бик нык тәэсир итә, күзләре яна, йөрәге кызу-кызу тибә башлый, шул балалардан үч аласы килә.

– «Җәяү сугышка бармыйлар, әмма дошман синең атка атланганыңны көтми», – дигәнләр. Сез, туганлар, хәзер алар янына барыңыз һәм ничек дә аларны ачуландырыб, сугыш ачыңыз, мин хәзер сезнең арттан барыб йитәрмен, диб, Чура шул йирдән ерак түгел бер күлгә китә. Ул күлгә һәрвакыт Нарик байның маллары килеб су эчәләр икән. Чура шунда бер читдә утырыб көтә. Озакламый, ерактан тузан күтәреб, маллар шул күлгә таба агыла башлыйлар. Шул күб мал арасында җем-җем кара төсле, бигрәк дә матур бер ат килеб чыга. Бу ат югарыда әйтелгән Нарик байның мәшһүр тулпары була. Чураның үткен күзләре бу яхшы атны бик тиз таныйлар һәм ул, аның янына барыб, тотмакчы була. Ләкин тулпар янына кеше килгәнне сизеб, арты белән тора һәм тибәргә хәзерләнә. Атның бу кыланышы Чурага ошамый, ул кулындагы корык белән бик нык атның сыртына берне утырта. Ат да көчле кулны сизеб, каршы торуда файда юклыгыны аңлаб, йиргә кагып куйган кадак кебек, урыныннан кузгалмый тик тора. Чура атны җөгәнли дә, атланыб китә. Тулпарның чабуы шулкадәр шәп була ки, хәтта күлдәге су аның җилендән дулкынланыб кала; шунда күл читендә утырган кошлар аның аяк астындан очыб чыгарга өлгерми табталыб калалар. Чура шадлана.

Күз ачыб йомганчы ул теге балалар янына барыб йитә. Бу вакыт Айрактан балалары җыелышыб тәмәнләрне бик каты кыйныйлар икән. Чура, буны күреб:

– Оятсызлар! Сезнең мәмләкәтегез көчсез бәндәләрне аяк астына салыб табтарга корылган мәмләкәт икән. Ләкин бу көндән соң исеңездә булсын: тәмәнләрнең өстенә дә кояш чыкды, хәзер аларның кабиләләрендә Чура исемле бала туды. Менә ул сезнең күблекеңездән курыкмаячак һәм сездән бу көнгә кадәр җәберләнгән тәмәнләрнең үчене алыб, бик күб елларга кадәрле аның бер исемене генә ишеткәндә сез барыңыз да тетрәячәксез, – диде дә, шундагы Гали байның баласы Занминнәтне корык белән сугыб, башыны кырыкга бүлеб, тәмәнләргә гәүдәсене ыргытды. Тәмәнләр, ачуларындан, Занминнәтнең гәүдәсене йөзгә бүлеб ташладылар. Чура бу вакыт барлык Айрактан балаларын кыра һәм кулга эләкгән берсене юк итә иде. Бик аз вакыт эчендә Айрактан балалары кырылыб бетделәр, алар арасыннан тик бер таз җаныйайы гына качыб китә алды.

Бу куркынычлы вакыйга тиз арада айрактанлар арасына таралыб, Гали бәйнең үзенә дә ишетелде. Гали бердәнбер углының үлүене ишетеб элек бик кайгырса да, соңындан ничек дә ачуы кайгысыны җиңеб, йөзләре бер усал кыяфәткә килеб, тешләре шыгырдаб, Нарик байның баласы Чураны йир йөзендән юк итәргә булды.

Шуның өчен ул үз янына бик яхшы коралланган, гайрәтләре һәм бөтен батырлыклары белән гаскәр арасында танылган кырык егетне сайлаб алыб, тәмәнләргә каршы

Безнең мирас №12 декабрь 2017

юлга чыкды. Гали бәйнең фикере Чураны гына түгел, хәтта бөтен Тәмән халкыны кырыб бетереб, аларның бар малларыны үзенә әүвәлчә итеб алыб киту иде.

Тәмәнләр, бу вакыйганы ишетеб, шашыб калдылар. Чура Гали бәйнең кадерле углыны үтергәч, Гали бәйнең боларның барысындан да ачу алуы бик билгеле иде. Аңа каршы торырлык тәмәнләрдә көч-куәт дә юк. Шунлыктан, алар зур кайгыга батдылар, еглаштылар.

Чура, боларның кайгырганын күреб:

– Сез юкга кайгырасыз. Гали бәй үзенең кырык мең айрактанын бергә алыб килсә дә, мин аны бу йиргә йибәрмәм, Аллаһдан минем сәламәтлегемне теләңез! – диде дә, үзенең атына атланыб, Гали бәйнең каршына китде. Аны бөтен Тәмән халкы озатыб калды.

Бу вакыт Гали бәй үзенең кырык егете белән Чурага каршы килә иде. Еракдан камыш араларындан кояшка каршы Чураның сөңгесе ялтыраб күренде. Озак да үтмәде, Чура камыш арасындан чыгыб, Гали бәйнең каршына килеб туктады. Гали бәй вә аның кырык егете, Чураны күреб, багана кебек катдылар. Гали бәй үзе Чураны бүгенгә кадәр күргәне юк иде, шуңа күрә, Чураның арыслан кебек гайрәтле бәдәне һәм карчыга кебек үткен карашы аңа бик нык тәэсир итде. Чура бу вакыт, һичбер нәрсә булмаган кебек, боларның каршында үзенең сөңгесенә таяныб, аты өстендә утыра. Әмма аның астындагы аты пошкыра. Тояклары белән йирне казый вә зур кара күзләрендән утлар чәчә иде.

Гали бәйнең янындагы кырык егете, Чураның каршында тора алмый, камыш араларына кереб качдылар. Гали бәйнең дә гомерендә болай курыкганы юк иде. Ул бөтенләй дерелди, каушый иде.

– Егетләр белән кая барасың, хөрмәтле Гали бәй? – диб сорады Чура Гали бәйдән.

– Тәмәнләр кабиләсендән Нарик бай углы Чура син түгелме? – дип сорады каушаб Гали бәй. – Мондарак кил! Сиңа хандан сәлам һәм ул синең тулпарыңны сораб җибәрде, – диде.

– Мине тәмән баласы диб атаңыз! Кырык мең айрактанларны йир йөзендән себереб түгәр өчен туган баламын. Ничек оялмый син минем тулпарымны сорыйсың, аның өстендә миндән башка һичбер адәм утыра алачак түгел! Син мине яныңа чакырыб, берәр начарлык эшләргә уйлыйсың, ләкин инде синең кулдан һичбер нәрсә килмәячәк.

– Ах, оятсыз! Син үзеңне ахры бик зурга куясыңмы! Хәзер мин сиңа үземне танытыйм. Син әле Гали бәйнең кем икәнен белмисең икән. Тулпарны үз ирегең белән бирмәсәң, мин аны көчләб дә ала белермен.

– Гали бәй! – диде гайрәт белән Чура. – Андый серләрне күб сөйләмә! Синең бу көнгә кадәр таянган агачың инде киселде. Онытма! Рәтсез кылана башласаң, бүген каргалар синең итеңне дә ашаб бәйрәм итәчәкләр.

Бу көнгә кадәрле андый сүзләрне ишетеб өйрәнмәгән Гали бәй Чураның бу сүзләренә бик ачуланыб, кызуындан кылычыны чыгарыб селтәде. Ләкин Чура аны сөңге белән чәнчеб, бер кечкенә баланы күтәргән кебек һавага күтәрде. Сөңге Гали бәйне озак күтәреб тора алмады, икегә сынды. Шуның бер башында Гали бәй иде. Гали бәйнең кырык егете дә Чураның ачуындан котыла алмадылар: Чура Гали бәйдән соң аларга арыслан кебек атылыб, берничә селтәү илә барысын да бетерде.

Шул вакыйгадан соң тәмәнләр күз ачдылар, айрактанлар аларны әүвәлге кебек кысу урынына алар бар йиргә хәтта барырга курка башладылар.

Чураның исеме шул көндән соң бик тиз арада төрле кабиләләр арасына таралыб, хәтта зур батырлар аны күрми торыб куркыр булдылар. Чура үзе бу вакыйгадан соң Ак калада калмыйча, ата-анасыннан аерылыб, Казан ханына хезмәт итәр өчен юлга чыгыб китде.

Текстны басмага ***Лилия Мөхәммәтҗанова*** *әзерләде.* ■

Безнен мирас №12 декабрь 2017

Күренекле археограф, тарихчы Сәетгаттар Габделмәннан улы Вахиди Казан губернасының Спас өязендәге Ташбилге авылында 1887 елның 30 маенда дөньяга килә. Кечкенәдән үк әти-әни һәм әби-бабасы сөйләгән риваять-әкиятләр тәэсирендә үскән бала, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга кергәч тә, Шиһабетдин Мәрҗани китапларын укып, борынгы тарихыбыз белән кызыксына башлый. 1911 елда әлеге мәдрәсәне тәмамлагач, Казан губернасының Уразлы авылында укыта. 1912 елда туган авылында башлангыч мәктәп ачып, шунда агарту эшен дәвам итә. 1914 елда Казандагы 3 нче мәктәпкә мөгаллим итеп билгеләнә һәм татар әдәбиятын, татар һәм рус халыкларының тарихын укыта. Укытудан бушаган вакытта борынгы чыганакларны барлый: кабер ташларындагы язуларны күчереп ала, халык арасында таралган риваятьләрне өйрәнә, кульъязмалар җыя.

«БУ ЭШЕБЕЗ НИГЕЗ ТАШЫ БУЛСЫН...»

(КФУның Н.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе фондында Сәет Вахиди мирасы)

Рәйсә Шәрәфиева


Перевод С.М. Вахидова

Ярлык Сахиб Гирея

Воитель Сахиб-Гирея (слово)

Эмирам, высшим судьям, великим сеидам, народным судьям, почетным лицам, уполномоченным, чиновникам на местах, посланникам, садовым чиновникам, судовым чиновникам, полицейским чиновникам, чиновникам на заставах, таможенным чиновникам, всему населению, вообще всем казанским областям и всем государствам, да будут они хранимы от бедствий и несчастий.

Когда до них дойдет этот приказ, слов мое таково: этот Шейх-Ахмед сын Мухаммеда, потом сын Шейх-Ахмеда Абдал, потом Саид-Ахмед, его брат Мухаммед сын Муса, Якуб сын Саида, его брат Буланс, его брат Нур-саид — эти семь человек, пришедши к нам, били челом, что они были тарханами прежних уважаемых ханов; мы вновь пожаловали упомянутых лиц во имя великого Бога и ради пророка Мухаммеда, сделали их тарханами. Их назначенным лицам на дорогах, в селениях, в путях, даже во всякое время — когда они сидят и когда встанут, к их крестьянам, поместьям, водам и скоту не смеют пусть прикоснуться злые намерения и не вмешиваются злые поступки и действия ни одного человека. Ясак, оброк, подать, именуемую „салы" не взимать. Подать „кунак-култыка", „сус", торговой налог не требовать. К имуществу, собственности, деньгам, водам, землям никто руку пусть не протягивает. В дом их насильно пехлеваников гостей не ставить. Деревенскую подать, земельный налог, налог с трубы не собирать. Продовольствия, фуража не требовать. Ни с каких сторон вреда и притеснений (им) не причинять. Пребывая в спокойствии, вечером, утром, днем и ночью, они воссылали бы нам и нашим потомкам молитвы и добрые пожелания. А всякого рода насилие, беды, вред, беспокойства

Сәет Вахидинең Сәхипгәрәй хан ярлыгы турындагы мәкаләсеннән бер бит. 1935 ел

Шиһабетдин Мәрҗанинең «Вафийәт әл-әсляф...» китабы. XIX гасыр азагы



«Кыйссаи Йосыф» әсәренең Әтнә районы Бәрәскә авылында күчерелгән нөсхәсе. 1835 ел

1912 елда Сәет Вахиди зур фәнни ачыш ясый – Мамадыш ягындагы Мамай авылында яшәүче Рәхмәтулла Әхмәревтә борынгыдан сакланган Сәхипгәрәй хан ярлыгына тап була. 1523 елда язылган, Казан ханлыгы чорыннан калган, моңарчы бер галимгә дә мәгълүм булмаган сирәк документның кыйммәтен аңлагач, галим аны сатып алырга тели. Әмма хуҗасы, үзе язу танымаса да, бу кулъязмадан аерыласы килми, күчереп алырга да рөхсәт бирми. Сәет Вахиди шул авылның мулласына – Кәшшафетдин Рахманколыйга мөрәҗәгать итә. Мулла ярдәм итәргә риза була һәм Рәхмәтулла агайга кеше җибәрә, бер көнгә генә теге кулъязманы сорап тора. Сәет, шатланып, кулъязманы күчереп ала.

Сәет Вахиди 1914-1917 елларда Беренче Бөтендөнья сугышында катнаша. Сугыштан кайткач, яңадан әлеге кулъязманы кулга төшерү хыялы белән яна башлый һәм, җитәрлек акча җыйгач, 1920 елның 15 июнендә Сәхипгәрәй ярлыгын Рәхмәтулла агайдан сатып ала.

Галим 1918-1920 елларда Казанда укытучылар курсы оештыра. Ул курста укучыларга шушы сораулар нигезендә анкета тутырырга куша: *«Сез укыткан авылда кеше кулында Болгар һәм Казан ханлыгы чорыннан калган кулъязмалар бармы? Булса, әсәрнең исемен, язучысын, язылу вакытын күчереп язып, миңа җибәрергә. Иске мәчетләрдә, мәдрәсәләрдә, муллалар, мөгаллимнәр өендә иске китаплар бармы?»* Нәтиҗәдә, шушы анкета ярдәмендә, шактый гына борынгы кулъязмалар табыла.

Сәет Вахиди 1919-1921 елларда Казан университеты рабфагында укыта. Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте, Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте, Гыйльми үзәк һәм башка фәнни оешмаларның әгъзасы була.

1925 елның 1 февралендә С.Вахиди Сәхипгәрәй хан ярлыгын ТАССР Милли музеена бүләк итә, чыганак хәзерге вакытта да шунда саклана.

1928 елдан ул ТАССР Дәүләт музееның Шәрык кулъязмалары бүлеге мөдире булып эшли башлый һәм Россия археография комиссиясе белән хезмәттәшлек итә. 1930 нчы еллар башында Татарстан икътисад фәнни-тикшеренү институтында эшли.

Галимнең татар халкының бай мирасы юкка чыгуга борчылып язган мәкаләләре шак-



Сәет Вахиди китапханәсеннән кульязма китаплар

тый. «Игенче» газетасының 1929 елгы 10 октябрь санында «Минзәлә кантонын тарихи яктан өйрәнү» исемле мәкаләсендә болай дип яза: «*... Симәк авылында Мөхәммәтнәсип Төхфәтулла улының борынгы бабалары тархан булганлыкны – аларның кулында Казан ханнарыннан бирелгән тарханлык ярлыгы булганлыгын сөйләделәр. Шактый иске заманнардан бирле муллалар кулында яшәп килгән бер көтепханәдә иске кульязма–документлар арасында бер кульязма әсәр булган. Анда Казанга хан сайларга бару, ханнарның җыелган вәкилләргә сөйләгән сүзләре, Казан ханнарының тәрҗемәи хәлләре, Мәскәү кенәзләре белән булган төрле сугыш вакыйгалары, Казанның алынуы һәм бүтәннәр язылган. Шуңа ханнарның ярлыклары да теркәлеп куелган булган икән. Аянычка каршы, бу көтепханә 1910 нчы елда булган зур янгында юкка чыккан*».

С.Вахиди, авыл халкының өйләрендә сакланган борынгы кульязмаларның янгында юкка чыгуы, күп җирләрдә утильсырьега тапшырылу турында газета битләрендә мәкаләләр бастырып, чыганакларны туплау, өйрәнү өчен Гыйльми үзәк оештыруның зарурлыгын исбат итүгә күп көч куя. Аның тырышлыгы бушка китми, 1925 елны андый үзәк барлыкка килә.

Сәет Вахидиның борынгы мирасны өйрәнүдәге фидакарь хезмәтен бу юллар да дәлилли: «*Бөтен көч һәм тәҗрибәләрне җыйнап, кирәк булган бөтен чара һәм методларны кулланып, мин эшкә керештем. Берсе артыннан икенчесен көтепханәләрне тикшерә, актара башладым. Аерым кешеләрнең көтепханәләрен, кечкенә архивлар, шүрлек, шкаф һәм киштәләр, андагы бөтен язмалар; очырмалар, андагы ящик һәм сандыклардагы бөтен кульязмалар, барлык басма китаплар, төргәк-кәгазьләр – барысы да минем күздән кичерелә, тикшерелә, үткәрелә бардылар. Очырмалардагы тузан-туфраклар, утын амбарларындагы, подвал һәм кладовойлардагы сырость, пычрак вә салкыннар бу эшне дәвам иттерүдән мине туктата алмадылар*».

С.Вахиди тарафыннан бүләк ителгән борынгы кульязмалар тасвирламасының соңгы битендә болай диелгән: «*Без бу каталогка язылган язма тарихи хатирәләрне борынгы бабаларыбызның олуг мәдәни хәзинәләренең төрле афәтләргә очраганнан соң тузылып, чәчелеп калган калдыклары икәнен истә тотдыкыбыз хәлдә, аларның эчендә*

Мәхмүд Гали Болгариның «Нәһҗел фәрадис» әсәре. XV гасыр

тел-әдәбиятыбызны һәм аның тарихын, шулай ук тарихыбызны вә гомумән үткәндәге бабаларыбызның тормыш вә кичмешләрен өйрәнүдә дөрес вә битараф мәнбәгъ [чыганак] булу ягыннан гаять мөһим урын тотканлыкларын әйтеп китүне бурычыбыз [дип] саныйбыз. Киләчәк яшь буыннар вә гомумән гыйлем ияләре, безнең төрле вакытларда, төрле татар авылларына йөреп, эзләп-табып алган документ һәм кульязмалардан киң вә тулы файдалану белән бергә, боларга нисбәтән күп дәрәҗәдә мөһим язма мәдәният хатирәләребезне эзләп табуларына безнең бу эшебез башлангыч булып, киләчәктә нигезләнәчәк бөек гыйльми көтепханә вә аның янындагы кульязма вә документлар бүлегенә безнең бу язма хатирәләребез беренче нигез ташы булсын».

КФУның Н.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә С.Вахидинең шәкерт чактагы өйрәнчек язулары, Идел -Чулман буйларының үткәне турында татар риваятьләре, Сәхипгәрәй хан ярлыгының күчермәсе һәм аңа бәйләнешле төрле язулар, галим тарафыннан 1925 елда Татарстан Үзәк музәханәсенә бүләк ителгән кульязмаларның каталогы, 1938 елның 5 гыйнварында атып үтерелүе турында белешмә-справка һәм башка шәхси язмалар бар.

Китапханәдә С.Вахиди тарафыннан җыелган 3000 кульязма саклана. Алар арасында Шиһабетдин Мәрҗанинең 6 томлы «Вафийәт әл-әсляф...», Каюм Насыйриның хатлары, календарьларның цензор нөсхәләре, дини язмалары, дәреслекләре; Хәсәнгата Габәши, Нәҗиб Түнтәри, Габдулла Буби кульязмалары; Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» күчермәләре, «Кабуснамә», Мәхмүд Гали Болгариның «Нәһҗел фәрадис» әсәре, «Мөхәммәдия», Коръәннәр, тәфсирләр һәм башка төрки-татар, гарәп, фарсы телләрендәге күпсанлы кульязмалар бар.

1937 елда Сәет Вахиди кулга алына, аңа пантюркист идеяләрен таратучы дигән нахак бәла ягалар. Алдарак язылганча, галимне 1938 елның 5 гыйнварында атып үтерәләр. ■

2016 елның көзендә тарих фәннәре кандидаты Фәридә Юлдаш кызы Гаффарованың (1951-2006) шәхси архив-китапханәсен галимәнең гаиләсе – ире Әхәт Гаффар, кызлары Ләйлә белән Сөмбел Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә тапшырды. Ошбу елның сентябрь азагында галимнәр, китапханәчеләр һәм җәмәгать эшлеклеләре катнашында әлеге коллекцияне укучыларга тәкъдим итү чарасы узды. Анда әйтелгән кайбер фикерләрне сезгә дә тәкъдим итәбез.

Бибәһа хәзинә

РАЗИЛ ВӘЛИЕВ:

«Бу – татар мәдәнияте өчен зур вакыйга»

Фәридә Гаффарова безнең китапханә белән бик тә дустанә мөнәсәбәттә иде. Мәгълүм ки, Садри Максуди – зур галим, сәясәтче, дәүләт эшлеклесе. Фәридә бу теманы ничек ерып чыгар икән, Төркиядә эшләр өчен финанс кайдан юнәтер, әлеге шәхеснең туганнары белән уртак тел табармы икән, дип шикләнә төштем. Ул чорда Төркиягә барып кайту гаять мәшәкатьле иде. Әмма Фәридә бик җитез булып чыкты. Ул үзеннән соң зур мирас калдырды. Шушы хәзинәнең Татарстан Милли китапханәсе фондына бүләк ителүе гаять игелекле гамәл. Бу – татар мәдәнияте өчен зур вакыйга.

СӨМБЕЛ ГАФФАРОВА:

«Шунысы куанычлы – дәвамчыбыз бар»

Әнигә бу архивны тупларга мин дә ярдәм иттем. Без Әхмәтһади Максудиның кызы Бәһрәмия апа һәм оныгы Диләрә апага барып, алардан бер чемодан тулы кулъязма дәфтәрләр, басма китаплар алып кайттык. Бу әнием өчен бик шатлыклы вакыйга булды. Күпләр Төркиягә барып кием-салым төяп кайтса, әнием аннан китап һәм кулъязма яки аларның күчермәләрен ташыды. Шунысы куанычлы: безнең ике туган кардәшебез Миләүшә Гайнанова Садри Максудиның Төркиядәге эшчәнлеге турында кандидатлык диссертациясе яклады – бу юнәлештә әнинең дәвамчысы бар.

ЛӘЙЛӘ ГАФФАРОВА:

«Бу китаплар әнием өчен зур хәзинә иде»

Әниемнең планнары күп булды. Садри Максудидан соң, аның абыйсы Әхмәтһадиның эшчәнлеген өйрәнде. Безгә аның татар мәдәнияте өчен күп гамәлләр кылганын аңлатты. Бу китаплар әнием өчен зур хәзинә иде. Алар шәхси китап киштәсендә тузан җыеп тик ятарга түгел, ә тагын да фәнни хезмәтләр бирергә

Безнең мирас №12 декабрь 2017

тиеш. Әнинең татар халкы өчен йөрәге янды. Бәлки киләчәктә халкыбызның асыл егет-кызлары бу китапларны өйрәнер, әниемнең рухи дәвамчылары булыр, дип өметләнәм.

ФӘРИТ СОЛТАНОВ:

«Тарих фәне буенча диссертацияне татар телендә яклап үрнәк күрсәтте»

Фәридә Гаффарова фәнни юлын Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының 1970 нче елларда оешкан иҗтимагый фикер тарихы бүлегендә лаборант буларак башлап җибәрде. Башта, Яхъя ага Абдуллин куйган максатны истә тотып, марксистик листовка-прокламацияләрдә татарлар нинди фикер күтәргәнен өйрәнде, соңрак «Шура» журналын тикшерде. Үзгәртеп кору чоры башлангач, Садри Максуди эшчәнлеге, төркичелек темалары белән мавыга башлады. Диссертациясен татар телендә язды һәм яклады, янында Рафаэль Мөхәммәтдинов тәрҗемә итеп торды. Күпләргә ул тарих фәне буенча диссертацияне татар телендә яклап та үрнәк күрсәтте. Фәридә Гали Акыш мирасы белән кызыксынды, галимнең бай мирасын Казанга алып кайтырга теләде. Аның турында китап чыгарырга да өлгердек. Бу да Фәридәнең чын күңелдән эшләгән изге эше иде.

АЙРАТ ЗАҺИДУЛЛИН:

«Автографлы китаплар аерым әһәмияткә ия»

Фәридә Гаффарова коллекциясе 243 берәмлектән тора, шуларның 20гә якыны – кульязмалар. Алар арасында Әхмәтһади Максудиның гаилә әгъзалары белән язышкан хатлары, «Нәсыйхәт» китабының кульязмасы, типография өчен әзерләнгән басмаларның гранкалары, аның кулы белән язылган караламалар бар. 40ка якын газета-журнал алынды. Аларның кайберләре, мәсәлән, «Акмулла» журналының нөсхәләре безнең бүлектә юк иде. XX гасыр башында чыккан «Ак юл», «Ялт-йолт», «Мәктәп», «Шәрык кызы», «Дин вә мәгыйшәт», «Хокук вә хәят», «Аң» журналларының, «Тәрҗеман» һәм «Йолдыз» газеталарының да аерым саннары – бибәһа хәзинә. Фәридә Гаффарова коллекциясендә автографлы китаплар аерым әһәмияткә ия. Алар арасында Муса Бигиев, Гыйбадулла Алпаров кебек олуг шәхесләребез Әхмәтһадига бүләк иткән китапларның кыйммәте бигрәк тә югары. Коллекциядә кырым татарларына нисбәтле китаплар да бар. Белүегезчә, Әхмәтһади Максуди андагы «Зынҗырлы» мәдрәсәсендә укыткан. Кырым татарларының атаклы җәмәгать эшлеклесе, публицист Хәсән Сабри Айвазов үз китабын «Мөхтәрәм әдибебез Әхмәтһади әфәнде Максуди җәнапларына...» дигән юллар язып бүләк иткән.

ЗӨФӘР РӘМИЕВ:

«Галимнең хезмәтләре фәнни кыйммәтен югалтмады»

Фәридә Гаффарованың Максудилар мирасына, «Йолдыз» газетасына игътибар итүе һәрьяктан хупланырга тиеш. Галимәнең басылып чыккан хезмәтләре хәзер дә кулланыла, фәнни кыйммәтен югалтмады. «Габдулла Тукай» энциклопедиясен эшләгәндә дә авторларыбыз аның китапларына, мәкаләләренә игътибар итте.

Фәридә институтның иҗтимагый тормышында да урынын

тапты. Ул минем хәтердә аралашучан, ачык фикерле, кешегә ихтирам белән карый торган шәхес буларак калды.

РӘМИЛ ИСЛАМОВ:

«Фәридә Гаффарова коллекциясе китапханәгә бик зур байлык»

Китапханәгә Әхмәтһади Максудиның үз кулы белән язган дәфтәрен генә бүләк итсәләр дә, бик зур байлык булыр иде. Троицкида басылган «Акмулла» журналы гына да ни тора!

Фәридә ханым көләч йөзле, ярдәмчел шәхес, әмма тоткан җиреннән өзеп тә ала торган кеше иде. Бу – яхшы мәгънәдә. Ул үзен һәм башкаларны да төрле җәберләүләрдән сакларга сәләтле инсан булды.

ИЛДУС ЗАҺИДУЛЛИН:

«Безнең буын Максудиларның мирасын кайтару эшен башкарырга тиеш»

Фәридә Гаффарова кебек шәхесләр – тормышны алга этәрүчеләр. Ул, институтта профсоюз лидеры буларак, күп эшләр башкарды, еш кына җыелышлар оештыра иде. Татар милләте, дип җан атып, халкы турында сөйләп, шул рухны таратып яшәгән күренекле шәхес булды. Без совет чорында исемнәрен дә әйтергә тыелган затларның мирасын акрынлап кайтара башладык. Фәридә Гаффарова – Максудиларны өйрәнү юлында капка ачып куйган шәхес. Аның тырышлыгы белән берничә конференция дә үтте. Безнең буын Әхмәтһади һәм Садри Максудиларның мирасын кайтару эшен башкарырга тиеш, аларның аерым китаплары да басылып чыгар, дигән өметтә калам. Максудиларның эшчәнлеге киңкырлы, шуңа күрә аларның мирасын кайтару эшен дә берничә институт берләшеп башкарырга тиеш, дип уйлыйм.

ИРЕК ҺАДИЕВ:

«Мирасны чүплеккә чыгарып ташлаулары турында еш ишетәбез»

Әхмәтһади Максуди – 1906 елда Казан шәһәре җәмәгать китапханәсенең мөселманнар өчен махсус бүлеген – «Китапханәи Исламия»не оештырган шәхес. Татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү, кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлекләре Максуди оештырган беренче рәсми татар китап йортының хаклы рәвештә дәвамчылары, дип саныйбыз.

Бу чараны фән дөньясында тирән эз калдырган, зур хезмәтләр кылган, өйләрендә бай архив-китапханәләр туплаган шәхесләребез уйлансын, үзләрендә булган тарихи ядкәрләрне тиешле оешмаларга тапшырырлар бәлки, дигән өмет белән дә уздырабыз. Язучы, галим-голәмәләребез мәрхүм булганнан соң, аларның балалары яки фатирларының яңа хуҗалары әлеге мирасны чүплеккә чыгарып ташлаулары, юкка чыгарулары турында еш ишетәбез. Мондый хәлләр безнең милләттә башка кабатланмасын иде!

Фәридә Гаффарованың гаиләсенә, әлеге мирасның әһәмиятен аңлап, аны безнең китапханәгә тапшырган өчен, Алланың рәхмәте яусын!

Текстны ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №12 декабрь 2017

ИСЕМЕҢ ҺӘМ ҖИСЕМЕҢ

(XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ИСЕМНӘРЕ ТЕЗМӘСЕНӘ БЕР КҮЗӘТҮ)

Әлфинә Сибгатуллина

Исеменең мәгънәле, матур, дини булуы, әлбәттә, кешегә күпмедер күләмдә җаваплылык рухы да өсти, әйтик, пәйгамбәр (с.г.в.) исемен йөрткән *Мөхәммәд, Мөхәммәдвәли*ләр гөнаһлардан иң куркырга тиешле кешеләр булырга тиешле. Тик һәрвакытта да кеше үз исеменең ни аңлатканын белеп бетермәскә, исеме белән җисеме туры килеп җитмәскә мөмкин. Мәсәлән, рисаләдәге Зөлкарнәйн – бөек Александр Македонскийның Көнчыгышта кулланылган исеме, ә автор бу исемне алган татар абзыен... өйләнә алмыйча йөрүче мескен бер ир-ат итеп тасвирлый:

قیام‌الدین تـوت قیامت درتنی بش نمازنی اوته‌گل‌سن هر کونی
قاسم آبظی قایغو توتمادنیااوچون صاقلاگیزلو بولغوچی قدر کیچون
قطب‌الدین قاتی سویلمه مچقرب قیوم آغای یبه‌رمه‌سن سپتروب
قوتلی احمد آشاغانـده سویلمه قرآن اوقوساڭ بیك اوزن کویلمه
قوتلمت قایغرمان دنیا اوچون دخی اوغالانماغیل یوقلارا اوچون
قربان علی قوناق کیلسه قارشوآل قوی‌لارڭنڭ سیمزن قربانغه چال

قافیت الکاف

کمال‌الدین کامل ایتکل ایمانـڭ آخری برکون عزرائل آلورجانوڭ
کلیم‌الله تور کوتوب‌سن اولومڭ طاش پولاطی طازادور بارویرڭ

قافیت اللام

لطف‌الدین سن سویمه ظالم کمسه‌نی یخشی اشکه اونده‌مه‌س ظالم سنی
لطف‌الله هم قوما فانی دنیانی سڭا آرتدن ایله نوربلگل آنی
لقمان اولساڭ کوب فکرله آخرت باراسی یولوڭ یراق آزق کیره‌ك

قافیت المیم

مفتاح‌الدین مالوڭ اولسه بیرزکواة سبب اولـور عمرگـه بـرکات
مصطفی مصحف سوزینه توت‌قلاق نفسی شیطانی توتوبن اوتغه‌یاق
مرتضی مالـوڭنی قیلماغیل حرام خراب اولما دنیاآخرت شول‌کلام
میرسیاف‌هم‌سنڭ اولسون آق‌یوزڭ آیة ایله‌ن حدیث اولسون هرسوزڭ
میرحیدر هم مهربانلو بولاکـور الانگری قل‌لغنی قیـلا کـور
محمود اولغل آلچاق هر بر کشی‌گه کونچیلك قیلما بره‌ونڭ اشینه
مولود آقای مالنی اسراف ایتمه‌گل حرام اشدر تله‌نورگه کیتمه گل
محمد کمال کوب ییمه کوب یوقلاما قایدا بارصاڭده اوزڭنی ماقطاما
محمدولی تـوت محبت تڭریگه کیچه کوندوز بول خدانڭ امریده

«*Зөлкарнәйн* булса исмең, йә агай,

Хатын алмыйча йөрисен ник алай».

«Син» дип үз итеп эндәшүе һәм, нигездә, гади сөйләм формаларын (ахмак улма, авызың ачып калма, тик ятма һ.б.) куллануы белән автор укучысына эчкерсез бер мөнәсәбәт күрсәтә. Хәтта урыны-урыны белән авыл абзыена афористик гыйбарәләр белән дә мөрәҗәгать итеп: *ике тиенлек файда бирмәс бу йокы; чана түләрсең, угрылаб тәртәсен*, дип үгетли.

«*Байморза*, башмакларыңа куй олтырак,

Оегың былчыранмасын, мәчет ерак», –

дип, аның хәленә керә. Язучының сүзгә чаялыгын исбатлаучы бу юлларны да китерми мөмкин түгел:

«*Зиннәтуллаһ*, зәки бул, булма юаш,

Намаз укы, бел, намазсыздыр чуаш.

---

* Ахыры. Башы журналның 11 нче санында. «Вәгазьнамә рисаләсе» исемле китапның тулы тексты белән beznenmiras.ru сайтында танышырга мөмкин.

Зәйнуллаһ, син зиннәт иткел эшләрең,
Бу намазларның төшергел тешләрен».
Ә биредә автор Каюм агайны бөтенләй дә хур итә:
«*Котбеддин*, каты сөйләмә кычкырыб,
Каюм агай ебәрмәсен сиптереп».

Авторның мондый «гадилеге» аңа дини-ислами терминнар, китаби гыйбарәләр һәм госманлыча сүзләрне куллануга һич тә комачаулык итми:
«Әсәдуллаһ, сәңа бәнем сүзем шул,
Сират-ел мөстәкыйм үзрә сабит уз.

Касыйм абзый, кайгы тотма дөнья өчен,
Сакла гизле булгучы Кадер кичен».
(Кадер киче Рамазан аеның соңгы ун көнендә «яшерелгән», көне төгәл билгеле түгел, дип фараз ителә.)

Авторның Таһирга мөрәҗәгате шул чор татар көнкүрешеннән бер картина бирүе белән кызыклы. Югарыда әйтелгән Биктаһир исеме кебек, *Таһир да тәһарәт* сүзе белән бәйле һәм «чиста, саф» дигәнне аңлата. Рәсәй мөселманнары XIX йөз азагы-XX йөз башында поезд, пароход кебек транспортларга утырып, озын юлларда сәяхәт иткәндә, мәсәлән, хаҗга барганда, гомуми туалетларда тәһарәтләнү мөмкинлекләре тапмаганлыктан, үзләре белән гел комган йөртергә мәҗбүр булганнар. Биш вакыт намаз укыган мөселман өчен комган иң кирәкле юл әсбабы саналган, шуңа күрә аны хәтта билгә бәйләп тә йөрткәннәр. Читтән карап торган кешегә көлке булып тоелган бу күренешне Фатих Кәрими «Шәкерт илә студент» (1899) хикәясендә сатирик рәвештә тасвирлап бирә. Менә безнең язучыбыз да әлеге гадәтне телгә ала:
«*Таһир*, дәхи тәһарәтсез йөремә,
Сәфәр барганда, комган так билеңә».
Ирләргә багышланган өлештә өйләнү темасы да, әлбәттә, кузгатылмый калмый:
«*Фәррахшаһ*, шадланма кызларны күреб,
Пешмәсен аузың, каба күргел өреб».
Өйләнергә җыенган егетләр кызның нәсел-нәсәбенә һәм укымышлы булуына игътибар итсеннәр, ди автор:
«*Фәррахрүз*, син ашыгыб булма хараб,
Кәләш алсаң, ала күр нәсленә карап.

Фәйзуллаһ, син сөймә кызның наданын,
Хәрам итмә ул нәҗесә син малың».

Бу кисәтү, табигый рәвештә, хатын-кызларга да кагыла: автор аларны надан һәм намазсыз (бинамаз) кешегә кияүгә барып, үз-үзләрен харап итмәскә чакыра, гыйлемле егеткә, шәкерткә барыгыз, шулвакытта гына ике дөнья бәхетенә ирешерсез, ди:
«*Бибигалимә*, гыйлем кыз, галим улсын хәләлең,
Дөнья-ахирәт рәхәт улыр, чөнки синең хәлләрең.

Бибихәлимә, хәлеңне һичберәве белмәсен,
Галим улса гәрчә ярың, гүр газабын күрмәссең.

Бибиҗан, син үз җаныңны җәфаларга салмагыл,
Бинамазга бикәч булып, мәңге мәхрүм калмагыл».

Гомумән, рисаләнең хатын-кыз исемнәренә багышланган өлеше аеруча җанлы һәм төсләргә бай. Монда автор, үгет-нәсыйхәт тонын тагын да көчәйтеп, хатыннарда Аллаһтан һәм... ирләреннән курку хисен тәрбияләүне максат итеп куя, «ирен санлаган – Аллаһны санлар, Аллаһны санлаган – ирне санлар» принцибын алга сөрә:

«*Хөсниҗиһан*, киче-көндез тәгать иткел Тәңрегә,
Җан-тән илән тәслим улгыл һәм иреңнең әмренә».

«Ир сүзен тотыңыз», «ир сүзеннән чыкмагыз», «ир ризалыгын алып яшәгез» фикере төрле тормыш-көнкүреш очраклары белән бәйләнештә даими тәкрарлана:

«*Сиддыйка*, бирсәң сәдака, белсен аны һәм ирең,
Разый улса гәрчә ирең, оҗмах улыр һәм гүрең.

Бибиҗәмал, бик гүзәлсең, дәхи татлы сүзләрең,
Һәрдаим ирең каршында ачык булсын йөзләрең».

Ир-атларга эндәшкән вакытта **дускай**, **туганкай**, **шәрик**, **агай**, **абзый**, **абый**, хәтта **бабай** дип эндәшкән автор, хатын-кызларга **түтәй**, **абыстай**, **сеңлем**, **туташ**, **җиңгәчи** дип мөрәҗәгать итә. Татар хатын-кызларының кайбер сәер гадәтләрен «ачып сала торган» юлларны укыганда, укучы елмаймый түзә алмый. Мәсәлән:

«*Бибикамилә* абыстай, алма кебек йөзләрең,
Салма бүлмә ярыгыннан ят кешегә күзләрең», –

юллар халык җыры белән аваздаш. («*Ак эшләпә мамыктан*, кызлар карый ярыктан, карамас иде ярыктан, *бер күрергә* зарыккан»). Муса Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» (1886) әсәрендәге мәгърифәтле кыз Хәнифәнең дә егетне беренче тапкыр бүлмә ярыгыннан күзәтүен искә төшерик. Нишләтәсең, ул заманнарда хатын-кызның күпчелек вакыты «кече як»та, өйнең хатын-кыз өлешендә узган, килгән ят кешеләрне алар бүрәнә яки такта ярыгыннан күзәткән, чаршау артыннан тыңлаган. Гомумән, рисаләдә татар хатын-кызларының холыклары төрлечә ачыла, барысы да чибәр һәм тырыш, аз сүзле һәм күп эшле түгел, кайберләре мактанчык:

«*Сәхибкамал*, җәйгә чыксаң, җәй келәткә урыныңны,
Никадәр булсаң да күркәм, бик күтәрмә борыныңны».

Кайберләре – гайбәтче:

«*Мәгърифә*, син макта һәрдаим үз иреңнең эшләрен,
Гәрчә сатсаң гайбәтне, коелыр азау тешләрең».

Икенчеләре – җилбәзәк:

«*Миңсылу*, әйт күб салават, дәхи әйткел күб зикер,
Кызлыгыңның кад(е)рен бел, тотмагыйл төрле фикер».

Гомумән, автор фикеренчә, сүз тыңлаучан, уңган һәм диндар хатын – Аллаһның ир-атларга биргән иң бөек нигъмәте:

«*Зәйнәп*, укыгыл намазыңны, фарыз эштер һәм савап,
Көлеп ачык йөзләр илән кияүеңә бир җавап.

Бибихәмидә, ушандак самауар куй, пич ягып,
Кичкә керсәң, киявеңне йоклат аркасын кагыб».

(Кияү дип автор бу очракта, әлбәттә, ирне атый.)

Ә менә явыз холыклы хатын – тәмуг-җәһәннәм хәбәрчеседер:

«*Гәнбәр* абыстай, гыйбрәт алсаң, дөньяда күптер мисал,

Иренә тәмуг чаткысыдыр, булса хатыннар усал».

Нәсыйхәтче автор хатын-кызларның киенү-төзәнү эшләренә катышып, акыл сату форсатын, әлбәттә, ычкындырмый:

«*Таибә түтәй*, йөзеңне капла яулыгың илән,
Йортта йөргән заманыңда башыңа җабып җилән».

Бигрәк тә он-камыр эшләре белән шөгыльләнгәндә, хатын-кызның чәче-башы капланган булырга тиеш:

«*Зөлхая*, һәм хәя кыйлгыл, кычкырыб сөйләмәгел,
Аллаһтан курыксаң, яланбаш дәхи он иләмәгел».

Моннан башка тагын кияүдәге хатынга килешми торган гадәтләрдән: *Зарифа түтәй, җиңеңне сызганма бик югары; Заһирә туташ, ... башыңа бәйләми ятма, йокласаң мелла белән; Минневафа, ...кукерәксез йөремә, Мәгълифә, яланаяк йөремә* һ.б.лар.

Бизәнү-төзәнү мәсьәләсендә автор *«Заһидә, дәхи үзеңне ирең өчен бизәгел»,* дисә дә, йөзгә кершән салу һәм сөрмә тартуларны, төрле буяуларны куллануны, нигездә, кабул итми, хәрәм эш дип атый:

«*Шәмсекамәр*, син матур кыз, кызган үзеңне-үзең,
Салма намәхрәм йөзеңә, һич вакыт ике күзең».
(намәхрәм – хәрәм, шәригать тыйган)

Шулай ук каш төзәтү, маңгай чәчен салындыру да кызларга килешә торган эш түгел, ди автор:

«*Габидә*, һәм гаиб эшдер, зинһар, алдырма кашың,
Кабих эшдер маңгаеңдан һәм салындырма сачең».

Хатын-кыз өчен асыл матурлыкның ана булуын әйтеп, «кичке кәсеп» кебек темаларга да даими басым ясап тора ул:

«*Газизә*, син сәламәт бул һәм яшең булсын озын,
Кичке кәсебне күб итсәң, чук булыр угыл-кызың».

Татар хатын-кызларына мөрәҗәгать итеп, автор шул заман авыл өендәге кече якка – хатын-кыз бүлегенә, ягъни хәзерге тел белән әйткәндә, кухняга – аш өенә дә алып керә, анда исә коймак, бәлеш, камыр ашлары пешә:

«*Мәргубә*, кыйл гыйбадәтне, фарыз эшләрне төшер,
Иртә торсаң, самавар куй дәхи дә коймак пешер.

Мәфтуха, һәм зифа буең, дәхи кара кашларың,
Камырыңны каты баскыл, татлы булыр ашларың».

Гөбедә атланмай ясала:

«*Зөбәрҗәт*, син укыган кыз, кайгы тотма һәрдаим,
Ул иреңә ашаткыл, гөбе атласаң маең».

Зур табага салып, бәлеш пешерү – һәркемнең дә кулыннан килә торган эш түгел, чөнки бәлешнең тишелеп ага торган ямьсез «гадәте» бар:

«*Шәмсениса*, бәлеш яса һәм төбе тишелмәсен,
Тиешсез сүзләр әйтмә иреңә, маңгаеңа бирмәсен».

Хуҗабикәнең вак, әмма әһәмиятле вазыйфаларыннан берсе – иренең юыну һәм тәһарәт алуы өчен комганда даими җылы су булдыру:

«*Бәдерниса*, син ушандак йокламагыл утырыб,
Җылы суларны хәзерләп, комганың куй тутырыб».

Һәм, әлбәттә, ул юынганда су салып тору, сөлгене әзер тоту:

«*Сәйдә*, син һәм иреңнең каршысында сөлге тот,
Гәрчә курыксаң тәмугдан, каршы әйтүдән телең тот».
Ирнең өс-башын чиста тоту да хатынның уңганлык билгеседер:
«*Өммеҗәмилә*, җәннәт эстәб тот Ходайның кушканын,
Кара тотма син иреңнең дәхи күлмәк-ыштанын.

Бәдигыльҗәмал, һәр эшеңдә көтмә ирең кушканын,
Ике көндә бер алыштыр дәхи күлмәк-ыштанын».

Хатынның иренә күрсәтергә тиеш җылы мөнәсәбәтенең кайбер детальләре итеп, автор боларны саный: *Мәрхәбә* дини мәҗлескә барганда да, иренең рөхсәтен алып барырга тиеш; *Мәрфуга* ирен ныграк сыйлап, күңелен яуларга; *Мәфлиха* иренә кычкырмаска; *Махитаб* икмәк валчыкларын таптаудан сакланырга; Мөҗидә юлдан кайткан ирен чыгып каршы алырга тиеш һ.б.лар. Хатын үз вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгәндә, ир ягыннан ору-сугу – кыйнау кебек хәрәкәтләрне язучы бик табигый саный:
«*Шәмсеруй*, син тыңла сүзне, руза тот, укы намаз,
Шәригатьчә булса эшең, бер дә ирең кыйнамас.

Зөбәйдә, син зиннәт иткел үзеңә баштанаяк,
Иллә сокландырма ятны, төшмәсен башыңа таяк.

Заһидә, дәхи үзеңне ирең өчен бизәгел,
Гайбеңне сизсә ирең, кыйнаб, өзәр үзәгең».

Хатын-кызларның ирләре тарафыннан кыйналуы мәсьәләсендә автор, күргәнебезчә, патриархаль фикердә тора һәм иргә буйсынуны шәригать кушуы дип аңлата. Ир кеше хатынының тезгенен «таза тотарга тиеш» дигән караштa тора:
«*Бибиәсма*, син ушандак барча кызлар күркесе,
Нә теләсә, ирке бардыр хатынына ир кеше.

Бибирәхилә, бу сүздән син дә алгыл гыйбрәт,
Тезгенеңне таза тотар, ирдә булса гайрәт».

Бүгенге көндә гаҗәп тоелырдай, ә ул заманнарда бер хорафат яки гореф-гадәт булган тәртипләрдән берсе – ир белән хатынның бер-берсенә исем белән дәшмәве текстта болай бирелә:
«*Бибихәдичә* җиңгәчи, куймагыл намазыңы,
Һәм ирeңне аты берлән өндәмә: күб языгы».

Шулай итеп, ир һәм хатыннарга исемнәре белән дәшеп, яшәү-көнкүреш өлкәсендә үгет-сабак бирү максатында язылган «Вәгазьнамә рисаләсе» исемле әсәр XX йөз башы татар гаиләсе һәм җәмгыяте белән бәйле кызыклы гына тасвирлар авторның шәхси фикер сөрешенең үзенчәлекле чагылышын, шул чорның тел-сөйләм культурасы үрнәкләрен тәшкил итүе белән кыйммәтле. Әсәрнең өч йөздән артык татар-мөселман кеше исемнәре тупланмасыннан торуы аеруча ономастика фәне өчен бай бер чыганак булып хезмәт итәр, дигән фикердә калабыз. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2017

ҖАНЛЫ БАЙЛЫК

Эльмира Шәрифуллина

1977 елда «Казан утлары» журналының 6 нчы санында «Илебез – кадерле җиребез» дигән мәкаләм басылып чыккач, Фазыл һәм Кәбир Туйкиннарның туганнары, балалары: «Сез безгә канатлар куйдыгыз, хәзер без, шушы журналны кочаклап, турырак басып йөри башладык», – дигән фикер белдерде. Бу рәхмәтләр, билгеле, мине дә канатландырды. Һәм мин, Ф.Туйкинның гарәп имлясыннан кирилицага күчереп чыккан әсәрләрен (мәкаләләрен дә) бербөтен итеп туплап, китабын чыгару уе белән яши башладым. Ләкин, ни Туйкиннар, ни мин иганәче таба алмадык. Татарстан китап нәшриятында «Әдәби мирас, Альманах» томлыклары чыга башлагач, коллектив җыентыкларда булса да дөнья күрә торсыннар, дип, кульязмаларымны китапны төзүче-редакторга илтеп бирдем. «Әдәби мирас, Альманах»ның 1991 елда чыккан санында, минем кереш сүз белән, Ф.Туйкинның ике әсәре – «Ватан каһарманнары» пьесасы һәм «Сугышчы Сатыш әфәнде» исемле хикәясе басылды.

Инде килеп, Туйкиннар нәселеннән үсеп чыгып ныгыган бүгенге буын, 2014 елда, үзләре оештырган «Тамырлар» фонды утырышына чакыргач, җанланып китеп, Фазыл әфәндегә тагын әйләнеп кайттым. Дөресен генә әйткәндә, ифрат та эшчән, тынгысыз җанлы, балаларны чын ярату белән яратып мөгаллимлек итүче – тәрбия кылучы, педагог, галим, фольклорчы, драматург, шагыйрь, язучы, журналист Фазыл Туйкә (Фазыл Кәрим улы Туйкин) – студент чагымнан ук, үтә дә кадерле бер шәхес булып, күңелемә кереп урнашкан иде инде. Соң шулай булмый, аңлы һәм күзгә күренмәгән җепләр белән дә араларны 50 ел вакыт бәйләп тора икән бит. Мәкаләләремдә бәян ителгәнчә, 1967 елда ук мин аның сәнәкчеләр турындагы «Соңгы каракош» дип исеме һәм авторы үзгәртелгән пьесасында мөгаллимә ролен башкарганмын. Ә инде университетка укырга кергәч, Туйкин турында бер кәлимә мәгълүматым булмаган килеш, аның иҗат эшчәнлеген өйрәнүне диплом эше итеп алганмын. Йә, язмышыма Аллаһы юнәлеше димичә, ни дисең?! Гүя, киләчәктә үз башыма төшәчәк гөрзиләр сугышының ниндилеген күрә, гыйбрәтләнә торыр өчен әзерлек еллары үткәнмен...

***

Каюм Насыйри әйтмешли, «милләте өчен күпме тырышса, шулкадәр җәфа күргән» Фазыл Туйкинның язган-эшләгәннәрен дөньяга чыгара алмыйча газапланулары, шуларны халыкка җиткерү җәһәтеннән өзгәләнеп, партия һәм мәгариф эшлеклеләренә, тел һәм әдәбият галимнәренә, фольклорчыларга, халык әдәбиятын җыйнау өчен төзелгән комиссиягә һәм башлыгына да язган хатлары, әсәрләренең хәбәрсез югалулары, зур гаиләсен туйдыру өчен шул хезмәтләренең әҗерен ала алмыйча интегүләре, нәселенә килгән авырдан-авыр фаҗигаләр – уйлаган кешегә, тере тәнең дөрләп янарлык!

«Ялгыз бер дуадак булсам, һичбер Сезне йөдәтмәс идем. Мин шул бер карчыкның баласы, бер хатынның ире һәм биш баланың атасы булганмын. Аларны тәэмин итәргә юл тапмый торып, ВПИга китеп булмый. Шунлыктан, мин урында әзерләнеп имтихан тотарга сораган идем...» – дип яза ул Татарстан мәгариф хезмәткәре Нургали Надиевка.

Бу шәхеснең аянычлы тормышын чак кына булса да күзаллау өчен, тагын берничә хаттан өзек укыйк: *«Минә хәзер безнең кулда 350 чамасы атама җыелды. Шуларның гербарийлары да өлгерә. Менә шул материаллар милли мәркәзгә кирәк булырмы? Кирәк булса, ул аны нинди шарт белән ала алыр? /.../ Безнең шарт ике генә. Беренчесе – хезмәт хакы алу. Атамалар җыю, аның үләннәрен табып гербарий төзү бик кыйммәткә төште. Ул хезмәтләргә тулысы белән хак түләү бик авыр булыр, аны сорамыйбыз да. Алай да гербарий башына берәр сум бирерсез дип чамалыйбыз. Икенче шартыбыз: безнең материаллар матбугатка чыгарылса, йә башка гыйльми юлга кертеп эшләтелсә, безнең хезмәт булуы яшереп калдырылмасын иде...»*

«/.../ Дөрес, сезнең миннән урлаганыгыз юк. Алай да Казан егетләре мине байтак ачындырды инде. «Балалар сәхнәсе» дигән бер җыентыгым, басылырга карар бирелгәч, гыйльми үзәкнең тел-әдәбият һәйәтенә бирелеп, аны файдаландырды. «Озын көйләргә халык әдәбияты» дигән әсәрем, басылырга карар бирелгәч, башы белән югалды. Билгеле, ул җәүһәр берәр тәтәй егетне кызыктыргандыр...»

«/.../ Ленинградтагы Фәннәр академиясенең «Шәрыкны өйрәнү һәм тикшерү бүлеге» бар... Тюркологлар өчен меңнәр белән акчалар, озын гомерләр түгеп тә ача алмаган бик күп мәсьәләләргә монда (Ф.Туйкинның унбиш ел дәвамында язган «Халык әдәбияты» исемле дүрт табаклык гыйльми хезмәтендә. – **Э.Ш.***) җаваплар бардыр. Сез шул хакта Фәннәр академиясе белән сөйләшә алмассызмы икән?..»*

Безгә мәгълүм булган бик аз хатлардан аерым юллар бу. Шулай итеп, гыйльми-әдәби эшләрдә бөгелеп хезмәт итәргә билен буган Бөгелмә тел-әдәбият укытучысы Фазыл Туйкинның ихласлык белән бирелеп эшләгән кыйммәтле хезмәтләре, шуларны халыкка җиткерү өчен түккән көче, ачыргаланып та, үтенеп тә язган хатлары – стенага бәргән борчактай, беркемдә бернинди теләктәшлек тапмыйча, йөрәгенә кара кан булып сава килгән...

Кыскасы, бу искиткеч авыр, сикәлтәле тормыш юлы үткән шәхес буенча эшләгән эшләремнең һич югы нәни бер өлешен дөньяга чыгарыйм, дип, 2016 елның изге Рамазан аенда шушы язмамны төгәлләдем. Кайбер көннәрнең 35 градуска җиткән эсселеге дә, уразаның бер-бер көненең тәүлеккә чак кына тулмаган озынлыгы да кыенлык тудырмады. Киресенчә, изге айда – изге эш санап, дәртләнеп эшләдем.

Инде килеп, җырлар турында берничә сүз.

Фазыл Туйкинның «Җырлар әхтәрисе» һәм «Нардуган» китапларының өчтән бере чамасын, студент елларымда ук, кириллицага күчергән булганмын. Хәзер исә тулысынча эшләп чыктым. 2017 елның 10 июнендә Фазыл бабабызның тууына 130 ел тулуын истә тотып, китап итеп төзедем. Алдыма бернинди дә гыйльми максатлар куймадым. Теләгем бер генә – бу олы хезмәт, Ф.Туйкин җыйган халык җырлары – тулысы белән кабаттан да халыкның үзенә барып ирешсен иде!

Укучыда нindидер сорау туа калса, алдан ук искәрмә биреп китим. Башта мин «Җырлар әхтәрисе»нең 1912 елда чыккан басмасы белән эшләгәнмен. Хәзер кулымда 1918 елда басылганы. Аның, кабат (китапханәдә) төпләнгәндә 44, 45, 46, 47, 48, 49, 50 нче битләре буталганлыктан, янәдән дә 1912 елда чыккан вариантка мөрәҗәгать итәргә туры килде. Алты ел аерма белән чыккан бу ике китапка, камилләшү җәһәтеннән, төзәтүләр дә кертелгән. Күрәсең, төзүче-автор аны кабат карап чыккан, редакцияләгән. Яки шул ук җырның яңа вариантларын тапкан булуы да ихтимал. Мәсәлән, 1912 елдагы җыентыкта:

«Алтын-көмеш Азиядә,
Матур кызлар Русиядә;
Русиядәге матур кызлар
Бакчада да дачада», – диелә.

Ә 1918 елда чыкканында:

«Алтын-көмеш әсәйдә,
Матур кызлар Рәсәйдә;
Рәсәйдәге матур кызлар
Бакчада да дачада», – дип басылган.

Ф.Туйкин халык җырларын «җанлы байлык» дип атый, аның халыкчан яңгырашын саклап, ничек җырланса, шулай яза. Ихтимал, аларның кайберләрендә, кайсы төбәктән җыелуына карап, шул якның җирле сөйләме дә саклангандыр: Ак Идел, ак калпак, алтын сач, ап-ак, керпек, җөгән, җурган, җегет, шалтыр-шылтыр (су агышы), богдай, берлән, атадин, синдин һ.б.

Тагын, «куштан» сүзенең шактый күп кулланылуы да игътибарны җәлеп итте. Гадәттә, кире сыйфатка ия: булган, ялагай, хуҗаларга тәлинкә тотучыларга карата гаепләп әйтелә торган бу сүз кайбер җырларда кирәкле гадәт буларак аңлашыла:

«Абзый, безгә ат кирәк,
Йә йөгерек, йә җурга;
Сөйгән ярлар булсын иде
Йә бик куштан, йә мулла».

Татарстан китап нәшриятында «Татар халык иҗаты» томлыкларының 1976 елда чыккан «Кыска җырлар (дүртьюллыклар) җыентыгына Фазыл Туйкинның да байтак җырлары алынган. Китапның ахырында бирелгән «Чыганаклар» дигән бүлешмәдә: «Фазыл Туйкин. «Җырлар әхтәрисе». Казан, 1912», – дип куелган.

Татар халык лирикасын җыю, өйрәнү өлкәсендә күп хезмәт куйган Ф.Туйкинның бу җыентыгында озын һәм кыска үлчәмле мең дә бер йөз җыр тупланган. Үз көйләре булган утыз бер җырдан һәм кушымталардан үрнәкләр дә бирелгән. Дүртьюллы җырлар, темаларга бүленмичә, алфавит тәртибендә урнаштырылганнар. Көнкүреш һәм мәхәббәт җырларының күркәм мисаллары төп мәйданны били. Төзүче җыр текстларының халыкчан яңгырашына ихтирам белән карап эш иткән. Җыентык үзгәртүсез-нисез 1914, 1918 елларда кабат басылып чыга. «Бу томга шуннан ике йөз егерме дүрт җыр сайланды», – дигән мәгълүмат бирелә.

Томлыкны төзүче, кабатлап бастырганда җырлар үзгәреш кичермәгән, дигән фикерне әйтсә дә, беркадәр аерма бар. Йогаклап әйткәндә, «Татар халык иҗаты»ның унике томлыгы кебек дәрәҗәле басмада, бу юлда җанын ярып бирердәй булып хезмәт куйган Фазыл Туйкинның да лаеклы урын алуы – күңелле хәл!

Безнең мирас №12 декабрь 2017

Фазыл Туйкә туплаган җырлар (1887-1938)

* * *

(«Баламишкин» көенә)

Ашказар суы буенда бер матур булган, диләр,
Үзе сөйгән бер егеттә кияүдә, дип сөйлиләр,
Беркөн кияү киткән, имеш, су буена сунарга,
Кыз көтсә дә, кайтмаган, ди, киткән көнне кунарга.

Иртә берлән кыз киенеп эзли киткән сөйгәнен,
Эзе берлән эзли торгач, белгән батып үлгәнен.
Шулчакта ул, сөйгәнем, дип, әрнеп елаган, диләр,
Шунда бу бик моңлы көйне шул кыз җырлаган, диләр.

* * *

(«Тәфтиләү» көенә)

Кара ла елан, ай, туз башлы,
Йөзәдер дә камышлар буенча,
Арысландай гына ир-егетләр
Йөриләр дә язмышлар буенча.

Биек тә тауның башларында
Ак куяннар бураннар туздыра,
Карчыга кебек булгыр яшьләр
Гомерләрен заяга уздыра.

Алдырмас та киек, һай, алдырмас,
Алларында кыялар дәү булса,
Кайгырмас та егет, юк, кайгырмас,
Газиз башкайлары ла сау булса.

Яндырган да шәмнәр, һай, сүнәрме,
Җыр җырлаган егетләр юләрме,
Җырлар җырлап күңел ачылмагач,
Моңлы кеше егылып үләрме?

* * *

Бу дөньяның ачы зәһәрләрен учлап бирәү йотса,
Явыз дөнья каты тырнаклары белән аны тотса,
Йөрәге әрнешеп, утлар кабып, үз урыныннан купса,—
Менә шул булыр чын кеше, бәгърем, кирәк булса. ■

МӨГАЛЛИМ МӨНБӘРЕ

Безнең мирас №12 декабрь 2017

Керәшен татарларының туй йолалары

Егет белән кыз үзара сөйләшеп, өйләнешергә килешкәч, егетнең әти-әнисе һәм тагын өч кеше (1 хатын-кыз, 2 ир-ат – егет ягыннан туган булырга тиешле кешеләр) кыз өенә бара.

Алар: «Без даулап та, яулап та түгел, килешеп-сөйләшергә, егет белән кызны бер гаилә итәр өчен килдек», – дигән белдерү ясый.

Башына түгәрәк яулык бөркәнгән яшь килен. Мишә буе төркеме

«Очраштыгыз, уйнаштыгыз, уйлаштыгыз, инде тормыш корыгыз», – ди арадан берсе. Җырлап та әйтәләр:

«Карт имәннең каерысын
Каерырга килдек без.
Әткәсеннән-әнкәсеннән
Аерырга килдек без».

Кызны сорарга барганда бербөтен ипине, тозны ашъяулыкка төреп алып баралар. Кыз алышырга килгән хатын:

«Әйдә, кодагый, күлмәк тегик,
Икебез пар яшелдән.
Киленебезне теләп алабыз
Үзебез белгән нәселдән», –

[1] Мәкаләгә фоторәсемнәр Р.Г.Мөхәммәдованың «Керәшен татарлары киеме» дигән китабыннан (Казан: «Сүз», 2015) алынды.

дип җыр башлый. Кара-каршы җырлашу китә. Бераз өстәл артында утырганнан соң, егет ягы, кызны алып, өенә кайтып китә. Егет өенә кайткач, аның әти-әнисе киленне каршы чыгып ала. Киленнең аяк астына тун җәяләр һәм яңа бөтен ипине башлап, аның кибән башына май ягып, егет белән кызга бүлеп каптыралар. Егетнең әнисе киленгә шундый сүзләр әйтә: «Төкле аягың, йолдызың, армас йөрәгең, талмас беләгең, тәмле-татлы телең белән кил».

Егетнең ата-анасы туйга хәтле кыз йортына кода көйләргә бара, ягъни туйны үткәрү чаралары турында үзара киңәшеп сөйләшәләр (туй кайчан була, ничә пар кунак чакырырга, ашлымы-ашсызмы, бүләклеме-бүләксезме һ.б.). Туй башлыгын билгелиләр. Туй башлыгы аргыш дип атала, ә кияү егете туй йөртүче була. Туйның аргышы һәм кияү егете ике яктан да билгеләнергә тиеш.

Менә туй көне килеп җитә. Егет белән кыз бу көнне язылыша. Кияү һәм кәләш белән аларның дуслары, туганнары бара. Кайткач, өстәл артына утыралар. Яшьләр өстәл артында өлкәннәр килгәнче генә утырырга тиеш, аннан соң алар таралыша.

Туй алырга аргышның кияве һәм кияү егете юл тота. Авылда булса, атка кыңгырау тагып, килен чиккән сөлгене элеп, җырлап баралар. Кыз өендә аның ягыннан туйга барасы барлык кунаклар да җыйналышып көтеп тора. Шуннан соң атларга яки машиналарга төялешеп, туй буласы йортка китәләр.

Туй йортына барып җиткәч, егет ягы туй кунакларын җырлап каршылый:

«Алтыннардан басмалар, әй, салганчы,
Көмешләрдән күпер салабыз,
Сезнең киләселәрне белеп,
Каршылар чыгып алабыз».

Кыз ягы:

«Каршы бакчаларда – куш умарта,
Куш умарта эчендә – кортлары.
Алтыннан – багана, көмештән – капка,
Шушы микән кодалар йортлары.

Кара урманнарга барып керсәм,
Урман каравылчысы йорты икән.
Боярлар йорты, дип торам,
Кодалар йорты икән.

Су буенда була микән ак мунчалар,
Ат бәйләргә булыр микән култыксалар.
Бер-ике кич кунар идек,
Безне монда кундырсалар.

Агыйделләргә басма салдым
Су астыннан чыккан таш белән.
Безне кодалар көтеп торган
Пешкән аш һәм олыгайган баш белән».

Шуннан соң түшәк сатулашу башлана:

«Сатулашу, тартышулар –
Сатучының хәйләсе.
Сорочида, билгеле инде,
Мең сум тора бәясе.

Әфлисун, әфлисун,
Әфлисун тәмле лә соң;
Әфлисуннар тәмле дә соң,
Түшәкнең бәясе төп-төгәл биш йөз сум».

Бу күренеш беткәч, аргыш түшәкне кияүгә бирә һәм матур сүзләр әйтә: «Икәү ятыгыз, өчәү торыгыз, башыгыз авыртмасын, саныгыз сызламасын, тигез гомер итегез, матур яшәгез, санлашып торыгыз».

Моннан соң, өстәл янына утырту башлана. Кыз ягыннан килгән кунакларны аргыш үзе утырта. Егет ягындагылар сыйлый башлый. Сөйләшү, көлешү... Әйтәсе сүзләр әйтелә, тост тотыла. Егет ягындагылар җыр башлый:

«Ничектәй килдегез сез безгә,
Батмыенча Кара диңгезгә;
Кадерле кодалар сез безгә,
Ни сый-хөрмәт бирим мин сезгә.

Күк күгәрченнәр мин очырдым,
Ындыр табакайларына төшердем.
Инде, шөкер, берләр Ходайга –
Сез кодаларны кулга төшердем.

Өстәл өсләрендә, әй, ашъяулык,
Ашъяулык өстендә ашамлык;
Ашагыз-эчегез, кодаларым,
Сезнең өчен пешергән ашамлык.

Кара урманнарның уртасында
Карамалар булды бөккәнем.
Иртәдән алып кичкә кадәр
Сез булдыгыз минем көткәнем».

Кыз ягы җырлый:

«Айлар килдек без, айлар килдек без,
Агыйделләр кичеп килдек без.
Агыйдел кичеп, суын эчеп,
Бер күрешер өчен килдек без.

Сезләргә килдек без кунакка
Ак самавыр белән чәй эчтек.
Инде, шөкер, берләр Ходайга –
Сез кодалар белән күрештек.

Кырларга чыксам,
мылтыккайлар алам,
Урман киекләре атарга.
Өстәл тулы тәмле ризык,
Белмибез, кодагый, кайсын ашарга».
(Кара-каршы җырлау дәвам итә.)

Шуннан соң, табынга аш чыга башлый. Аны җырлап чыгаралар:

«Салкын чишмәләрнең төпләреннән
Җыеп кына алдым вак таш,
Сез кодалар килеп кергәч,
Пешереп үк алдым кайнар аш.

Күкти сыерларның сөтен саудым,
Казаннарда калач басарга,
Безгә Ходай шулай язсын –
Бергә-бергә ризык ашарга.

Алабуга төркеме хатыннары кием комплексы

Ике лә басу бергә булса,
Атарбыз киеккәйләр бар булса;
Гомергә шушылай бергә йөрешербез,
Аллакай безгә әгәр боерса».

Килгән кунаклар аш бирүчеләргә җырлап чәркә бирә:

«Болан бияләйгә караганда,
Күн ди бияләйләр катырак;
Бу чәркәләрне сез эчәсез,
Ашияләре белән булса татлырак.

Чын ди чынаяклар мин алдырдым
Яңа гына Кытай йортыннан,
Атлы килеп, җәяү китмә,
Эчеп җибәрерсең бер тыннан.

Юл ди буйлары ай имәнлек,
Имәнлекәйләрдә уңа игенлек.
Алдагы көннәрне Алла белсен,
Бүгенге көннәребез иминлек».

Әгәр туй ашлы булса, кыз ягыннан килгән ашны да җырлап чыгаралар:

«Безнең өсталләргә шул килешә,
Челтәрләп үк суккан ашъяулык.
Кем ашы, дип, сез сорасагыз?
Әтекәй белән әнекәйдән
калган ди ашамлык.

Сары атларыңны садка җибәр,
Бар бит сезнең сәйфан садыгыз.
Ара ерак, юл пычырак,
Авыр тартып килде атыбыз».

Җырны кодалар дәвам итә. Егет ягы җырлый:

«Бер ди кулларында, әй, ал ди яулык,
Бер ди кулларында гөл яулык.
Бик зур дәүләтләр белән кодалар килә,
Каршы алыйк, аякка басып».

Кыз ягы җырлый:

«Биеккәй тауның башларында
Бодайлар коеладыр бер җиткәч,
Кыз балалар бик җәл дә бит,
Тотып кына булмый бер җиткәч».

Бергәләп җырлыйлар:

«Урманнарга барсам, күкеләр атам,
Урман күкеләренең күклесен.
Безнең теләгәннәр безгә булды,
Безне теләгәннәр үкенсен».

Бәлеш чыгарганда да кара-каршы җырлаулар дәвам итә:

«Бәлешләр ясадым миннәр чүгәләп,
Әй, бәлешләрем лә булган, әй, тәбәнәк;
Әй, бәлешләрем лә булган, әй, тәбәнәк,
Ә ясаучылары аның, әй, ябалак.

Биек тауның башларында
Солы кибәннәре кем куйган,
Ашыйк-эчик без, кодалар,
Ашау-эчүләрдән кем туйган?!»

Бәлешләрне урнаштырып бетергәч, кыз ягы тиз генә барысына да чәркә тоттыра һәм җырлый:

«Агыйделдән пароход килә,
Алдагысында дөге лә ярмасы;
Алдагысында дөге лә ярмасы,
Пешерүчеләре шәһәр алмасы.

Төнге тынлык эчләрендә,
Шыгырдыйдыр байларның капкасы.
Килгән кодачаларның ашыйсы килгән,
Ачасызмы бәлешнең капкачын?

Пелис чалбар без кимибез,
Без киябез атласын;
Йөз сум булсын, мең сум булсын,
Сез ачасыз бәлешнең капкачын».

Аргышка, кияү егетенең чәркәләренә бүләккә яулык ябалар, бәлешләрне ачкач, ашларын мактап җыр җырлыйлар:

«Өсләрегездәге киемегез
Буй-буй киткән яшеле,
Кашыгыз кара, буегыз зифа,
Сез кайсы пәйгамбәрләрнең нәселе».

Сыйлашу-җырлашу шулай дәвам итә. Каз чыгару булса, мондый җырлар:

«Кода кеше бик зур кеше,
Зур эшләрне башкара.
Кода, тешләрең бармы соң
Казның башын ашарга?

Кодагыйның яшь чагында,
Җылы булган куены.
Башны муен йөртә, диләр,
Кодагыйга муены.

Син бит минем туган түгел,
Син – кода кеше генә.
Кода, сиңа кисеп бирәм,
Казымның түшен генә.

Йөгерә-йөгерә уйнап йөри,
Кара сарык бәтие.
Йөгерә-йөгерә эшләр өчен,
Киленемә тәпие.

Тәлинкәгә турамыймын
Казымның бөтен санын,
Ике боты кияү белән
Кызга тиеш бит аның.

Биек тауның башларыннан
Төшеп килә буш арба,
Ә канаты кыз балага
Бу йортлардан очарга.

Бөтен казны өлешләргә
Син бераз үзең чамала,
Инде хәзер тигез итеп
Тура кодачаларга».

Җырлашып, кара-каршы сыйлашкач, бераз биеп, ял итеп алына. Кунаклар яңадан өстәл артына утыра. Тау итү (сый өчен хөрмәтләү) башлана:

«Туп-туп баскан туры атның
Тояк эзгенәен ком баса.
Бу илләргә ничек килер идек,
Сез кодаларыбыз булмаса?

Биеккәй тауларның, әй, башында,
Ширбәт сиптем очкан кошларга.
Ашадык та без, эчтек тә, хөрмәт күрдек,
Дәүләт яусын шушы йортларга.

Алтыннардан бура бураттым,
Эчләрендә ашлык бетмәскә.
Без, кодалар, сезгә шуны телибез –
Башыгыздан дәүләт китмәскә.

Мич башыннан егылуның
Бар бит аның чарасы.
Кайту өчен курыкма син,
Үзебездә чамасы.

Сафьян итекләр алдырдым,
Аякларыма сыймагач.
Сезгә күңелләребез булды инде,
Ихлас күңел белән сыйлагач.

Ак мунча алачыгында
Яшь килен талкан талкый,

Бу эскиз Казан арты Мишә буе керәшеннәренең традицион киемнәренә нигезләнеп эшләнде

Кодалар, гаеп итмәгез.
Җиккән атыбыз заркый».

Шуннан кунакларны озата чыгалар, киенү, җырлашу һәм озату башлана:

«Башыңа кигән сүрәкәңне
Сары укалар белән йөзләрбез.
Сездә күргән сый-хөрмәтне
Сагынып-сагынып сөйләрбез».

Шулай итеп кунаклар таралыша. Туй тәмамлана.

Бу туй йоласы Питрәч районының Кибәч авылында үткәрелгән туйлардан тупланган. Мәкалә 40 елдан артык татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләгән һәм бик күп туйларда аргыш булып йөргән әнием Пелагея Борисовна Курицына сөйләгәннәрдән һәм үзем күргәннәрдән чыгып язылды.

Галина Золина,
Казандагы 15 нче урта мәктәпнең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы. ■

ТЕЛ МӘСЬӘЛӘСЕ

Галиҗан Тирешкави

*Хәзерге көндәге вакытлы матбугатта, социаль челтәрләрдә телне укыту турында бәхәс куерган кебек, XX йөз башында да төрки һәм татар телләренең төрле проблемаларына нисбәтле фикер алышулар барган. Шуларның берсен 1912 елгы «Шура» журналының 24 нче санында, мөгаен, баш мөхәррир Ризаэддин Фәхреддиндер: «Русия вә Иран, Төркия вә Чин (Кытай) дәүләтләрендә төрекләрне 60-70 миллион дип чамалыйлар. Ошбу кыйтгаларда мәгыйшәт кылучы төрекләр өчен уртак телгә хаҗәт бармы, булса, моны мәйданга чыгаруның юллары ничек?» – дигән сорау белән кузгатып җибәрә. Шунысы игътибарга лаек, күп авторлар (Г.Исхакый, Н.Яушев, Җ.Вәлиди һ.б.), Исмәгыйль Гаспралының «Телдә, фикердә һәм эштә берлек» дигән шигаренә тугры калып булса кирәк, «Шура», «Мәктәп», «Мөгаллим» журналларында һәм газеталарда дөнья күргән мәкаләләрендә гомуми төрек (төрки) теле кирәклеге, аңа ихтыяҗ барлыгы турында яза. Кайберәүләр аны имля, икенчеләр матбугат һәм әдәбият, өченчеләре исә мәктәпләр аша гамәлгә ашырып булачагын исбатлый. «Шура» журналының 1916 елгы 9-10 саннарында басылган, «Төркестан»да яшәүче **Галиҗан Тирешкави** язган мәкаләдә исә аерым җәмгыять төзергә кирәклеге искәртелә.*


مكتب
١٩١٣ نجی سنه ١٣٣١ نجی سنه ربیع الآخر ١٢. مارت ٨
٢ نجی صان. ایكی آطنده ده بر چقا طورغان تعلیم وتربیه ژورنالی. ١ نجی یل.

مندرجات:

گیمنازیه حقنده ... ش. احمروف.
مدرسه‌لریز حقنده ... احمدزكی ولیدی.
اصول تعلیم ... نجیب دوماوی.
تاتار مكتبلرینه اوچیتللر چینشدرو ... عین. ق.
دین مدرسه‌لرنده منطق ... ع. عزیز.
استانبولده باكی مكتبلر ... عبدالرحمن مصطفی.
ابتدائی مكتبلرده اوقولا طورغان فنلر ... محی الدین قربانعلییف.
آولده قزلر مكتبی مسئله‌سی ... جلیل ابوالخان.
مسكاوده بولو مناسبتی ایله ... فخرالاسلام آگییف.
املا-زلق ... محبوب‌جمال آقچورینا.
مكتبلریزنك مالیه جهتی ... محمود فؤاد طوقتارف.
آتالار قولاغینه بر نیچه سوز ... فخرالبنات سلیمانیه.
معلمه‌لریزگه شهادتنامه قایدن آلورغه؟ ... فرخانه فیض‌اللینا.
اوقو ومكتب عالمینه دائر خبرلر ... *

اداره‌خانه‌سی قزانده «صباح» كتبخانه‌سنده
نسخه‌سی ٢٠ تین.

«Мәктәп» журналы, 1913 ел

Мәкаләнең авторы Галиҗан, нисбәсеннән күренгәнчә, хәзерге

«Шура» журналы, 1908 ел


شورا
١٩٠٨ = نومیر ١٢
اورنبورغدا اونبیش کونده بر چقغان
ادبی فنی و سیاسی مجموعه‌در
محرری رضاءالدین بن فخرالدین
ناشرلری م. شاکر م. ذاکر رامیفلر

***Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районындагы Тирешка авылында** туган, дип уйлыйбыз. Кызганыч, әлеге шәхес турында мәгълүматыбыз бик аз: «Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре» (2005) исемле китаптан аның «публицист, мулла» икәнен, «Шура» журналының библиографик күрсәткеченнән (төзүчеләре — М.Госманов, Р.Мәрданов, 2014) бер дистәгә якын мәкаләсе барлыгын гына беләбез.*

Укучыларыбыз мәкаләдәге «төрек» дигән сүзнең кардәш халыкларны (татар, казакъ, үзбәк, уйгыр һ.б.) берләштерә торган «төрки» икәнлегенә төшенерләр, дип уйлыйбыз. Автор төрки телләрне аерым, мөстәкыйль тел буларак түгел, ә «шивә», ягъни төрки телнең бер диалекты яки «һәр кавемнең үз ана теле» дип яза.

Редакция

Тел үзе гади вә әһәмиятсез генә йомшак бер ит кисәгеннән гыйбарәт булса да, аның аркылы чыккан тавыш, сүз вә җөмләләрнең дәрәҗәсе гаять югары яки түбән булырга мөмкин. Һәм дә бөтен дөнья адәмнәре шул сөйләшә белүләре аркасында хайваннардан югары торалар. Шул тел аркасында үзләренең фикер вә хиссиятләрен башкаларга аңлаталар. Шуның өчен дә телне гакылның тәрҗеманы, диләр. Гакыл вә зиһеннәребезнең тәрәккый вә югарылыгына никадәр иҗтиһад итсәк, шул нисбәттә үк телебезнең тәрәккый вә югарылыгына иҗтиһад итүебез кирәк. Чөнки гакыл вә зиһенебезне тиешенчә тәрәккый иттереп, телебезгә әһәмият бирмәсәк, гали фикерләребезне вә хаклы таләпләребезне башка затларга вә чит милләтләргә ярлы, сөйкемсез вә эшләнмәгән тел илә аңлата вә тәэсир итә алмаячагыбыз көн кеби ачык бер хакыйкатьтер. Гакыл илә тел икесе бер кардәш булганлыктан, берсен икенчесеннән аерырга ярамаганлыгын һәр гакыл иясе аңласа кирәк. Чөнки бу көнге гыйлем вә һөнәрне гакыл эзләп тапса, тел эшләп, тәмам итеп чыгарган. Югыйсә, дөньяда ни шәкерт, ни мөгаллим вә бер даһи философ булмас иде. Ни дин вә ни канун төзелмәс иде. Һичберәве булмас иде. Шулай булса да, без телебезгә

«Надан вә әхлагы бозык булган үги ана, күңеле ак вә пакь булган бер ятим балага нинди күз илә караса вә нинди хурлыклар күрсәтсә, без төрекләр дә мөкаддәс телебезне шулай кактык, хөрмәтсезлек күрсәттек».

әһәмият бирмәдек. Надан вә әхлагы бозык булган үги ана, күңеле ак вә пакь булган бер ятим балага нинди күз илә караса вә нинди хурлыклар күрсәтсә, без төрекләр дә мөкаддәс телебезне шулай кактык, хөрмәтсезлек күрсәттек. Инде шуның җәзасын татыйбыз...

«Телгә хөрмәтсезлек» гөнаһыннан кәффарәт[1] булсын өчен, гыйлем вә һөнәргә бар көчебез илә ябышуыбыз тиеш. Котылу шунда. Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре рәхәт-рәхәт мәгыйшәт иттегебез җирне никадәр кадерле кылып яратса, шул җир өстендәге һәммә хайван вә мәхлукатларны да бик күп төрдә яраткан. Шулар җөмләсеннән инсаннарга карасак, яратылыш җәһәтеннән булган төрлелекләренә хәйран калмаслык түгел. Адәмнәр, үзләренең яратылмышларында вә терекчелекләрендә бу көнгә кадәр булган гакыл вә гыйлемсезлекләре аркасында, табигатьнең шәфкатьсез, мәрхәмәтсез кануннары астында бик нык изелгәнлектән, үзләренең бер-берсенә күрсәткән йомшаклык вә катылыкларын таныганлыктан соң, табигать вә мәгыйшәтләрендә, гакылда хисапсыз күп үзгәрешләр күргәннәр. Гакыл, аң-зиһен үзгәрү сәбәпле, телләре дә үзгәргән. Бу үзгәрешләр күбәеп, хәзерге хәлгә җиткәннәрдер.

Ошбу көндә бөтен дөнья адәмнәре бер мең төрле тел, 5-6 мең төрле шивәдә сөйләшә, диләр. Телләрнең болай бер-берсенә башка, бөтенләй аңлашылмау дәрәҗәсенә җитеп дөньяга килүенә үзебез сәбәп була алмаган кеби, шул төрле хәлендә дөньядан китүенә дә без каршы тора алмабыз. Чөнки телләрнең болай төрлеләнүе белән көрәшү табигатьнең кануннарына вә мохитнең агышына каршы тору була. Моңа каршы торган адәмнәрне без белмибез, шуның өчен дә асылы башка булган, бере-беренә аңлашылмый торган ике телне берләштерү хакындагы эшләрнең нәтиҗәсе хәерле булып чыкмыйдыр. Әмма инде асылы бер булып та, башкарып-төрләнеп киткән бер телне, асыллары башка булган ике телне берләштерү кебек мөмкин түгел, дия алмыйбыз, бәлки киресенчә, авырлык белән булса да, бер агымга салып җибәрергә мөмкинлек бар, дибез. Тарихлары, каннары, диннәре бер булган вә бер хөкүмәт идарәсендә яшәп, мәнфәгатьләре уртак булган бер кавемнең шивәләрен (асыл шивәләрне бетерми, шул шивәләрдән алынган лөгатьләрне) берләштерү гайре табигый бер эш, дип тә әйтә алмыйбыз.

Бу җирдә шуны да хәтердән чыгарырга ярамыйдыр: асылы бер булган төрек шивәләреннән чүпләнеп «гомуми төрек теле»н барлыкка китерә калсак та, бу тел икенче дәрәҗәдәге тел булып калачак. Чөнки бүгенге төрки шивәләрнең һәркайсы «ана теле» саналадыр. Ана теле дәрәҗәсенә ирешкән тел кадәр мөкаддәс тел юк. Адәмнәрнең иманына иблис зарар итсә итәр, әмма ана теленә зарар вә зыян китерә алмас.

Моннан шундый нәтиҗә чыгадыр: 1) шивәләребезне саклап тәрәккый итәргә тырышу кирәк, чөнки ул – ана телебез; 2) шивәләрдән гомуми-уртак бер төрки тел ясау кирәк, чөнки мәнфәгатьләребез уртак.

Бөтен төрек шивәләреннән сүзләр җыелып алып, уртак бер телнең чыгышына сәбәпләр бик күп булырга мөмкин. Әмма иң баш сәбәп – шивәләребезнең арасыннан берәвен генә алып, бөтен төрек балаларына шул шивәне кабул иттерә алмавыбыздыр. Калган шивәләр илә берәүнең максатын аңлау безгә кыен. Күбрәк укыган вә

[1]Кәффарәт – гөнаһтан арыну өмете белән кылынган яки кылынырга тиешле эш.

дөнья күргәннәребез, башка шивәләр илә язылган гәзитә вә журналларны укып, эчтәлегенә төшенә алсалар да, һәр сүзнең мәгънәсенә төшенә алмыйлар. Әмма инде авыл халкы бөтенләй аңламый. Шуннан соң: «Моны язган адәм үзе укысын!» – диләр. Шуның өчен дә бер шивәне генә хаслап, бөтен төрек балаларына: «Менә инде шул шивә күпнең уртасында уртак тел булсын!» – дия алмаячакбыз. Бер зат, бер шивәне кулына тотып: «Төрек балалары алдына чыгып, сезнең шивәгез уртак тел булырга ярамый, чөнки шивәгездә бик күп ят милләтнең сүзләре бар, әмма безнең шивәбездә төрек балаларының күңелләрен рәнҗетә торган чит лөгать юк. Шивәбез сафлыгы вә даирәсенең киңлеге илә башка шивәләрдән күп югары торадыр. Безнең шивәбез уртак тел булырга тиеш!» – дисә, моңа кыска гына итеп: «Шивәгез никадәр саф вә даирәсе киң булса да безнең ана шивәбез кадәр була алмас!» – дисәләр, урынсыз әйтелгән булырлар идеме? Инде шулай булгач: «Тел – халык өчен, халык тел өчен түгел!» – дияргә туры киләдер.

Ана теле дәрәҗәсенә ирешкән тел кадәр мөкаддәс тел юк. Адәмнәрнең иманына иблис зарар итсә итәр, әмма ана теленә зарар вә зыян китерә алмас.

Төрки шивәләрнең аерым-аерым үз алларына гына камилләшүе бик яхшы эш. Әмма дөньяда адәм төсле яшәргә теләгән зур бер милләткә заманның әйдәве буенча йөрергә туры киләдер. Заман безне далада күчмә хәлендә яшәргә түгел, ә мәдәни бер тормыш илә торырга мәҗбүр итәдер. Мәдәни тормыш ел саен, хәтта сәгать вә минут саен тормышыбызда булмаган бик күптөрле мәсьәләләрне берсе артыннан берсен алдыбызга китереп куядыр. Менә шул яңа мәсьәләләрне шәригать вә закон буенча хәл кылу, гамәл кылу безнең үз ихтыярыбызда. Без никадәр шивәләр илә сөйләшсәк тә, барыбыз да бер төрек токымы вә бер төрек балаларыбыз. Шулай булгач, без бер кавем вә бер җенес икәнбез, мәдәният мәйданында да бер булып, бер-беребезгә көч вә куәт биреп эш кылуыбыз тиеш күреләдер, чөнки мәнфәгатьләре уртак булган бер халыкка бергәләшеп, бер максатка карап бару һәм күңелле, һәм җиңел булачак.

Бөтен төрек балалары мәдәни бер ихтыяҗыбызны үтәү нияте илә бер җиргә җыелсак, шул ихтыяҗыбызны үтәр өчен фикерләребезне бер-беребезгә аңлатырга тиешбез. Фикер вә хиссиятләребезне аңлату өчен тел кирәк. Бу хәлдә нинди тел илә сөйләшү кирәк? Төрек балаларының бөтенләй чит булган бер милләтнең теле илә сөйләшүе телебезне вә милләтебезне хурлау буладыр. Шивәләрдә фикер алышу мөмкин түгел. Инде ни кылмак кирәк? Менә бу «ни кылмак кирәк» сөаленә, бөтен төрек балаларына гомуми бер төрек теле кирәк, дигән җавапны бирүдән башка сүзебез юк. Мондый телнең барлыкка килүе мөмкинме? Булса, моны мәйданга чыгару өчен нинди юллар бар?

Кай җирдә җәмгыять булса – анда гыйлем, һөнәр тамыр җәядер. Гыйлем, һөнәр кайда булса, дөньяның кирәк-ярагы анда табылыр. Җәмгыятьләре нигезле бер юлга куелган бер милләт илә җәмгыятьсез яшәүче икенче бер милләтнең тормышы арасында бик зур аерма бар. Иң зур җәмгыятьләребездән саналырга тиешле булган мәмләкәтләр үзләренең күләмнәренә нисбәтле никадәр мөһим эшләр эшләсәләр, шулкадәр үк иң кечкенә булган потребительный обществолар да үз күләмнәренә нисбәттә шулкадәр мөһим эш чыгаралар. Җәмгыятьләребездә көч тә күп, бәрәкәт тә бар.

Шивәләребезне берләштерү, бер калыпка салу, матур иттереп чыгару – яхшы вакыйга, зур бер эш. Зур эшне эшләү кечкенә көчләрнең вазыйфасы түгел, чөнки зур эшләр алдында кечкенә көчләр юк булып бетәдер. Эше күп булган «гомуми төрек теле»нең төзелүенә бер җәмгыять кирәк. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2017

«ШЫГЫРДАН ТӨЕНЕ»Н ЧИШКӘНДӘ

Фатих Кутлу

(Кайтаваз-юльязма)

2. ТАҺИРӘ АПА

Шыгырданнан китешли Чичкан авылына, Ркаил абый Зәйдулланың туган йортына, аның әнисе Гөлинә апа янына кереп, хәл-әхвәл белешеп чыктык.

Казанга кузгалганда вакытка күз салсак, сәгать төгәл җидене күрсәтә иде. (Хәтерләсәгез, Казаннан да иртәнге җидедә чыктык.)

Кайтканда сәфәребезнең искиткеч матур, хозурлы, күңелле узуына кинәнеп кайттым. Редакциягә дә, көн дәвамында руль әйләндергән Ләбиб абый Леронга да кат-кат рәхмәт әйттем. Күңелемне бер генә үкенеч тырнады – Таһирә апа Борчаклы белән күрешә алмадык. Сәяхәтебезнең шул ягы китек калачак иде. Иртәгә Чаллыга юл тотасым бар. Хатыным, балаларым шунда, алар мине көтә. Калган эшкә, һичшиксез, кар

Таһирә апа Борчаклы. 1951

Таһирә апа Борчаклы. 19.07.2017

Ахыры. Башы журналыбызның 11 (2017) санында

Фидания апа. 1952

Фидания апа Шыгырдан китабы белән. 19.07.2017

явачак. Түзмәдем, машинада ук Таһирә апаның кызына шылтыратып: «Әниегезне бүген күрмәсәм, йокым йокы булмаячак», – дидем. Рәхмәт яугыры, адресын бирде. Ләбиб абыйдан Казанга кергәч үк мине төшереп калдыруын сорадым. Машина чакыртып, Таһирә апа янына барырга иде исәбем. Ләкин Ләбиб абый күнмәде, теге адресны эзләп китте һәм тапканына инангач кына, мине төшереп калдырып, Ленар дусны (Ленар Гобәйдуллинны) озатырга китте.

Әнисә ханымның ишеген кактым. Таһирә апаның теге фоторәсемдәге кыз булуы ап-ачык күренә иде. Үзе егерме көн инде Казанда икән. Авылын бик нык сагынган. Шыгырданнан кайтып кына төшкән кешене күргәч, аның туган авылына икеләтә кайтасы килеп китте, ахры.

Әле ул минем язмам турында берни белми иде. Янына утырып, «Шыгырдан төене»н алдына салдым. Рәсемне күргәч, шаккатып: «Без болай фотога төшкәнне дә белмим, онытканмын инде», – дип куйды. Сабакташларын хәтерли иде, билгеле. Фидания апаны да истән җуймаган: «Бик матур көлә иде, – дип, хәтерен яңартты. – Чәчләрен калфак рәвешендә үреп килә иде. Без бик яратып, бик кызыгып карый идек аның чәчләренә...» Аны җөпләп, кызы – Әнисә ханым: «Әни безгә укытучысы Фидания апа турында гел сөйли иде», – диде. Яхшы ук гәпләшеп утырдык. Фидания апага шылтыратып, икесен сөйләштермәкче идем, ләкин аргы якта төребкәне алучы булмады. Вакыт соң иде инде. Шулай да, өйгә тыныч күңел белән кайтып киттем.

3. ЧАЛЛЫДА

Фидания апа мине Чаллыда түземсезлек белән көтә иде. Вакыт табуга, аның янына бардым. Башта «Шыгырдан төене»н укып чыкты: «Бик матур мәкалә булган бу», – диде. Сәяхәтебез турында җентекләп сөйләп бирдем. Сәфәр фотоларын күрсәткәндә, укучыларын: «Ул кадәрле картаймаганнар әле. Матур булып торалар», – дип бәһаләде. Памир абыйның «Шыгырдан» китабы аңа көтелмәгән бүләк булды. Мин аңа: «Мәннаф

Немакаевның фоторәсемен күрдем», – дидем. Ул: «Аның фотосы миндә дә саклана», – диде. Фидания апаның Шыгырданга килгән көннәрендә Мәннаф ага үзе бүләк иткән икән. Шундый гадәт булган. Артында урысча язу (бусы да гадәттән, күрәсең): «Здравствуй, Фидания! Я буду любить и уважать тебя, но, конечно, и ты не забудь меня. От Немакаева М. 26 ноября 1951 г.»

Бая Таһирә апа белән Фидания апаны сөйләштерә алмаган идем бит әле. Хәзер Таһирә апаның номерын җыйдык. Бик сөенештеләр, куаныштылар. Әңгәмәне мөгаллимә: «Мине яшәрттегез, үлгәнче җитәрлек дару бирдегез! Ходай сезгә дә сәламәтлек насыйп әйләсен, очрашырга язсын!» – дип тәмамлады.

Шушы урында мин: «Шыгырдан халкының күңелендә җуелмаслык тирән эз калдырган Фидания апа «минем җәннәтем» дип йөрткән Шыгырдан якларын күреп кайтса иде!» – дип теләдем. Амин!

4. АЛАБУГАДА

Ләкин сәфәрем әле моның белән дә тәмамланмады. Остазым Мөнир абый хозурына Алабугага барасым бар иде. «Шыгырдан төене» аның белән башланды. Шыгырданның бер өлеше – асыл улы! – безне төрле фәннәрдән (хәзерге татар теленең сүз ясалышы, морфологиясе, диалектологиясе, иске татар язуы һ.б.) берничә ел буе укытты.

Остазым бакыйлыкка күчкән көннәрдә көндәлегемә теркәлгән, соңыннан «Безнең мирас» битләрендә дөнья күргән язмам самими һәм ихлас булган икән, дим: аның бәрәкәтле тәэсире һаман дәвам итә...

Журналның 7 нче санын алып, курсташым белән бергә Мөнир абый яшәгән йортка киттек. (Моңарчы игътибар итмәгән идем, адресы: Ч. урамы, 7 икән. Тагын җиде...) Безне остазыбызның хатыны, үзе дә гимназиядә татар теле укытучысы Рәмзия апа каршы алды. Шыгырданга сәяхәтебезне сөйләп бирдем. Язманы бик яратып укыды. Чуашстанга юл тотканда Ләбиб Лерон әйткән «Мөнир абыйның берәр җыентыгын чыгарып булмасмы?» фикерен Рәмзия апага җиткердем. Ул моңа бик сөенде. Мәрхүм үзе дә исән чакта шул хакта хыялланган. Язмаларын китап рәвешенә китереп, макетын да әзерләгән булган. Башка язмалары да электрон вариантта саклана икән. Рәмзия апа ул «китапны» да, анда керми калган башка шигырьләрен дә, бик теләп, миңа тапшырды. Остазымның чынга ашмый калган хыялын бергә-бергә тормышка ашырырга насыйп булсын иде!

Рәмзия апа үзе дә мәрхүмнең каберенә барып кайтырга ниятләгән икән. Зиратта булдык...

Шаһигардан-Шыгырданым минем,
Иман нуры сеңгән авылым,
Денен, телен саклап кала алган
Дан-шөһрәтле мишәр кавемем,
Оныта алмый, өзелеп сагына сине
Бурлактагы газиз бер улың.
Чулман төбәгендә төпләнсәм дә,
Кыйблам син, Шыгырдан, күз нурым.

И, остазым Мөнир абый! И, Шыгырданның газиз улы, сөекле баласы!

Шулкадәр зурлап язган туган авылыңны күрдем, Аллаһка шөкер! Син дөньяга аваз

Мөнир абый кабере янында. 19.07.2017

салган нигездә булдык. Туганнарың, авылдашларың белән күрештек.

Без – төрек шәкертләре сине бик нык яраттык. Үзең дә безне якын иттең. Рәхмәт сиңа! Урының җәннәттә булсын!

5. НОКТА КУЯР АЛДЫННАН

Сәфәремдә һәрдаим 7 саны юлдаш булуына һәркем игътибар иткәндер.

Безнең халык саннарның серле рәвештә шулай туры килүен хәерлегә юрый.

Шыгырданга барырга теләк-догам «Безнең мирас» журналының 7 нче санында, 57 нче биттә басылып чыккан.

17.07.2017 көнне иртә белән сәгать 7дә кузгалдык.

Кичке 7дә Казанга юл тоттык.

Ул дүшәмбе көн иде. «Дүшәмбе» сүзе 7 хәрефтән тора.

725 (икенче өлеше: 2+5=7) номерлы машина белән бардык.

Тукай урамы, 27 йортта тукталдык (Мөнир абый туып үскән нигез).

Безне юлга чакырган фоторәсемдә 7 укучы кыз сурәтләнгән.

Фидания исемендә 7 хәреф бар.

Фидания апа Чаллыда 7 нче мәхәлләдә тора. 14 (7+7) нче керештә (подъездда) яши.

Мәннаф Немакаев 17 августта вафат булган.

Мөнир абый Алабугада 7 нче йортта гомер кичергән.

Мөнир абый белән Рәмзия апа 27 июльдә (июль – җиденче ай) өйләнешкәннәр.

Мөнир абый 7 мартта 57 яшьтә бакыйлыкка кичкән.

Язмамның караламасы 7 августта тәмамланды. Көн шулай ук дүшәмбе иде... ■

ЕРАКТАГЫ ЯКЫН МИЛЛӘТТӘШ

Сәлия Гарифуллина

Наил исеме гарәпчәдән «бүләк, бүләккә лаек» дип тәрҗемә ителә. Кызык кына бу дөнья! Күпчелек исемнәр җисеменә туры килә дә куя. Кайберәүләрнең тәкъдир «дәфтәре»ндә алдан ук шулай теркәлә, күрәсең.

Чыннан да, мәкаләдә бәян кылыначак тормыш сәхифәсе тулы повесть, хәтта ки роман язарлык. Гап-гади татар малае берзаман дөнья күләмендә танылу алган галим булырмын, илләр гизәрмен, дип фаразладымы икән?!.

УКЫТУЧЫЛАРЫМ ТЫЛСЫМЧЫГА ТИҢ ИДЕ...

Наил Хәйрулла улы Ибраһимов – физика-математика фәннәре докторы, Швециядәге Блекинге Технология институтының табигый һәм математик фәннәр кафедрасы профессоры 1939 елның 18 гыйнварында Ютазы районының Иске Урыссу авылында туган. Сугыш чоры малае буларак, ачлык-ялангачлыкны да җитәрлек татыган ул. Башлангыч белемне ана телендә алгач, тимер юл станциясе янындагы җидееллык мәктәптә урысча укып бетергән. Бәхетенә күрә, Лариса Бархат сыман сәләтле-сизгер укытучыга эләккән. Малайның мисалларны чикләвектәй тиз һәм җиңел «яруын» шәйләгән мөгаллимә, өстәмә рәвештә аңа катлаулыларын, кызыкларын тәкъдим итә башлаган. Галим математика укытучысына бүген дә рәхмәтле... Аның «Укытучыларым тылсымчыларга тиң иде» дигән сүзләре генә дә ни тора!

АРАЛАША БЕЛҮ – БӘХЕТ

Наил Ибраһимовның төрле телләрдә иркен сөйләшә алуы хәйран калдыра. (Аның лекцияләрен Россиядә генә түгел, Канада, Төркия, АКШ, Швеция кебек илләрдә дә мөкиббән китеп тыңлыйлар.) Бу гамәленә дә «оеткы» балачакта салынган. «Кечкенәдән күптелле мохиттә үстем, – ди язмамның каһарманы. – Әтием гарәпчә җиңел укый иде, мине дә өйрәтте. Намазга да өйрәндем әле! Татар телен башта латин, аннары кирилл хәрефләренә күчерделәр. Анысын да тиз таный башладым. Китапларны су кебек эчтем...»

Ибраһимовлар гаиләсе. Сулдан уңга: Алия, Сания, Рәйсә, Наил

Җидееллык мәктәпкә килгәндә бер урысча сүз белмәгән малайга тәү чиратта математика дәресләре якын була. Саннар барлык телләрдә дә бер үк ич! Тора-бара урыс теле дә үзләштерелә.

Армия хезмәтендә дә китаптан аерылмый үҗәт егет. Үзлегеннән югары математика, физиканы өйрәнә. Берзаман ул китап кибетендә акцент белән сөйләшкән сатучы ханымга игътибар итә. Танышалар. Баксаң, Мюллер фамилияле ханым алман милләтеннән икән. Шул рәвешле, Наил алман теленнән дәресләр ала башлый. Таләпчән остазы шигырьләргә кадәр ятлата. Якташыбыз үлемсез Гете әсәрләрен әле булса яттан хәтерли.

ГОМЕР КЫСКА, АШЫГЫРГА КИРӘК!

Максатчан, гыйлем «букчасын» шактый тулыландырган солдат кыенсынып тормый, көннәрнең берендә шәһәрдәге физика институтына барып керә. Биредәге укытучыларга төгәл фәннәр яратуын, армиядән соң югары белем алырга җыенуын әйтә. Мөгаллимнәр Мәскәүгә барырга киңәш итә. Тәвәккәл егет, һич икеләнмичә, башкаланың физика-техника институтына юл тота. Заманында Капица, Ландау сыман атаклы галимнәрне сыендырган абруйлы уку йортының студенты булу бәхетенә ирешә. Укый башлый. Әмма... тынгысыз егетне уку тизлеге канәгатьләндерми. Гомер кыска, ашыгырга кирәк! Бер елда ике курсны тәмамларга рөхсәт сорый. Ризалык алмагач, Новосибирск университетының механика-математика факультетына күчәргә карар кыла. Монда инде теләгенә ирешә. Биш курсны өч елда тәмамлап, 1965тә кулына диплом ала. Бер үк вакытта Гидродинамика институтында лаборант булып эшли, өстәмә лекцияләр тыңлый. Бигрәк тә Юрий Румерның физика дәресләрен калдырмаска тырыша. Кирәге чыгар, дип, француз һәм япон телләрен өйрәнә. 1967 елда – кандидатлык, 1972 елда докторлык диссертациясен яклый.

ТАТАР ҺИЧКАЙДА СЫНАТМЫЙ

1980 елда Наил Ибраһимов Уфага килә. СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалында математик физика лабораториясен ачуда катнаша. Анда мөдир була. Авиация институтында гамәли математика кафедрасына җитәкчелек итә. Төрле фәнни-гамәли конференцияләрдә чыгыш ясый, журналларда басыла. Хезмәтенә күрә хөрмәте: 1987 елда аңа СССРның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе тапшырыла. Озакламый танылган галимне Мәскәүгә – М.В.Келдыш исемендәге гамәли математика институтына чакыралар. 1993 елга кадәр биредә баш фәнни хезмәткәр вазыйфасын башкара.

Туксанынчы еллардан алып, профессорның гыйльми эшчәнлеге чит илләр белән бәйле. Әүвәл Истанбул техник университетында (Төркия) кафедра профессоры булып тора. Аннары Көньяк Африка Республикасында хезмәт куя, Йоханнесбург, Мафикенг шәһәрләрендә семинарлар уздыра. Наил әфәнденең фәнни хезмәтләре Көньяк Африкада аеруча югары бәяләнә.

«АЛГА» – ДӨНЬЯ ЯУЛАРГА!

2000 елда Наил Ибраһимов гаиләсе белән Швециягә күченә. Гаҗәеп күркәм Карлскруна шәһәренең Блекинге технология институтында математика кафедрасы профессоры булып эшли. Аннан битәр, Халыкара «Алга» үзәген оештыра, төрле ил математиклары белән тыгыз элемтә урнаштыра. Шул рәвешле, милләттәшебез фәнне яңа киңлеккә чыгару юлында татарның горур яңгырашлы «алга» сүзен этәргечкә әверелдерә.

2011 елда Казанда узган II Бөтендөнья татар галимнәре форумында Наил әфәнде «Төркемләп тикшерү – модельләштерүнең микроскобы» темасына чыгыш ясый. «Мәгърифәт» газетасында урын алган мәкаләдә автор, танылган журналист Хәмзә Бәдретдинов Наил Ибраһимовның чыгышыннан бер өзек китерә: «Әгәр югары уку йортларындагы хәлләр белән танышсагыз, сез бүгенге студентларның математиканы укырга теләмәүләрен күрерсез. Курстагы 150ләп студенттан лекциягә нибары унлап егет-кыз йөри. Россиядә Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган стандарт программа белән белем биргәндә, мондый «югалтуны» үзем дә баштан кичердем. Студентлардан: «Укыту ысулыгыз канәгатьләнерлек түгел», – дигән дәгъва ишетеп, аптырап калдым. Уйландым. Элекке кысаларга ябышып ятмаска кирәклекне аңладым. Математик модельләштерүнең төркемләп тикшерү тәртибен гамәлгә кертеп, четерекле мәсьәләгә гади чишелеш таптым, ягъни тигезләмәләрнең нигездә дүрт төрдән килеп чыгуын, калганнарының шуларга таянып тармаклануын исбатладым. Үз дәреслегемне булдырдым. Ул инглиз, швед, кытай һәм урыс телләрендә чыкты. Шулай ук немец, фарсы һәм испан телләренә дә тәрҗемә ителде... Инде хәзер Казанга килгәч, сорауның яңасы туды: мин бу өлкәдә Татарстанга нинди файда китерә алам соң? Әлбәттә, төркемләп анализлау ысулын, моңа багышланган 25 дәреслегемне туган халкыма кайтара алам!»

ЯШЬ БУЫНГА ӘМАНӘТ

Аңлашыла ки, Наил әфәнденең иң зур хыялы – туплаган гыйлемен яшь буынга тапшырып калдыру. Бу мөһим эшкә җәмәгате Рәйсә Сафуан кызы Хәмитова да лаеклы өлеш кертә: тигезләмәләрне гади алымнар белән чишүчеләр санын ишәйтә, Наил ага

эшләгән университет студентларына инглиз һәм швед телләрендә математика фәнен укыта. Аспирантура тәмамлаган, Швециядә диссертация яклаган. Ибраһимовларның кызлары да фәндә үз юлын тапкан. Сания Швециядәге Лунд университетында укыган, Даниядә аспирантура тәмамлап, диссертация яклауга ирешкән. Хәзер медицина һәм биология өлкәсендәге нанотехнологияләрне гамәлгә кертү белән шөгыльләнә. Алияләре Упсала һәм Лунд университетларында белем алган. Анысы иҗтимагый фәннәргә өстенлек бирә, фәкыйрьлек хөкем сөргән дәүләтләргә ярдәм күрсәтә торган шәхси компания вәкиле сыйфатында, илләр гизә.

Скайп аша Алия белән аралашып алырга насыйп булды. Ул бар булмышы, килеш-килбәте белән чын татар кызы: нәзакәтле дә, горур да, ихтыяр көче дә җитәрлек. Теләсә кайда үзен танытырлык, якларлык. Бу – әлбәттә, әти-әни тәрбиясе нәтиҗәсе. «Поезд тәрәзәсеннән күземне алалмадым, – дип искә төшерә Алия Татарстанга кайтуын. – Табигатьнең гүзәллегенә шаккаттым. Әти-әнинең бу яклар хакында сөйләгәнен хәтердә яңарттым. Урыссуга җитәрәк, күңел бөтенләй нечкәрде. Әби-бабамны искә алдым. Әни ягыннан дәү әтием сугышта булган, концлагерьда кеше күтәрә алмаслык авырлыкларга дучар ителгән, әмма, үлемгә үч итеп, исән-имин килеш туган нигезенә кайтып төшкән. Дәү әниемне хәтерлим дә әле. Ифрат иплe-тыныч, тыйнак, игелекле, пөхтә иде ул. Әти яклап та әби-бабам тырыш, чыдам кешеләр булган. Алардан башка бу дөньяда без дә булмас идек. Ни гаҗәп: монда – нәселем тамырланган җирдә әби-бабалар гел янәшәмдә торгандай хисләр кичердем. Мин – аларның дәвамы. Сынатырга ярамый!»

МАТУР БУЛСА ДА ТОРГАН ЖИР...

Ерак җирләрдә гомер кичерүенә карамастан, Наил Ибраһимов туган яклары белән элемтәне өзми. Наил абый әле нык чагында төрле фәнни-гамәли конференцияләргә дә еш кайтып йөргән. 2009 елда Уфада уздырылган шундый чарага, мәсәлән, туган авылында физика-математика укытучы ханымнарны да алып барган. 2011 елда, фәкать аның тырышлыгы нәтиҗәсендә, Уфа дәүләт авиация-техник университетында табигый фәннәр, техника һәм технологияләрнең математик модельләрен төркемләп анализлау фәнни-тикшеренү лабораториясе барлыкка килгән. Наил Ибраһимов аңа җитәкчелек итү дәверендә Россия грантына да лаек булган. Әйтергә кирәк, бүгенге көндә лаборатория уңышлы гына эшләп килә.

«Балачакта поезд машинисты булырга теләгем бар иде, – ди Наил әфәнде әңгәмәбез ахырында. – Чит-ят җирләрне күрү хыялы көчле булды. Иван Гончаровның «Паллада» фрегаты»н укыгач, кайларда гына «йөрмәгәнмендер»! Җылы якларны, диңгез-океаннарны гизәсем, сәяхәт кыласым килә иде. Байтак гомер узгач булса да, барыбер ул илләрне барып күрү бәхетенә ирештем...»

Кешенең торган җирләре күп булса да, туган җире бер генә шул!..

Нинди генә үрләр яулап, нинди генә дәрәҗәләргә ирешеп тә, үзеңнең кайдан, кайсы туфрактан, нинди халыктан булыңны һәрдаим хәтердә тоту, аның җылысын, кадерен тоеп яшәү – кеше өчен иң олуг мәртәбәгә һәм мактауга тиңдер, мөгаен... ■

Безнең мирас №12 декабрь 2017

ЕГЕТ КҮРКЕ ДАН БЕЛӘН...

Айгөл Әхмәтгалиева

Аның балачагын мин үзем шук, тынгысыз итеп күзаллыйм. Хыялланырга яраткандыр... Тәүлектәге егерме дүрт сәгатьне әзсенгәндер... Мәктәптә сыйныф командиры булганда ук киләчәк һөнәренә юл сапкандыр...

– Юк, кечкенә чакта минем табиб буласы килә иде.

Бу сүзләрне бүгенге мәктәп директоры әйтә. Айдар Илдар улы Шәмсетдиновның исеме күпләргә яхшы таныш дип уйлыйм, чөнки Казанның ул җитәкләгән 165 нче мәктәбе – республиканың иң яхшы 100, башкаланың 10 мәктәбе арасына кергән уку йорты. Айдар әфәнде үзе исә – 2016 елда Россиянең иң яхшы директорлары бәйгесендә катнашып, мәртәбәле икенче урынны яулаган шәхес.

Айдар – Казан егете, 1976 елда дөньяга килгән. «Әти-әнием рус мәктәбен бетергәч, өйдә русча сөйләшәләр иде. Үзем дә рус мәктәбен тәмамладым», – диюенә баштарак сәерсенеп киттем. Чөнки ул, әллә нинди мәкальләр, гыйбарәләр куша-куша, саф татарча бик матур сөйләшә. Сере бар икән...

Әй, ак яулыклы әбекәйләр! Милләтнең рух һәм тел сакчысы булгансыз бит сез, бәяләп бетергесез асыл хәзинәсе, алтын баганасы булгансыз... Әнә бит, яннарында дәү әнисе Миңлегаян яшәмәсә, Айдарның теленә каян килеп кунар иде бу татарча аһәң, йөрәгенә Аллаһ сүзе кайлардан иңәр иде?!.

– Әниемнең әнисе Миңлегаян – Туфан Миңнуллин белән бер авылдан, Кама Тамагы районындагы Мәрәтхуҗадан, ә бабаем Габдрахман – себер татарларыннан. Әти ягыннан Нияз бабаем исә – Чистай мишәре, Разия әбием – Мәскәү татары. Миңлегаян әбием бездә торды, аның белән гел татарча сөйләшә идек. Әтием Илдар да, әнием Рушания дә гомер буе заводта эшләде, өч малай үстерде. Мәктәп җыелышларына әти йөри иде: «Айратныкына барсам, җайлы гына утырам, Айдарныкында – уңайсыз, артык мактыйлар; Русланныкында уртача ичмаса», – ди иде кайтып кергәч. Мин 68 нче мәктәптә укыдым, бик актив идем, яхшы укыйм, ә менә инглиз теленнән алдырып кына китә алмыйм бит! Людмила Павловна «4»лене дә кызганып кына куйгандыр инде. Җиденче сыйныфта хәл үзгәрде: кулыма «Самоучитель английского языка» дигән китап килеп керде. Төбенә тоз коеп укый торгач, ул фәнне иң яхшы укучыга әйләндем дә куйдым, чиреккә бер минем генә «5»ле чыкты. Чит тел өйрәнү шулкадәр җәлеп итте, тора-бара

табиб булу теләге дә артка чигенде. Чигенмәс тә иде – мединститутка керү хыялы чынга ашмас кебек тоела башлады, чөнки ике туган апам да, өч ел рәттән барып караса да, ахыр чиктә биофакка керергә мәҗбүр булды. Түләп укырга өйдә акча юк...

Айдар Илдар улының үзен укыткан мөгаллимнәрне искиткеч бер җылылык белән телгә алуына сокланмый мөмкин түгел. Әйтерсең, иң-иңнәрне бары тик аның юлына гына тезеп куйганнар да, алар, барысы да маяк булып, егеткә яктылык нуры гына өләшкәннәр. Бәлки шулайдыр да. Әнә бит, рус теле укытучысы Гүзәл Зәкәриевна, гарәп теленә факультативка барабыз, дип, дәрестән кыякларга иткән егетләрне: «Башта татарчагызны яхшылап өйрәнегез!» – дигән бер җөмләсе белән урынга утырта. Ә татар теле укытучысы, өлкән яштәге Туйгел Зиннәтовна? Җиденче дәрес булып, атнага ике тапкыр кергән татар теле дәресендә, балаларны үзе алып килгән груша кайнатмасы белән сыйлый-сыйлый, чәй эчертә, татарча шигырь ятлата... 11 нче лицейда укыганда, татар теленнән кергән Луиза Ахуновна? – зыялылыгына, затлылыгына таң калырлык. Соңыннан, инде пединститутның чит телләр факультетына укырга кергәч тә, гамәлләре белән үрнәк булырлык мөгаллимнәр күп очрый Айдар әфәнденең юлында. Бу факультетка күпләр «тәрҗемәче булам» дигән уй белән керә. Ә Айдарның нияте катгый – ул укытучы булачак! Педагогика, методика, дидактиканы аның кебек ләззәтләнеп укучы студент бармы икән? – Күпләр мыек астыннан елмаеп кына куяр... Беренче курста ук балалар бакчасында инглиз теле алып барган егет үзе сайлаган юлның дөрес икәненә инанганнан-инана бара: ошый аңа балаларга чит тел өйрәтү, ошый – шуның белән шул! Өченче курста чагында исә үзе укыган 68 нче мәктәпкә эш сорап кайта Айдар. Шул рәвешле 19 яшендә мөгаллимлек стажына юл салына да инде. Яшь укытучы кул астында инглиз теле өйрәнә башлаган икенче сыйныф укучылары, аның белән кулга-кул тотынып, унберенчегә кадәр бара. Моңа кадәр мәктәптә чит тел өйрәнгән бала бусагадан чыкканда, «укыйм һәм сүзлек ярдәмендә тәрҗемә итәм» дигән статус белән атласа, Айдарныкылар үзгә: алар, чатнатып, саф инглиз телендә сөйләшә. Эш башлаганда, аерым бүлмәсе дә булмый егетнең, немец теле укытучысы Илсөяр апаның кабинет «чоланында» дәрес бирә ул. Илсөяр апа исә, беркадәр вакыттан соң, янына килеп: «Синең дәрес биргәнеңне тыңлап торам да, сокланып туймыйм. Мин менә югары квалификацияле укытучы, моңа гомерем буе килдем. Ә син – тумыштан мөгаллим», – ди, гади генә сүзләр белән егеткә бик зур бәя биреп.

Кемгәдер гаҗәп тә тоелыр, кемдер ышанмас та: администрациядә уңайлы гына утырган кәнәфиеңне калдыр да: «Миңа мәктәп бирегез, мәктәп директоры буласым килә», – дип, үз башыңа бетмәс-төкәнмәс мәшәкать, эш эзләп кил, имеш! Нәкъ менә шулай дигән Айдар Илдар улына 46 нчы татар мәктәбенең дилбегәсен тоттыралар. Анда бер ел эшләп, үзен күрсәтүгә – гомуми белем бирүче 165 нче мәктәп ачкычын.

Яшь чак – җүләр чак, дигәндәй, куркуны белмәгән вакытлар. Анда җимерек, монда җимерек, мәктәпнең даны югары түгел, башлангыч сыйныфлар җыелмый, коллектив чуар – менә шушы авырлыкларга күз йомып, үз хыялына таба атлый яшь директор. Инде әллә кайчаннан җанын кыбырсыткан – чит телләрне су урынына эчәрдәй укучылар тәрбияләүче мәктәп булдыру турындагы хыял ул. Тик, ай-һай, коры теләк кенә булып калмасмы икән? Ни дисәң дә, мәктәпнең матди-техник базасын аякка бастыру өчен генә дә байтак йөгерергә кирәклеге ярылып ята... Алайга калса, үзе яратып укыган «Алхимик» әсәренең герое шикелле, хыялыңа күз текәп, аңа каршы туп-туры атлаганда, нишләп әле яуланмас биеклекләр булсын? Ярар, яңа килүчене кайберәүләр: «Сез бик яшь түгелме соң, булдыра алырсызмы?» – дип каршы да алсын. Озак вакыт та үтмәс, тупланачак, иңгә-иң куеп эшләрлек укытучылар коллективы да тупланачак. Айдар Илдар улы һәр мөгаллимне тәүдә үз янына чакырып, кыл иләктән уздырачак, аның белән

сәгать буе инглиз телендә аралашачак: балага чит тел укытырга дип килгән укытучының үз әзерлеге ни дәрәҗәдә, дөньяга карашы киңме, чит ил мәдәнияте, әдәбияты турында белеме бармы, педагогиканы беләме... Мәктәп «инглиз телен тирәнтен өйрәтүче» дигән статус та алачак, бирегә килергә теләүче балалар саны да күзгә күренеп артачак, БДИ нәтиҗәләре буенча укучылар алгы сафта барачак. Балаларны эстетик яктан тәрбияләүне күздә тотып, мәктәп эчендә кышкы бакча да, тере почмак та, Бөек Болгарга багышланган панорама да булдырылачак, хәләл туклануны үз эченә алган мәктәп ресторанын да эшләячәк... Бүген – бу хыяллар барысы да чынбарлыкка әверелгән.

Айдар Илдар улы «титулларын» санаганда, аны сүз уңаеннан гына артист дип атарга да мөмкин булыр. Остазлары аның күңелендә театр дигән сихри дөньяга мәхәббәтне кечкенәдән уята. Мәктәптә дә, институтта да спектакльләр еш куялар, аларда катнашу – Айдар өчен үзе бер җан рәхәте. Карло Гоцциның «Хан кызы Турандык» әсәрендә Панталоне ролен башкарганын, Шәриф Хөсәеновның «Зөбәйдә – адәм баласы»нда уйнаганын, институтта гарәп һәм инглиз телендә спектакль куйганнарын горурланып искә төшерә ул. Бүген укытучыларның «Яшел яр» театр түгәрәгендә әйдәп баручы артистка әверелүенең сәбәбе иң беренче чиратта шул елларга барып тоташса, икенче сере – татарча спектакльләрдә уйнау туган телне даими чарлап торырга булыша. Мәктәп директорының үз коллективындагы укытучылар һәм укучылар белән бергә сәхнә тотуына афәрин, диясе килә, мондый чаралар үзара да, тамашачы булып килгән ата-аналар белән дә җылы, дустанә мөнәсәбәт булдыруга бер этәргеч булып тора. Театрның җитәкчесе – тынгысыз җанлы режиссер, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, тамашачыларны ел саен яңа спектакльләр белән сөендерүче Нурания Җамали бу эшкә тотынуын елмаеп искә ала:

– Айдар Илдарович бервакыт ТНВда Роберт Миңнуллин алып барган «Китап» тапшыруына килгән иде, мәктәп турында, анда спектакльләр кую турында сөйләгәне колагыма чалынды. Соңыннан: «Шундый матур сөйлисез, сезнең мәктәптә эшлисе килә башлады хәтта», – дим, шаяртып кына. Бервакыт бер ханым шылтырата: 165 нче мәктәптә мизансцена әзерләп яталар, ярдәм итмәссезме, дип, мине чакыруы. Барып, «әйдәгез, күрсәтегез», дисәм – әле рольләрне дә бүлмәгәннәр. Аяз Гыйләҗевнең музеен ачарга җыеналар, шунда «Шикәрем син, балым син» әсәреннән өзек куярга телиләр икән. Уйнарга ирләр юк. «Менә Сез уйнасагыз, куям», – дидем Айдар Илдаровичка. Шуннан китте инде, аны хәзер һәр спектакльдә катнаштырабыз. Ул гаҗәеп кеше, һәр эшкә өлгерә алуына шаккатырлык: үзе дә, балалары да татар телен онытмасын, дип, машинасында төрле спектакльләрнең язмасын тыңлап йөри; аның белән бөтен темага сөйләшергә мөмкин; җитәкчелек эше – үзе бер олы йөк, биш ел дәвамында Шәһәр думасында депутат булды; биш вакыт намазын да укый, мәктәптә авыз ачтырырга да өлгерә, бакчачылык белән дә шөгыльләнә – үзе үстергән груша, виноград, карбызларны, чәчәкләрне күрсәгез! Төркиядән орлыклар алып кайтып, кабинетында пальмаларга тикләм үстерә ул... Коллективта аны хөрмәт итәләр. Мин үзем дә, монда эшләү күңелемә рәхәтлек бирмәсә, килеп тә йөрмәс идем. Бөтен директорлар да Айдар Илдарович кебек күңел биреп, мәктәп өчен янып-көеп йөрсәме...

Аяз Гыйләҗев музее турында сүз чыккан икән, бу урында олпат язучының тормыш иптәше Нәкыя ханымның фикерләренә колак салу артык булмас:

– Аязның музее Айдар Илдаровичның инициативасы белән, аның татар җанлы булуы аркасында, татар әдәбиятында Аяз Гыйләҗевнең тоткан урынын аңлавы нәтиҗәсендә ачылды. Кешелекле җитәкче! Андыйларның хезмәте бәяләнергә тиеш! Россия директорлары бәйгесендә, 350 кеше арасында безнең татар егете җиңүче булып

кайтты – шул хакта берәр зурлап сүз булса! Чыкса, бер язма чыккандыр... Берәр яһүд шундый җиңү белән кайтсамы – бөтен тирә-якны шаулатырлар иде...

Шау-шу өчен эшләве түгел директорның, тынгысызлыгы – күңел таләбе. Ислам диненең кануннары буенча яшәгәч, аның төп принципларының берсе – гаделлек. Кул астында эшләгән йөздән артык укытучыга да, техник персоналга да, укучыларга да кешелекле мөнәсәбәттә булу.

– Мин ике нәрсәдән куркам, – ди Айдар Илдар улы, сүзебез бу темага кагылгач. – Начар кешеләрдән һәм үзем кешеләргә начарлык эшләүдән куркам. Намазны өйгә кайтып түгел, үз кабинетымда укуның да сәбәбе бар: биредә эшли башлаган елларымда бер укучыбыз белән фаҗига булды. Шуннан соң намазны катгый рәвештә мәктәптә укыйм, чөнки дога-теләкләр балаларны сакларга ярдәм итә.

Үз гаиләсендә тупырдап үсеп килгән Асия, Искәндәр, Мәликә өчен генә түгел, мәктәптәге мең ярымнан артык бала өчен дә кайгыруын тоеп, янә гаҗәпкә калырсың. Атаклы педагог В.А.Сухомлинскийның: «Әгәр кешеләр синең балаң турында начар сүз сөйлиләр икән, димәк, алар синең турында сөйлиләр», дигән гыйбарәсе гаиләдә бала тәрбияләүне күздә тотып әйтелсә дә, бу очракта урынсыз булмас. Чөнки Айдар абыйлары мәктәптәге һәр укучының тәртибе, белеме, рухи дөньясының матурлыгы өчен әтиләрчә ихласлык белән җан атып, борчылып тора, аларны киләчәктә зур хәреф белән язарлык чын кеше итеп күрергә хыяллана. Тәрҗемә эшенә җиң сызганып тотынуы да балалар күңеленә янә бер нур өстәргә теләвеннәндер әле, башкача булса, бу авыр хезмәтне Тукайның балалар өчен язган шигырьләрен инглизчәгә тәрҗемә итүдән башламас иде. Кибетләрдә хәзер «Су анасы», «Кәҗә белән Сарык» китаплары инглизчә дә «сөйләшә», Такташның «Тәүфыйклы песи»е дә алар рәтендә – барысы да Айдар Шәмсетдиновның җиңел кулы һәм йокысыз төннәре нәтиҗәсендә Татарстан китап нәшриятында зәвыклы булып дөнья күрергә өлгергәннәр. Соңгы елларда бик тырышып төрек телен дә өйрәнгән Айдар әфәнде, төрек язучысы Синан Акюз романын русчага тәрҗемә итеп, аны да китап итеп күрергә өметләнә. Бу җәһәттән танылган тәрҗемәче, татар әдәбиятын чит илләрдә дә танытуга гаять зур хезмәт куйган Фатих Кутлуның фикере укучылар өчен кызыклы булыр:

– Айдар әфәндене мин ак күңелле, инсафлы, ихлас кеше дип беләм. Өстәвенә, Ходай аңа талантны да өеп биргән. Мин аның тел өйрәнү дәртенә тукталырга телим. Ул бит татар, рус, инглиз телләрен камил дәрәҗәдә белә, үзлегеннән төрек телен дә өйрәнә башлаган. «Туган телне өйрәнүнең нигә кирәге бар соң?» – дип ана теленнән качкан кызганыч кешеләр күп булган бүгенге җәмгыяттә Айдар әфәнденең үзенә «бер дә кирәге булмаган» дүртенче телне өйрәнүе – олы мактауга лаек бер гамәл. Ул төрек телен шомартыр өчен телефоннан минем белән һәрвакыт төрекчә сөйләшә. Алай гынамы, төрекчә романнар укып, телен камилләштерә. «Тырышкан – табар, ташка кадак кагар», ди бит. Ул төрек теле өлкәсендә шундый остарган ки, төрек романын хәтта рус теленә тәрҗемә итәргә батырчылыгы җиткән, морадына да ирешкән. Мондый тырыш кешегә ничек сокланмыйсың инде?! Аңа күз генә тимәсен.

...Әлеге сүзләргә өстәп ни әйтим? Үзегез күреп торасыз: иң шәп директорларның берсе булу өчен артык күп нәрсә кирәкми икән бит: туган телеңне, милләтеңне яратырга, шул милләтнең асыл улы булырга омтылырга, үзең укыткан балаларны да гыйлемле, иманлы, илгә-көнгә кирәкле, заман белән бер адымда атлаучы күпкырлы шәхес итеп күзалларга, бал кортыдай гел эзләнергә, очарга гына кирәк икән. Бары шул гына.... ■

Безнен мирас №12 декабрь 2017

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов



Омск күренеше. XX гасыр башы

ОМСК ШӘҺӘРЕ (ДӘВАМЫ)

Поезд Чулымнан кузгалып киткәндә, мин ифтарга утырдым. Ул арада күршем тагын яныма килде. «Рәхим итегез, чәй эчәсезме?» – дип, каршы алдым. Күршем бик кызыксынучан кеше булып чыкты: бу юлы сәясәтне бер читкә куеп, дин турында сүз башлады:

– Аллаһ ник мондый авыр нәрсәләрне тәкъдим иткән икән? Сезнең бу ураза дигәнегез нәрсә соң? Нинди ризыклар ашарга ярамый? – дип сорады.

– Мин философ түгел. Хикмәтен бөтен нечкәлекләре белән аңлатып бирә алмам. Безнең ураза «фәҗр-и садык»тан[1] башлана һәм кояш батканга кадәр дәвам итә, бу вакыт арасында ашамыйлар да, эчмиләр дә, – дип җавап бирдем.

Бик аптырап болай диде:

– Мин Исламны бөтенләй белмим. Христианлыкны да беләм, дип әйтә алмыйм инде анысы. Безнең юл озын, вакыт үткәрү дә булыр. Миңа бераз Ислам турында мәгълүмат бирсәгезче, зинһар?

– Әлбәттә, белгәнемне сөйләрмен.

– Мин кайчандыр лютер мәзһәбендә идем, хәзер исә католик мәзһәбендә.

– Ни өчен мәзһәп алыштырдыгыз?

– Мин үзем дә белмим, никах мәсьәләсе белән бәйле булды. Католик рухани безне моңа ничектер күндерде. Минем өчен болай да әллә ни әһәмияте юк иде. Шулай булды да куйды инде!

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

[1] Фәҗр-и садык – таң алдыннан офыкта агарып җәелә башлаган яктылык (тәрж. иск.).

– Ике мәзһәпнең берсен сайлар өчен, берсен икенчесеннән өстен күрер өчен сәбәп була алырлык мәсьәлә бик җитди булырга тиещ.

– Әйе, яшь чакта әһәмияте бар иде, ләкин хәзер инде үтте. Мин Сезнең белемегездән файдаланып калырга телим, зинһар өчен, әйтегез әле: кешегә мөселман булыр өчен ниләр кирәк? Мәсәлән, мин хәзер католик, әгәр исламга күчәргә теләсәм, кемгә мөрәҗәгать итәргә тиешмен? Ул кеше миңа ничек карар?

– Безнең Исламда алай фәләнгә-төгәнгә мөрәҗәгать итүләр юк. Иман – вөждан таләбеннән гыйбарәт. Исламны кабул итәргә уйлаган кеше дөньяны барлыкка китергән бер көчнең барлыгын һәм берлеген кабул иткәннән соң, инсан углының пәйгамбәрләргә ихтыяҗы булуын да расласа, Исламга кергән була. Башка берни дә кирәкми. Аллаһ белән аның коллары арасында, хөкемнәрен җиткерү өчен арадашчы бары тик пәйгамбәрләр генә була ала.

Пәйгамбәрләрдән башка арадашчыга ихтыяҗ юк. Кем генә булса да, вөжданы белән Аллаһының берлеген расласа, пәйгамбәрләрне һәм шулар арасында Хәзрәт-е Мөхәммәтнең пәйгамбәрлеген кабул итсә, шул җитә, безнеңчә, ул кеше – мөселман.

– Ә ничә никах кирәк?

– Сез мыскыл итәргә җыенасыз, ахрысы. Мине һәм минем динемне хурларга Сезнең хакыгыз юк.

– Зинһар, гафу итегез. Һич кенә дә хурларга исәбем юк. Нигә хур күрим? Киресенчә, зур ихтирам белән мәгълүмат алырга телим.

– Ислам дине һичбер вакыт берәүнең дә шәхси ирегенә басым ясамый. Хатын-кыз мәсьәләсе кеше өчен табигый тормыш мәсьәләсе булып тора, дин мәсьәләсе түгел. Шунысы бар, Исламга кадәр, гарәпләрдә хатын-кыз хокукы аяк астына салып тапталган була. Ул заманнарда ир кешегә теләсә күпме хатын алырга, йөзләрчә хатын белән никахлашырга рөхсәт ителгән. Ислам дине килгәннән соң, бу хәл чикләнгән. Дүрттән артыгы хәрәм дип белдерелгән, ләкин дүрт хатын алу кирәк һәм тиеш диелмәгән. Бары тик шулай кирәк булса гына рөхсәт ителгән. Хәтта бу рөхсәт тә гаделлек белән кабат искә алынып, «Никадәр теләсәгез дә, хатыннарыгыз арасында гадел була алмассыз...» (Ниса, 129) аяте белән ныгытып куелган.

– Шулаен шулай да, тик хатын-кыз мәсьәләсе бик мөһим мәсьәлә. Хатыннарга да эшләп табу хокукы бирелгән булса иде. Ире вафат булса, яисә башка очракта, кирәк булганда үзен-үзе карый алырлык кадәр ирек бирелергә тиеш иде.

– Гафу итегез! Без дин турында сөйләшәбез, гореф-гадәт турында түгел. Сез исә менә хәзер гадәт турында сөйлисез. Безнең шәрык халкында күбесенчә шулай, ләкин бу – гадәт.

– Диннең дә йогынтысы булмый калмагандыр. Төркестанда хатыннарга һич хөрмәт юк, алар кешелек хисләреннән бөтенләй мәхрүм. Аларга да бу хаксызлык дин кушуы белән эшләнгәндер, дип уйлыйм.

– Булуы мөмкин, ләкин Сез мәсьәләнең нигезен бераз үзгәртеп җибәрдегез. Хатын-кыз хокукы – аерым, гадәт – аерым. Бүгенге көндә сезнең хатын-кызыгыз гаять ирекле, һәр эштә ирләр белән янәшә торалар, тик хокукта тигезләрме, юкмы – бу башка мәсьәлә. Без әлегә Аврупа хатыннары арасында бер генә генерал да күрмәдек, дипломат та юк. Мирас мәсьәләсендә исә өлешләре – җидедән бер. Ә менә Ислам буенча, икедән бер. Белмим инде, кайсысы күбрәк хокукка ия икән?

Шул арада янибызга ике хатын килде. Безнең сөйләшкәннәребезне башта тыңлап тордылар. Мин сүземне шулай дәвам иттем:

– Хатын-кызны мөмкин кадәр ачып, аларның көчсезлегеннән файдалану – хокукларын яклау була алмый. Әгәр бүген мәдәнилек, кешелек пәрдәләре артына сыенып, хатын-кызны алдау, нәфес таләбе булган табигый теләккә буйсындыру хо-

кукка хөрмәт дип карала икән, безнең Ислам ул кадәренә инде рөхсәт бирә алмас.

Ханымнарның берсе сүзгә кушылды:

– Көчсез һичбервакыт көчле алдында үзен яклый алмый, Сезнең фикерегезгә кушылам. Мин үзем шактый күрдем, безнең христианлыкта хатын-кызның пәрдәләре ачылган, ләкин хокуклары аяк астына салып тапталган. Дөресен генә әйткәндә, ирләр безнең белән түгел, малыбыз белән өйләнешәләр. Безгә өйләнер алдыннан, аталарыбыздан: «Кызыңны алам, ләкин бирнәсе бармы, никадәр булачак?» – дип сорыйлар. Бирнәсез кызлар кияүгә чыгу хокукыннан бөтенләй мәхрүм.

Хатыннарның икенчесе болай дип өстәде:

– Мөселман хатын-кызларының пәрәнҗә киюе безнең өчен бик кыен мәсьәлә булып тора. Ләкин шунысы бар: аларның өйдә, гаиләдә яшәешләре күбрәк тәртипкә салынган. Безнең мөселман күршеләребез бар, бик якын аралашып яшибез. Алар – өй эчендәге бар нәрсәнең тулы хокуклы хуҗабикәләре, ни теләсәләр – шуны эшли алалар, иреклеләр. Бары тик ирләр белән бергә утырмыйлар гына. Ә менә үзләре моннан бик канәгатьләр, һич зарланмыйлар. Ләкин бу безнең өчен мөмкин хәл түгел, чөнки без инде шулай күнеккән.

Мин, сүзгә катнашып, болай дидем:

– Бөтен милләтләргә дә үз гадәтләре яхшы булып күренә. Күршем белән безнең сүзебез дин турында иде. Ярар, туктатыйк алайса.

– Юк, юк, дәвам итегез! Безгә дә файдалы булыр, – диештеләр хатыннар. Мин, сүз тыңлап, дәвам иттем:

– Дин бар, аннан башка әле тагын дин исеме белән башкарыла торган шактый гына нәрсәләр дә бар. Боларны аера белергә кирәк. Мәсәлән, сезнең Христианлыкта поп әфәнденең гөнаһларны гафу итү күренеше бар. Кешенең үз теле белән гөнаһларын поп каршысында тануы бик авыр нәрсә. Бигрәк тә әгәр гөнаһ эшләгән кеше попның улы яки кызы, хатыны булса, ничек танырга кирәк, җир йөзендә моннан да авыррак бер мәсьәләне күз алдына китерергә мөмкинме?

Хатыннар икесе бергә диярлек:

– Бик ямьсез, бик ямьсез.., – диделәр. Шуның артыннан ук берсе болай диде:

– Мин моңа һич кенә дә ышана алмыйм. Бу – попларның хәйләсе.

Күршем дә:

– Моңа беркем дә ышанмас! – диде. Мин исә сүземне дәвам иттем:

– Әгәр дә бу – диннең нигезендә икән, моңа ышанмасагыз, якламасагыз, христиан була алмаячаксыз.

Шул арада безнең купе ишеге төбенә тагын берничә кеше килде. Алар да сүзгә катнаштылар. Шул рәвешле халыкара конференция дип әйтерлек җыелыш җыелды. Купега сыя алмадык, коридорга чыктык.

Берзаман мәсьәлә Думага күчте, аннары Милли җыен мәсьәләсе күтәрелде. Милләтнең киләчәге турында сүз башлануга ук, һәрберсенең кем икәне һәм нинди милләт кешесе булуы ачыкланды. Безнең вагонда дүрт поляк, ике яһүди, ике алман, бер татар, бер малорос хатыны, өч рус хатыны, бер эстон кызы һәм бер француз кызы бар икән. Боларның һәрберсе үз милләтенә шулкадәр җан ата иде ки, һәрберсе бөтен изгелекләрне, яхшылыкларны үз милләтенә бирергә, аныкы дип санарга тели иде.

Сөйләшү миллияткә кагылышлы шундый фикерләр эчендә чайкалып торганда, кабат дин мәсьәләсенә әйләнеп кайтты һәм милли төрлелек кинәт азайды. Мөселман буларак, мин аерылдым, ике яһүди исә мусавилеккә, ягъни иудаизмга булган бәйлелек һәм хөрмәтләрен белдерделәр. Юлдашлар арасында миннән башка университет бетермәгән кеше юк иде, мөгаен. Сөйләшүләреннән моны аңлап була иде. Дин белән бик ул кадәрле якын мөнәсәбәтләре булмаса да, үз диннәрен яклауда икеләнеп тормадылар, ул гына да түгел, диннәрен изгеләштерү, күкләргә кадәр күтәрү өчен тырышыпмы-тырышалар иде.

Мин дә Ислам диненең матур сыйфатлары турында сөйләргә тотындым. Бераздан тәслис, ягъни «святая троица» турында да сүз чыккач, аны акыл белән кабул итү мөмкин түгеллеген әйттем. Аннары сүземне шулай дәвам иттем:

– Тәслис ул шундый мәсьәлә ки, һичбер акыл аны кабул итә алмас. «Аллаһ өч тә, бер дә! Ләкин шул ук вакытта берберләреннән аерылуы да мөмкин түгел», – диелә. Алай булгач, яһүдиләр Гайсәне үтергәндә, өчесе бергә үлгән булырга тиеш түгелме соң инде, чөнки «аерылулары мөмкин түгел» дисез. Ярар, шулай да булсын, соңыннан боларны кем терелтте соң? Инде болай булгач, дүртенче тәңрегә ихтыяҗ туды бит.

Шул арада без Обь станциясенә килеп җиткәнбез. Барысы да, җыелышып, кичке аш ашарга, дип киттеләр, бәхәс туктады. Инде вакыт бик соң иде, мин, урынымны әзерләп, йокларга яттым. Күп тә үтмәде, күршем кире килде. Юк-бар сөйләшеп, бераз вакыт уздырдык, шаярышып көлештек. Бераздан, әңгәмәне дәвам итә алмаганга күршемнән мине кичерүен сорадым, шунда ук йокыга да киттем.

Иртән иртүк күземне ачуга, ишетәм: күршем миннән дә иртәрәк торган, купесында кыштырдый иде инде.

– Күршем, нинди төш күрдең? – дип сорадым аннан.

– Бик гаҗәеп төш күрдем, – диде. – Куркып уяндым, йоклый алмагач, тордым.

– Хәерлегә була күрсен!

– Хәере никадәр булыр, белгән юк. Төштә зур концертта утырабыз икән, дим. Бөтен дәүләтләр матәм эчендә. Араларында бер чалмалы бар, тәмәке тарта һәм шулкадәр күп төтен чыгара, хәтта: мәҗлестәгеләрнең йөзләре күренми иде.

– Хыял. Сезнең кебек джентльменга мондый хыял төс түгел. Башка берәү мондый нәрсә сөйләсә, Сез шаркылдап көләр идегез. Сез, ихтимал, моны сөйләп, мине ышандырырмын, дип уйлыйсыз. Безнең динебездә матәм юк. Мондый төшкә бездә, хыял, диләр, – дип көлдем.

– Мин Сезгә чынлап күргән төшемне сөйләдем. Чынлап та бик курыктым. Безнең русларда, төштә матәм күрү – бик начар, дип санала.

Без күршем белән шулай көлешеп сөйләшә идек, яңа юлчы керде. Миңа:

– Буш урын бармы икән? – диде.

– Рәхим итегез, бар, – дидем.

Яңа күршебезнең шәрык милләтеннән икәнлеге йөз-кыяфәтеннән билгеле булса да, кем икәнлеген белеп булмый иде.

– Сез кем? – дип сорадым.

– Якут, – дип җавап бирде. Бик тә яхшы булды әле, якутлардан таныганбелгән кешем моңарчы юк иде.

– Әйдәгез, танышыйкчы, минем исемем Габдерәшит, мин – татар, – дидем.

– Ә мин – якут, – диде. – Фамилиям – Михайлов.

Бу миңа бик сәер булып ишетелде.

– Бу бит чын рус фамилиясе, – дидем.

– Инде безнең якутлар да рус булып беттеләр. Православие динен кабул итмәгән якут калмагандыр инде. Мин үзем дә, теләсәм-теләмәсәм дә, Михайлов булдым.

– Русларда бер кагыйдә бар: православие динен кабул иткәннәрнең исемен генә үзгәртәләр, фамилиясе кала.

– Безнең якутларда болай да фамилия дигән нәрсә юк, бөтен кешегә исеме белән генә эндәшәләр. Якутларны православие диненә керткәннән соң, безгә койрык та тактылар. Ләкин койрык безнеке түгел, русларның бүләге.

– Православие динен кабул иткән кешеләр канәгатьме соң?

– Православиенең ни икәнен белсәләр, бәлки канәгать булырлар иде. Ләкин безнекеләр арасында алай аңлап-белеп православный булганнар юк. Кайчандыр бер поп бер жандарм кешесе белән килгән: «Дин – менә шушы жандарм!» – дигән, шуннан соң православный булганнар. Элеккерәк вакытларда православие динен кабул иткән кешеләргә милләт нәфрәт белән карый иде, ләкин тора-бара хөкүмәт шундый юлга басты: ике якут дәгъвалаша

Шаман

икән, берсе православие динендә булса, шул җиңә. Православие динен кабул иткәннәргә өстенлекләр бирелде, ихтирам күрсәтелде. Хәзерге вакытта бөтен якутлар да православный булдылар, ләкин рәсми булмаса да, шаманлык һәрвакыт яшәде һәм яши. Безнең якутлар православиене күпме генә күңелдән кабул итсәләр дә, бу яктан күпме генә катгый булсалар да, шаманлыктан бөтенләй ваз кичә алмаячаклар. Берәр мәсьәлә килеп чыкканда, православиедән өмет өзеп, шаманга мөрәҗәгать итәләр, рус поплары биргән потларны, такталарны бер якка атып, Ялпак Тостан шифа сорап ялваралар.

– Зинһар өчен, миңа шаманлык турында бераз мәгълүмат бирегезче. Шаманлык нәрсәне аңлата? Шаман нәрсә? Ялпак Тос[2] нәрсә?

– Безнең шаманлык будда диненең бер мәзһәбе булып тора. Шаман исә безнең мәзһәпнең рәисе кебек. Ялпак Тос исә – безнең изге чарабыз. Аның аша без шифа сорыйбыз. Кирәк булганда аның өчен корбан чалабыз.

– Будда динендә җан иясен үтерергә ярамый бит, сез ничек алай корбан чаласыз соң? Аңлый алмыйм.

– Әгәр ашар өчен булса, дөрес, ярамый. Ләкин фида буларак мөмкин, корбан – фида. Шул ук вакытта, Будда дине бик күп үзгәреш кичерде, бозылды. Ламаларда корбан юк, ләкин аларда булган ямьсезлекләр безнекеннән дә начаррак. Табына торган урыннарына кереп күрсәгез иде: дин һәм мәзһәп исеме белән тәңрене дә саталар.

– Нинди ямьсезлекләр, начарлыклар бар? Сөйләгез әле.

– Юк, сөйли алмыйм, монда хатын-кыз бар.

Дөрестән дә, күршебездәге хатыннарның берсе безнең сөйләшкәнне тыңлый иде.

– Күп нәрсәне хатын-кыз янында сөйләшергә дә ярамый, ә тәңре каршысында ярыймы? Була торган хәлме бу?

– Әйтерең бармы, әфәнде, ниләр генә юк, ниләр генә....

Мин, күршедәге хатынга карап: «Сезнең монда булуыгыз бик яхшы, ләкин, форсаттан файдаланып, безне күп әйбер белүдән мәхрүм иттегез», – дигәч, ул, урыныннан торып: «Тәңреләрнең бездән куркучылары да бар икән...», – диде һәм җитез генә китеп барды. Күпме генә: «Утырыгыз, китмәгез», – дисәк тә, туктамады.

Яңа күршемә:

– Ханым китте, – дидем. – Инде безгә ламаларның тәңреләре турында сөйләсәгез дә була.

– Ир белән хатыны арасында күз алдына китерергә мөмкин булган ямьсез мөгамәлә шәкеле, табыну урыннарында, изге урында тора һәм аны тәңре дип кабул итеп, изге дип санап үбәләр. Будда динендәге ямьсез, начар нәрсәләрнең һәммәсен дә сөйләп булмый, үзләре дә яшерәләр, табыну урыннарының, ягъни храмнарының

[2] Ялпак Тос – шаманнарның тәңреләренең исеме булса да, төрки телдә «ки» дигәнне аңлаткан ялпак һәм «күкрәк» мәгънәсендәге тос сүзләреннән барлыкка килгән кушма исем булып тора. Мин, бу мәгънәләрнең монда нинди катнашы барлыгын белмәгәнгә, сорадым (Габдерәшит Ибраһимов искәрмәсе).

ул бүлеменә Лама мәзһәбендә булмаган бер генә кеше дә керә алмый.

Безнең беренче танышкан күршебез сәер генә итеп:

– Дөресен әйткәндә, бу мәзһәп картларга төс икән, – диде.

– Господин Михайлов, сезнең якутларда укыган, белемле кешеләр бармы? – дип сорадым.

– Бездә югары уку йортында укыган кешеләр бик аз, юк, дип әйтерлек. Милли мәктәпләребез юк, бөтен мәктәпләр миссионерлар тырышлыгы белән ачылган. Аларның максатлары мәгълүм. Бездә белем мәктәпсез генә барлыкка килгән, ә хәзер инде мәктәп ачуның кирәге дә калмаган.

– Сездә җир мәсьәләсе ничек тора? Үзегезнең җирләрегез бармы? Җир сезнең шәхси мөлкәтегез була аламы? Кеше башына никадәр җир туры килүен белеп буламы?

– Бездә күбесенчә сазлык җир, тундра. Уңдырышлы җир бик аз. Инде Русиянең эчке төбәкләреннән бик күп кеше күчеп килеп утырды, әле дә киләләр. Әлегә мохтаҗ булмасак та, бер көн килеп, җиргә мохтаҗ булачакбыз.

Шулвакыт яныбызга кондуктор килде, билетларны җыеп алды. Томск шәһәренә китәчәк юлчылар өчен бераздан күчеп утырырга кирәк булачагын әйтте. Без әйберләребезне җыйдык, әңгәмәне дәвам итәр өчен вакыт җитмәде.

Якут күршебез миңа болай диде:

– Мин Сезне күптәннән беләм, Сезнең турыда мәкаләләр укыганым бар. Фикерләрегезгә тулысынча кушылам: безнең рус булмаган халыклар – инородецлар үлемгә хөкем ителгән. Русиянең эчке сәясәте шундый. Безнең якутлар, бурятлар инде үлә баралар, буыннар кырыла. Гомумән, Себердәге бөтен инородецларда буыннар көчсезләнүе күзәтелә, тик безнең якутлар барысыннан да тизрәк юкка чыгарлар, ахры.

– Бу көчсезләнүгә, юкка чыгуга йөз тотуның сәбәбе ни икән соң?

– Бик күп эчүдән, дип уйлыйм. Руслар яулап алганнан соң, эчкечелек күбәйде.

– Руслар яулаганчы эчкечелек юк идеме?

– Бар иде, тик безнең аракы сөттән җитештерелә, зарарлы түгел иде. Хәзер исә саф спирт куллану җәелде, поплар безне нәкъ менә шуның белән ауладылар да инде.

Поезд Тайга станциясенә килеп туктады. Монда безгә күчеп утырырга кирәк булачак. Кызганыч, бу матур, файдалы әңгәмәдән аерылдык.

Тайга станциясе Себер тимер юлында иң яхшы, төзек станция иде. Монда бер сәгать көткәннән соң, Томск шәһәренә киттек. Озак барасы түгел, өч сәгатьтән соң Томскида булачакбыз. Вагонда кеше бик күп, чөнки «куян» дигән качып баручы юлчылар күп. Мин, бу «куян»нарны күреп, янымда утырган юлчыга: «Русия тимер юллары кайчанга кадәр бу «куян»нарны ташыр икән?» – дидем. «Руслар төлке булганга кадәр», – дип җавап бирде ул. Якын-тирәдәгеләр кычкырып көлештеләр. «Куян»нарны бик орыштылар, төрле сүз сөйләнде.

Шулвакыт берәү сүз арасында: «Ни өчен бу Себер тимер юлы Томск кебек әһәмиятле шәһәрдән бу кадәр ерактан үтеп киткән икән, ә? Тоташтыручы юл төзисе урында, олы юл турыдан-туры Томск шәһәре яныннан ук үткән булса, ярамый идеме, йә?» – дип сорады.

Бер хәрби болай дип җавап бирде: «Геометрия белгечләре юлны менә шушылай салуны уңай дип тапканнар. Әгәр ул вакытларда Томск шәһәре үзе дә бераз тырышкан булса, һич югы бер илле-алтмыш мең сумлык бүләк тәкъдим иткән булса, һичшиксез, инженерларыбыз күчәрне шул якка борган булырлар иде. Илдә ришвәт яшәгәндә, туры юл бик күренми шул».

Өч сәгатьтән соң, Томск станциясенә килеп туктадык. Мине каршыларга мөгаллимнәр һәм шәкертләр килгән иде.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе.* ■

2018 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ КӨННӘР

Мөселман ай календаре буенча 1439-1440 һиҗри еллар

19 март – мөселман календаренда изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим (г.с.) пәйгамбәрнең, Гайсә (г.с.) пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук *кече хаж, гомрә хаҗы* кылына.

22 март – Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич *Рәгаиб кичәсе* дип атала. Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

13 апрель – *Мигъраҗ кичәсе*. Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә – Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 көн ураза тотуга тиңләнә.

30 апрель – *Бәраәт кичәсе*, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәлләрен һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышларын билгели.

16 май – изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн.

21 май – Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

15, 16, 17 июнь – Гайдел-фитыр, Ураза бәйрәме.

20 август – Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

21 август – Гайдел-Әдъхә, *Корбан бәйрәме*. Мөселманнарның иң зур (җомга көн һәм гает) бәйрәмнәренең берсе. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан Җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

20, 21, 22, 23, 24 август – *Тәшрикъ көннәре*. Бу көннәрдә мөселманнар, фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап зикер әйтә.

11 сентябрь – *Һиҗри Яңа ел*. 1440 Һиҗри елның вә Мөхәррәм әл-Хәрам аеның беренче көне.

Яңа елыбызда дөнья вә ахыйрәт бәхет-сәгадәтенә алып бара, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирештерә торган гамәлләр кылырга насыйп булсын! Бу көнне Аллаһының ризалыгы өчен догалар, изге эш-гамәлләр кылып, хәер-садака биреп үткәрергә кирәк.

20 сентябрь – мөбарәк *Гашура кичәсе* көне. Мөхәррәм әл-Хәрам аеның 10 нчы көнендә Гашура бәйрәме билгеләп үтелә. Бу көннең фазыйләтләре һәм хикмәтләре бихисап. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) болай диган: *«Ибраһим галәйһис-сәлам Гашура көнендә тугандыр. Аллаһы Тәгалә аны Нәмрудның утыннан Гашура көнне коткаргандыр, юлның тугрысын да Гашура көнендә күрсәткәндер»*.

10 октябрь – һиҗри тәкъвим буенча елның икенче ае яки *Сәфәр әл-Хәер ае* башлана. Изге вә бәрәкәтле ай булуын Аллаһы Тәгалә насыйп итсен!

19 ноябрь – *Мәүлед-шәриф кичәсе*.

20 ноябрь – *Мәүлед бәйрәме* – пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) туган көн. Ул мөселман дөньясында зурлап билгеләп үтелә.

Төзүче-мөхәррир –
хаҗи **Абдулла Дубин**.

ГОСМАНЛЫ ХИКӘЯТЕ

ГАЛИМНЕҢ АТЫННАН ЧӘЧРӘГӘН ПЫЧРАК

*Сигез ай буе дәвам иткән Мисыр сәфәре тәмамлангач (1516-1517 еллар), Госманлы солтаны Явыз Сәлим Истанбулдан Анадолу казаскәре[1] олы галим Ибн-и Кәмал[2] белән бергә кайтыр юлга чыга. Кайткан чакта гаскәргә бик пычрак җирдән үтәргә туры килә. Бервакыт галимнең аты абынып ала һәм тояк астыннан чәчрәгән пычрак солтанның чикмәненә тия. Барысы да куркып кала, билгеле. Янәшәдәгеләрнең барчасы, хәзер нәрсә булыр икән инде, дип бер-берсенә карап ала. Олы галим Ибн-и Кәмал, башын алга иеп, борчылу күзләре белән солтанга карый. Олуг Солтан исә болай ди: **«Остазым, борчылмагыз! Сезнең кебек могтәбәр галим атының аягыннан чәчрәгән пычрак безнең өчен бер шәрәфтер»**. Һәм ул, пычрак чикмәнен салып, аны ярдәмчесенә тоттырган чакта: «Васыятем шушы: мин үлгәч, бу чикмәнне сандукамның (табутымның) өстенә ябсыннар», – дип әмер бирә. Солтанның васыяте үтәлә.*

Явыз Сәлим солтан (10 октябрь, 1470 ел – сентябрь 1520 ел) – Госманлының тугызынчы падишаһы. Ул 1512 елда тәхеткә утырганда Госманлы җирләре 2375000 квадрат метр булган, сигез елда Европа һәм Африка кыйтгаларына җәелеп, ике ярым тапкыр артып, 6557000 квадрат метрга җитә. Кырым ханы Миңлегәрәй үзенең кызын Явыз Сәлимгә кияүгә бирә һәм аның тәхеткә утыруына ярдәм итә. Гарәп-фарсы телләрен бик яхшы белгән Явыз Сәлим төрекчә шигырьләр язган, фарсы телендә иҗат ителгән әсәрләре Топкапы музеенда саклана, фарсыча язылган «Диван»ы 1906 елда Алманиядә яңадан нәшер ителә. Явыз Сәлим 1520 елда 49 яшендә вафат була, төрбәсе Истанбул каласының – Явыз Сәлим мәчете янында.

*Язманы журналга **Рәсим Хөснетдинов** әзерләде.* ■

---

[1]Казаскәр – галим сыйныфның дәүләт дәрәҗәсендәге иң олы вәкиле.
[2]Ибн-и Кәмал яки Кемалпашазадә (1469-1534) – Госманлы дәүләте шәйхелисламы, дөньяви һәм дини эшләрне башкаручы галим, факих (ислам хокукы белгече), тарихчы, тәфсирче, каламче, әдәбиятчы һәм шагыйрь.

Безнең мирас №12 декабрь 2017

Тормыш. Иҗат. Хәтер

Энгель Нигъмәтуллин

(Галимҗан Нигъмәтинең тормышы
һәм эшчәнлеге турында кайбер уйланулар)

Галимҗан Нигъмәти[1] 1918 елның декабреннән Көнчыгыш фронтның Бишенче Кызыл Армиясенең сәяси бүлеге органы «Кызыл яу» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли башлый. Газетаның беренче дүрт саны Бөгелмәдә дөнья күргән. Нәшрият та армия белән бергә хәрәкәт иткән. 1919 елда, Колчак гаскәрләре һөҗүме аркасында, Кызыл Армия частьлары Уфаны вакытлыча калдырырга мәҗбүр булган.

Кешеләр авырлыкларга түзгән, чөнки хыялларында инкыйлаб-яз образы яшәгән. Илдә барган вакыйгаларның әһәмиятенә чын күңелдән ышанганнар һәм бөек тарихи хәрәкәттә катнашулары белән горурланганнар.

Галимҗан Нигъмәти 1921 елның язында Мәскәүгә килә һәм Шәрык хезмәт ияләренең Коммунистик университетына (ШХИКУ) укырга керә. Әлеге университет Страстной (хәзерге Пушкин) мәйданындагы бинада урнашкан була. Анда, атап әйткәндә, А.В.Луначарский, Л.Б.Красин, тарихчы М.Н.Покровский, шәрыкне өйрәнүчеләр А.А.Губер, И.М.Рейснер, Б.З.Шумяцкийлар укыта. Университетта зур фәнни-эзләнү эшләре алып барыла, еш кына фәнни конференцияләр һәм диспутлар уздырыла.

Бу университетта, Галимҗан Нигъмәти белән бергә, Сафа Борһан, Ярлы Кәрим, Мәхмүд Максуд, Фатих Сәйфи, Нәкый Исәнбәт, Латыйп Гомәров, Исхак Еникеев та укыган. Г.Нигъмәти әдәби түгәрәк эшчәнлегендә актив катнаша, гектографта Һади Такташ та хезмәттәшлек иткән әдәби журнал бастырыла.

Студентларның тормыш шартлары бик авыр була. Ул вакытларны танылган журналист Сафа Борһан болай дип искә ала: *«Мәскәү. Югары уку йортының тулай торагы. Зур һәм кечкенә бүлмәләрдә сигез йөзгә якын студент. Температура сигез градус булса, кемнеңдер карары буенча, җылытырга ярамый. Ягулык кризисы. Бүлмәдә утыз-кырык студент. Сулышлары белән сигез градус температураны саклыйлар, шуңа күрә җылытырга да кирәкми. Кыш буе җылы бирмәделәр. Студентлар, кем нәрсә булдыра*

[1] Галимҗан Нигъмәти (Галимҗан Әмирҗан улы Нигъмәтуллин (1897-1941) – әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм педагог. Ошбу мәкалә авторы Э.Нигъмәтуллин (1930-2001) – Г.Нигъмәтинең улы, әдәбият галиме, педагог, тәрҗемәче

– шуны киделәр һәм каешларын каты итеп тартып бәйләп куйдылар. Кайберәүләре бияләйләр дә киделәр».

Г.Нигъмәти 1922 елның башында Идел буендагы һәм көньяк губерналардагы ачлык турында илебез башына төшкән коточкыч бер афәт буларак яза. Кулдан килгәнчә ачларга булышу – безнең бурычыбыз, ди ул: йә паегыңның уннан бер өлешен бирәсең, яки ун кеше бер баланы ашатасың. «Азык-төлегебезнең бер өлешен биреп, без ачыгачакбыз; яртысын бирсәк тә, ачтан үлмәячәкбез бит, ә шуның белән ничә кешенең гомерен саклап калачакбыз». Авыр елларда халык фаҗигасенә кешеләрчә мөнәсәбәт белдерү мөһим була. Әлбәттә, студентларның болай да җитәр-җитмәс паегының бер өлеше миллионнарча ачларны һәм ачлыктан үлүчеләрне коткарып калу чарасы була алыр идеме

икән?! Әмма теләктәшлек, чит кешенең кайгысын буш сүзләрсез генә уртаклашырга әзер булуны беркем дә инкарь итми. Һәрберебез, хәтта шактый тәҗрибәле кешеләр дә, билгеле бер рухи-әхлакый үсеш баскычларын уза. Җитмәсә, идеология өлкәсендә эшләүче булса, дөреслек турында сөйләгәнче, үзен сынап карарга, чистарынырга тиеш. Юкса, аның бөтен тормышы ялганга әвереләчәк.

Галимҗан Нигъмәти 1922 елның сентябреннән 1924 елның июненә кадәр Дәүләт журналистика институтында укый. Бу уку йортының методикасы – студентлардан газетада эшләүче генә түгел, күпьяклы журналист, җитди публицист, сәяси һәм җәмәгать хезмәткәре дә әзерләү. Институт образы аның хәтеренә нык сеңеп кала. Анда Гобәйдулла Кушаев, Шакир Рәмзи һәм Г.Нигъмәтинең Казан газета һәм журнал нәшриятларында алга таба бергә эшләячәк башка хезмәттәшләре дә укыган. В.Л.Львов-Рогачевский һәм П.С.Коганның әдәбият тарихы турындагы эчтәлекле, ачык лекцияләрен яратып тыңлаганнар. Н.К.Иванов-Грамен һәм Ф.Г.Мускатблит та, публицистика теориясе турындагы лекцияләрен кызыклы итеп үткәреп, студентларның игътибарын җәлеп итә алганнар. Төрле яклап ачылу, һөнәр үзләштерү өчен мөмкинлекләр күп булган: Мәскәү газеталары нәшриятларында вакытлы эшкә, театрларга, музейларга, төрле лекцияләргә йөрү. Әлеге институт студентлары политехника музеендагы диспутларда катнашкан, университетта лекцияләр тыңлаган.

Шул елларда газет-журналларда Галимҗан Нигъмәтинең мәкаләләре күренә башлый, ә 1925 елда «Әдәбият мәйданында» дигән китабы басылып чыга.

Мәскәүдә Галимҗан Нигъмәтинең дуслары, фикердәшләре барлыкка килә. Алар арасында әхлакый-интеллектуаль мохит урнаша. Дусларының берсе – Һади Такташ. Шулай да Такташ берара Нигъмәтигә үпкәләп тә йөри. 1926 елның 3 апрелендә ул М.Максудка болай дип яза: *«Мәхмүт! Картлар яшьләр әдәбиятын онытырга тырыша. Мәскәүдә дә шулай, ахры. Галимҗан Нигъмәти халык хрестоматиясен бастырып чыгарды, анда яшьләрнең бер генә әсәре дә урын алмаган. Яңа әдәбиятның мәктәпләргә дә килер вакыты җиткәндер. Әйт әле аңа, мондый консерватизм белән җинаять кылмасын».*

Үпкәләү сизелә, ләкин дошманлык юк. Уртак әрнү, бәла һәм үпкәләрнең кайнар чолганышы бу...

1926 елның ноябрь аенда Галимҗан Нигъмәтине Татарстанга җибәрәләр. Ул «Кызыл Татарстан» газетасына мөхәррир итеп билгеләнә һәм анда 1928 елга кадәр эшли. Галим 1926 елда басылган «Безнең әдәбиятыбыз турында» дип исемләнгән мәкаләсендә татар совет язучыларының киң, күпкырлы оешмасын булдыру турындагы мәсьәләне күтәреп чыга. Язучылар җәмгыятенең бурычларын Галимҗан Нигъмәти шулай күз алдына китергән: үз юлыңны табарга булышу, мөмкинлекләреңне һәм сәләтеңне нәтиҗәлерәк куллану.

Галимҗан Нигъмәти 1928 елның 25 апрелендә «Кызыл Татарстан» газетасында «Татарстан язучылары җәмгыятен күптән төзергә кирәк иде» дип исемләнгән мәкаләсен бастыра. 5 нче май көнне Татар мәдәнияте йортында узган татар әдәбиятчылары җыелышында Язучылар җәмгыяте оешу турында рәсми белдерү ясала. Аның бюросына Г.Нигъмәти, Ф.Сәйфи, Г.Толымбай, Г.Кутуй һәм К.Тинчурин сайлана. Татар Язучылар җәмгыятендә, ТАППдан аермалы буларак, бөтендөнья мәдәниятенә зур хөрмәт белән карый торган саллы белемле язучылар күп була. ТАПП әгъзасы К.Нәҗми Г.Ибраһимовны, Ф.Сәйфине, Ш.Камалны, М.Гафурины, Г.Камалны, М.Галине һәм К.Тинчуринны «вак буржуаз язучылар» дип атый, чынлыкта исә алар – ышанычлы һәм дөреслек белән үз халкына хезмәт итүче демократ зыялылар.

Татар әдәбиятының тарихын өйрәнүне, рухиятнең тирән катламнарын ачарга

кирәклекне аңлаган Галимҗан Нигъмәти. Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) әсәрләренең җыентыгын чыгаруда башлап йөрүчеләрнең берсе була, аңа багышлап кереш мәкалә дә яза.

Татар язучылар җәмгыяте эшчәнлегенең ачык бер мисалы – әдәбиятчыларыбызның ил буйлап сәяхәте. Язучы-тәрҗемәче Сәрвәр Әдһәмова мондый сүзләр язып калдырган: *«1929 елгы сәяхәт күп кенә язучыларыбызның тагын да ныграк якынаюына, дуслашуына сәбәпче булды. Пароходта булсынмы ул, без йөргән урыннармы – бер гаилә булып яшәү һәм шул ай ярымлык тәэсирләр берләштерде безне.*

Ул вакытларда пароходлар хәзергегә караганда акрынрак йөзә иде әле. Безнең Казаннан Әстерханга Идел буйлап сәяхәтебез биш-алты көнгә сузылды. Ул көннәр, бигрәк тә кичләре бәйрәм кебек шундый күңелле үтә иде. Август ае, эссе көннәр. Көндезләрен күп вакытны палубада ышыграк җирдә үткәрә идек. Ара-тирә күрше бүлмәләрдән шигырь укучы Такташ, Кутуй тавышлары ишетелә. Тугандаш республикаларда чыгыш ясарга әзерләнүче Демьян Фәтхи тавышы да кушыла аларга.

Ә кичләрен, һава бераз суына төшкәч, без салонда җыелабыз. Салих Сәйдәшев пианино артына утыра иде дә, беренче аккордлары белән үк тирә-юньне таң калдыра иде. Без кайсыбер көйләренә кушылып китәбез. Җыр, көй тавышына бөтен пассажирлар да җыела. Салон эченә сыеп бетмәгәннәр палубадан яки тәрәзәләрдән багып тыңлыйлар. Идел өстендә Сәйдәш көйләре яңгырый. Ул уйнап арыгач, уеннар, шаярулар башлана. Такташ та, Кави да, журналист Исмәгыйль Рәми дә, юмор дигәндә, кеше кесәсенә керми. Ә инде артист Шакир Шамильский яисә Кәрим Тинчурин сөйләргә тотынса, бернинди театр да кирәкми!»

Галимҗан Нигъмәти һәрвакыт тормыш үзәгендә, һаман да язу белән мәшгуль була. Язучы Ибраһим Салахов ул вакытлар турында, Татар мәдәнияте йортындагы чыгышларны искә алып, болай ди: *«Сәхнәдә, өстәл артында регламентны кайгыртучы «хуҗа» күренми. Теләгән кеше чыга, ошаганын укый, кайчан тели – шунда төшеп китә. Сәхнәгә алмашка залдан башкалар менә. Кыюраклар, өлгеррәкләр.*

Ниһаять, башка теләүчеләр юк. Менә шунда сәхнәдә укылган әсәрләр турында фикер алмашу башлана. Һәм монда даулы иреклек. Телисең икән, сәхнәгә мен яисә урыныңнан сөйлә. «Сепаратор» – нигездә язучылар кулында. Һәммәсе дә ярсып-ярсып сөйли, кемнедер күккә чөяләр, кемнедер «дөмбәслиләр». Әмма зал ике кешедән нәтиҗә ясауны көтә. Менә алар урыннарыннан күтәреләләр. Иң элек кыскарак буйлы, чандыр, һәрвакыт тере, тынгысыз Гомәр Гали тора – торышка сөйли башлый. Трибуна янына килми, сәхнәдә йөри. Тән төзелешенә туры килми торган чиста, яңгыравыклы тавыш. Куллары һәрвакыт хәрәкәттә. Алар сөйләүченең тавышын өскә күтәрәләр, йомарлап укмаштыралар һәм таш итеп залга ташлыйлар. Зал тетрәнеп китә. Гомәр Гали үзенең сүзен инде урынына утырган хәлдә тәмамлый.

Ә хәзер икенче нотыкчы. Бу – Галимҗан ага Нигъмәти. Буе белән Гомәр Галидән озынрак. Тазарак. Ашыкмый. Тыныч. Һәрвакыт пөхтә итеп киенгән: соры костюмнан. Ак күлмәк. Кара галстук (ул елларда галстук тагу пролетар этикасы нормаларын бозу дип саналган. Аның урынына төрле төстәге шарфлар бәйләп кую модага кергән була). Әкрен генә урыныннан тора. Як-ягына карамыйча, әкрен генә атлый һәм трибуна артына килеп баса. Башын әз генә күтәрә төшеп, уйланып залга карый. Көл төсендәге чәчләре баш артына тарап куелган. Йөзе ачык, мөлаем. Күксел күзләре тыныч һәм уйчан.

– Гражданнар, – дип, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән, тыныч кына башлый ул чыгышын.

Гомәр Галинең бик көчле чыгышыннан соң гөрелдәгән зал кинәт кенә тынычланып кала. Алдан чыгыш ясаган нотыкчыдан аерылып торган Г.Нигъмәти урыныннан куз-

галмый, кулларын селтәми. Тавышы бик тыныч. Ләкин бу тынычлыкта ниндидер сихри көч сизелә. Ул бөтен залны сихерли, үзенә карата, җибәрми, тын да алмыйча тыңларга мәҗбүр итә. Тирән уй, төпле, ышандыргыч дәлилләр. Максаты изге: сәхнәгә күтәрелгән һәр шагыйрь, прозаикка иҗат юлын күрсәтү, яхшы хирург шикелле, авырттырмыйча гына, иҗатларындагы кимчелекләрне күрсәтү һәм ярдәм итү».

Хәсән Туфан – Г.Нигъмәтинең иң яраткан шагыйрьләренең берсе. 1929 елда Г.Нигъмәти шагыйрьнең беренче шигырьләр җыентыгын чыгара. Ф.Сәйфи Г.Нигъмәтигә үзенең «Өч нарат» дигән романы турындагы фикерләрен җиткерә.

Мөхәммәт Мәһдиев Г.Нигъмәти турында болай яза: «*...Ул әдәби процесста яңа үсеп килүче сәләтләрне күрсәтә алды, Туфан, Такташ иҗатларын пропагандалады. Тагын бер хәл: ул «исемсез» язучыларның киләчәген билгеләде. Мәсәлән, Нигъмәти, беренчеләрдән булып, яшь Газинең, Әмирнең уңышлы киләчәген күреп алды һәм бу турыда матбугатта язып чыкты»*.

Тәнкыйтьче, беренче чиратта, яшьләр иҗатында яңалык һәм күрә белү үзенчәлеген, тапталмаган әдәби чишелешләр таба белү осталыгын эзли. Г.Нигъмәти, үз бәясен көчләп такмыйча, вакытның яхшы хөкемдар булуына ышанып, иптәшләренең фикерләренә колак сала. Ләкин ул, шәхеснең әхлакый абруена тискәре йогынты ясауны күреп алса, шунда ук көрәшкә ташлана.

1934 елның 15 декабрендә Татарстан Язучылар берлеге идарәсе утырышында Ф.Сәйфинең К.Тинчуринны әдәби караклыкта гаепләгән гаризасын тикшерәләр. Сүз Ф.Сәйфинең «Дошманнар» һәм К.Тинчуринның «Җилкәнсезләр» әсәре турында бара.

Г.Нигъмәти, беренчеләрдән булып, К.Тинчуринны яклап чыга:

– Фатыйх та, Кәрим дә комиссия карарына каршы килмәделәр. Кайбер охшашлыкларның булуы әдәби караклык турында сөйләргә җирлек бирми. Әдәбиятта андый мисалларны күпләп табарга була. «Фауст»ка кадәр аның сюжеты буенча бик күп әсәрләр язылган була инде. Шекспир әсәрләре турында да шуны ук әйтергә була. «Җилкәнсезләр» һәм «Дошманнар» пьесалары арасындагы охшашлык – кечкенә һәм гадәти мәсьәлә.

Шәриф Камал да Галимҗан Нигъмәтинең фикерләрен бик кыю хуплый:

– Монда әдәби караклык турында сүз бара алмый. Хлестаковка охшаш образлар элек тә язылган һәм соңрак та язылачак.

1929 елның көзендә Галимҗан Нигъмәти Көнчыгыш педагогика институтына эшкә керә. Август ахыры. Институт студентлары җәдвал янында җыелышып тора. Тапкыр сүзле Солтан Байков калганнарны үз янына чакыра:

– Кем яңалык ишетергә тели? «Татар әдәбияты» һәм аның янына «доцент Г.Нигъмәти» дип язганнар. Кем ул? Белгәннәр һәм күргәннәр кулларыгызны күтәрегез, яңалыклар белән бүлешегез!

Башкортстан студентлары елмая:

– Бу бит безнең Галимҗан абый, ватандаш. Башкорт далаларында кымыз эчкән, әйбәт һәм музыка яратучы халык арасында яшәгән!

Әдәбият сөючеләр «Безнең юл», «Яңалиф» журналларында, «Кызыл Татарстан» газетасында басылган Г.Нигъмәтинең мәкаләләрен укып бара.

Галимҗан Нигъмәти XIX гасыр (1917 елга кадәр) татар әдәбиятын укыта башлый. Элекке студент, Галимҗан Нигъмәтинең укучысы Хатип Госман болай искә ала: *«1935 елның беренче сентябре. Без – Казан дәүләт педагогика институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә әле генә кабул ителгән студентлар. Аудитория. Һәркем үзенә урын сайлый. Беренче дәрес булачак. Кыңгырау шалтырый. Бөтенесе тынып калды. Көтәбез. Ишек ачылды. Без көткән кеше килеп керде һәм, туктап тормыйча, башын*

селкеп кенә безнең белән исәнләште дә кафедрага таба үтте... Үзалдына папканы ачып салды. Ике куллап кафедрага тотынды. Тыныч кына карашы белән аудиторияне айкап чыкты. Ашыкмый. Мөгаен, сүз сайлыйдыр... Менә, ниһаять, тыныч һәм тәэсирле тавыш яңгырады:

– Сәнгать ул – дөньяны образлар ярдәмендә үзләштерү юлы.

Кинәт бу фикер минем аңымны яктыртып җибәрде, ниндидер зур бер сер ачылгандай булды. Күңелемдә, тоньк шатлык хисе белән бергә аралашып, соклану хисе җанланды. Шул хәлдә минем аңым, рухи асылым лектор сүзләре артыннан юнәлде. Мин моңа кадәр таныш булмаган яңа, кызыклы, яңа мәгънәләр белән тулы дөньяга килеп эләктем, югалдым.

Үзенең киң белемлелеге белән ул безгә үрнәк иде. Аңлашыла, профессорның үз белгечлегендә белемле булуы гаҗәп түгел. Ләкин мәсьәлә башкада: белгеч әлеге хәтер байлыгын тыңлаучыга ничек, кайсы яктан ача бит. Монда иң кыйммәтлесе шул: белем байлыгы лекторның үз фикеренә, хисләренә, ышаныч символына әйләнергә тиеш. Шулвакытта гына аның кулланылмыйча яткан иҗади көче уяныр, шулвакытта гына аның лекцияләрендә җан, мәгънәвилек булыр, шулвакытта гына тыңлаучылар алдында аларга инде билгеле фактлар көтелмәгән яктан ачылыр...»

***

Галимҗан Нигъмәтиләр гаиләсе Тельман урамында урнашкан агач йортның икенче катында яшәгән. Тар баскычтан менеп, уртак аш бүлмәсен узасың, ә алдарак – озын коридор. Сул якта ике бүлмәле фатир. Кечкенәрәге – йокы бүлмәсе дә, китапханә һәм эш бүлмәсе дә. Зур бүлмәнең тәрәзәсе янында шактый нык кисмәктә роза гөле үсеп утыра. Аның янында бу өйгә еш килүче кунак – Һади Такташ утырырга яраткан. Бүлмә уртасында озын өстәл. Галимҗан Нигъмәти, шушы өстәл артында утырып, машинкада басылган кульъязмаларны төзәткән. Өстендә ап-ак күлмәк, җиңнәрен терсәкләренә кадәр сызганып куйган. Гомумән, пөхтә һәм матур киенү – яшь чагыннан ук килгән гадәт. Бүлмәдәге тынлык еш кына кунаклар килү белән бозыла. Кави Нәҗми, Гомәр Гали, Гомәр Толымбай, Кәрим Тинчурин, Фатих Сәйфи килә торган була. Алар барысы да Галимҗан Нигъмәтинең Совет язучыларының беренче корылтаена әзерләгән доклады буенча фикер алышырга, аны төзәтергә җыелганнар. Кәрим Тинчурин Кави Нәҗмигә драматургиягә караган материал тапшырган.

Галимҗан Нигъмәти һәрвакыт кешеләр арасында булган, сәяхәт итәргә яраткан. Ул соңгы тапкыр 1937 елның җәендә хатынының туган ягы Әстерханга сәяхәт кыла. Яңа Болгар авылына кайтышлый, Әстерханда элек циркта көрәшче булган туганнары Гыйләҗ абыйларында туктыйлар. Галимҗан Нигъмәти, Шаумян урамында урнашкан шау-шулы коммуналь йорттагы ике кечкенә бүлмәне күреп гаҗәпләнә:

– Пәһлеван батыр читлектә яши, – ди.

Гыйләҗ абый үз заманында циркта күренекле көрәшче саналган, бервакыт хәтта Иван Заикинны да җиңгән. Ул гади, эчкерсез, галимнәрне хөрмәт итә торган матур күңелле кеше булган. Аның белән аралашу әдәби һәм башка көрәшләрдән, аеруча бик яхшы истә калган утыз җиденче елда алган стрессны юкка чыгарган. 1941 елның 21 гыйнварында Вожаельдән килгән соңгы хатларының берсендә Галимҗан Нигъмәти болай дип язачак: «Безнең карт абыебыз пәһлеван Гыйләҗгә сәлам җиткерче»... ■

Безнең мирас №12 декабрь 2017



ӘБИЛӘР ЧУАГЫ

Хәйдәр*

Гөлҗиһан әби буявы уңган, инде купшып коела башлаган рәшәткәгә сөялеп, беравык торды да авылга таба атлады. «Алтын йөгерткәнмени үзләренә. Яфрак коярга да өлгермәгәннәр», – дип уйлады ул, зираттагы агачларга карап. Алтынсу яфраклар исә: «Бөтен дөнья саргайган мәлдә каян килгән яшеллек бу?» – дип, карчыкның яшел яулыгыннан көнләшкәндәй, шыбырдашып куйдылар.

Гөлҗиһан әби үзе моны сизмәде дә. Уйлары тынгылык бирми иде аңа. «И-и, Раббым! Дөньялыкта күрешергә насыйп булмагандыр инде... Кыямәт көннәрендә генә теләгемә ирештерерсең микәнни?..»

*Хәйдәр Гайфетдин улы Гайнетдинов (1952-2000)

Безнең мирас №12 декабрь 2017

Зиратның теге дөньяга алып чыгучы капка түгеллеген бик яхшы белә ул. Теге дөнья дигәннәре әллә бар, әллә юк, дигәндәй... Кем барып күргән дә, кем әйләнеп кайткан аннан. Кыямәт көннәре, дип, болай гына әйтә инде... Дөньялыкта күрешүгә ни җиткән?! Зираттагы агачларга сокланып йөрүе дә теге дөньяга ашыгудан түгел. Алай юрамый Гөлҗиһан әби. Аннары, үлгән кеше белән кавышырга җыенмый бит ул. Исән кеше белән!

Тракторлар гөрелтесен тыңлый-тыңлый кайтты Гөлҗиһан әби. Игеннәрне җыеп алгач, туңга сөрәләр. Тавышлары көчле булса да, күңелгә шом салмый бит, әй! Әллә улы Хәлим тракторда эшләгәнгәме икән? Алай дисәң, элек тә колакка ятышсыз тоелмый иде. Җанга ниндидер якын аваз, моңлы аваз чыгаралар бит, кара инде, ә...

Тракторлар кыр ягыннан тырышып-тырышып киләсе ел уңышы турында хәбәр салалар иде.

«Дөньялар үзгәрде. Мондый да имин елларда нишләп исән булмасын?! – дип уйлады Гөлҗиһан әби. – Чегәннәр дә, исән, диделәр бит!»

Чегәннәр багуын берәүгә дә сөйләгәне юк иде әле анын. Дөрестерме-юктырмы күрәзә дигәннәре – анысын, белсә, ахирәте Фатыйма гына белә инде. Сугылып чыгарга кирәк әле Фатыйма күршегә, нишләп ята икән? Хәлимнең кырдан эшен бетереп кайтырына да шактый вакыт бар. Оныклары да өйдә түгелдер. Кояш әнә төшкелектән авышты гына.

...Сугыш башланган елны Гөлҗиһан белән Кави өйләнешкәннәр генә иде әле. Аларның гаиләсе бик бәхетле булырга тиеш иде югыйсә. Шулай булмыймы соң?! Алар бер-берсен яраталар иде бит. Кави да Гөлҗиһанга теләп өйләнде, Гөлҗиһан да Кавига теләп кияүгә чыккан иде. Түп-түгәрәк бәхет бер яктан кителә, диләр... Халык арасында таралган әйтемдәге хакыйкать Кави белән Гөлҗиһанны урап узарга тиеш иде кебек. Аларның бәхете бер яктан түгәрәк тоелса да, каралты-куралары, мал-туарлары әлегә юк иде. Бердәнбер дүртпочмаклы йорт. Аннары, гаилә бәхете бит ул бала булганда гына түгәрәкләнә...

Аларны кинәт башланган сугыш мәңгелеккә аерды да куйды... Егерме икенче июнь таңында сугыш башлану хәбәре Иштирәк авылына да килеп иреште.

1914 елгы Герман сугышын айкап кайтучылар бу сугышның тагын да шәфкатьсезрәк булачагын, күп гаиләләрнең җимереләчәген сизенәләр иде, мөгаен; яшь егетләрнең сугышка җыенуларын күреп, алар лапас асларында яшеренеп сыгыла-сыгыла яшь түктеләр. Кеше алдында күз яше чыгармаска тырыштылар. Киресенчә, егетләрнең күңелләрен үстерергә теләптер, юату сүзләрен кызганмадылар.

– Сез ул мәлгуньнәрнең муеннарын тиз борырсыз, – диделәр алар. – Уракка төшкәнче кайтып җитәргә тырышыгыз!

Күбесе Германия белән сугышуның ничек булачагын күз алдына да китерми иде. Ни төсле була ул сугыш? Тиктомалга ни өчен сугышып мәшәкатьләнергә соң әле? Шуңа күрә дә алар сугыш башлану хәбәрен тыныч кабул иттеләр. Бу хәбәр Кавины да артык борчымады.

– Кайту юк инде безгә... Күрешүләр насыйп булмас инде... – дип, башкалар елаша-елаша саубуллашканны Кави үз хатынына күрсәтергә теләмәде.

Басу капкасын чыккач, Гөлҗиһанны чаукалык буенарак алып китте дә култыклап алды.

– Мин, – диде ул, – исән кайтам. Шулхәтле кан коешырга нимес тә җүләр түгелдер әле. Син миннән үлде, дигән хәбәр көтмә. Исәнлегем турында хәбәр килмәсә дә, кайгырма: барыбер кайтырмын.

Җигүле атлар район үзәгенә таба юл алдылар. «Вараксин» гармуннары өзгәләнеп

«Шахта» көен башлап җибәрде. Ир-егетләр гармунга кушылып сузып-сузып җырлыйлар. Мәңгегә аерылышу ачысын шушы бер җыр үзенә ничек туплап бетерә алды икән?.. Кем чыгарды икән бу җырны? Мөгаен, дөньяның иң бәхетсез кешесе булгандыр ул... Бәхетле кешедән мондый үзәк өзгеч моңны көтәргә ярамый.

Сөйләшер сүзләре күп булса да, Кави белән Гөлҗиһан эндәшмичә генә атладылар. Икесенең дә күңеле тулган иде. Аерылышуның никадәр авыр булуын икесе дә менә хәзер генә белделәр кебек.

– Печән чабармын дигән идем быел...

Моңа хәтле еламыйча түзеп барган Гөлҗиһан ике кулы белән битен каплады да сукмак буена чүгәләде. Тавышсыз гына сулыга-сулыга елый иде ул.

– Йә инде, – диде, ни әйтергә дә белмәгән Кави. – Сабыр бул инде...

Гөлҗиһанның күңеленә җыелып килгән барлык ачыргалануы тышка бәреп чыкты.

– Китмә, Кави! – дип, чирәмгә капланып илерә-илерә үкседе ул. – Ташлап китмә!..

Яраткан кешесенең шулай ярдәм сорап үксүен карап тору кызганыч иде. Никләр генә сугыш башлаган ул немец, кем уйлап чыгарган бу сугышны?! Кави иренен тешләде, үзе дә елап җибәрүдән чак-чак тыелып, Гөлҗиһанны җирдән күтәреп торгызды.

– Сабыр бул... – дип әйтүдән башка сүз эзләп таба алмады. «Их, нигә дип төркемнән аерылырга иде!.. Кешеләр белән калса, аерылышуны җиңелрәк үткәрер иде», – дип үз-үзен битәрләде ул.

Алар култыклашкан килеш озатучылар төркеменә таба киттеләр. Ичмасам, җырламасыннар иде, аерылышу да бу хәтле үк моңсу булмас иде.

– Нигә печән чабар идем, дидең, Кави?

Гөлҗиһан һаман да сулкылдый, тамак төбенә утырган төер аңа һич кенә дә сөйләшергә ирек бирми иде әле.

– Нигә дип... – Кави үзенең ниятен кычкырып әйтергә базмады. – Сабыр бул, Гөлия...

Кавиның ниятләре бик тә матур иде. Печән әзерләп, көзгә башмак тана сатып алмакчы иде ул. Балалары була-нитә калса, сөт кирәк бит! Моны Гөлҗиһанга әйтсәң, тагын капланып елаячак инде...

Сөйләшер сүзләр инде беткән, түгеләсе яшьләр түгелгән. Гармун да «Шахта» көен сузмый, җыр белән күңелләрен басарга теләүчеләр дә тынып калган.

– Йә, ашыгырга кирәк! – дип кычкырды колхоз председателе. – Военкоматта көтәләр.

– Ие шул, – дип күтәреп алдылар ирләр аның сүзен. – Мәңгегә аерылышмыйбыз бит! Тиз генә барып кайтыйк та...

Янәшәсендә басып торган Фатыймага Гөлҗиһан шунда гына игътибар итте: бер баласы итәгенә асылынган, берсен кулына күтәргән. Гөлҗиһанның, ичмасам, баласы да юк бит! Бер ялгызы кала... Ичмасам, Кавиның төсе итеп үстерер иде. Аның күз төбен тагын яшь каплады... Ул, башын күтәреп, Кави киткән якка карады: сугышка китүчеләр төркеме күз яшьләре аша әллә нинди шомлы булып күренде.

Кавиның шул китүдән хәбәр-хәтере булмады.

Хат ташучыны ул көн дә көтеп ала торганга гадәтләнде. Кырга эшкә киткәндә күршеләренә әйтеп калдыра иде:

– Мин кайтып өлгермәсәм, хат килсә, югала күрмәсен.

Юк, Кавидан хат килмәде.

Көзге көннәрнең берсендә Фатыймага ире үлү турында кайгылы хат китерделәр. Бу хәбәрне ишетүгә, Гөлҗиһан ахирәте янына ашыкты.

Ике баласы сәке читендә утыра. Аларның йөзләренә ятимлек төсмере иңәргә өлгергән. Фатыйма инде елап арыган, озак елаудан күз төпләре шешенеп беткән, өзек-өзек сулкылдап кына куя.

– Кайгырма инде, Фатыйма, – диде ни әйтергә белмәгән Гөлҗиһан, – минә минекенең дә хәбәр-хәтәре юк бит әле...

Фатыйма бер ноктага караган килеш озак утырды. Ахырда:

– Синең үле хәбәре килмәде, ичмаса, – дип, сәкегә капланып үксергә кереште. Өлкәннәрнең сәерлекләрен карап утырган балалар да аңа кушылдылар...

Ул көнне Гөлҗиһан Фатыймаларда гына кунды.

Менә хәзер алар әйтерсең лә әле генә йокыдан торганнар. Кайгыдан елашып утырулары да гүя кичә генә булган. Тик, ни өчендер, танымаслык булып үзгәргәннәр генә: битләрендәге җыерчык араларына бетмәс-төкәнмәс сагыш-моң сеңеп калган...

– Кайтмадылар шул...

Гөлҗиһан карчыкның тавышында һаман да өмет чагыла иде. Кайтырга вәгъдә итеп тә соңга калганнар диярсең...

– Синең, ичмасам, үле хәбәре килмәде. Ходай биреп, кайтып та төшәр әле, – дип, Фатыйма карчык аның күңелен тагын да алгысытып җибәрде. Чегәннәр турында сорашырга иң уңайлы чак иде. Чәй эчкән арада, Гөлҗиһан әби җайлап кына узганнарны кузгатырга кереште.

– Карале, Фатыйма, элгәре авылга чегәннәр килерие. Хәтерлисеңдер инде?..

– Хәтерләмимме соң! – Фатыйма әби бал белән майны ахирәтенәрәк этәрде.

– Хәзер бер дә күзгә-башка чалынмыйлар. Кем биздергәндер мескенкәйләрне.

– Шәһәрдә, ди алар. Авылга килеп чыкмыйлар шул менә.

– Яңалык була торганые шуларның күренеп китүе.

– Яңалык булмый ни! Башка халык бит инде. Киенүләренә хәтле.

– Башка халык та соң... Безнеңчә дә беләләрие бит алар.

– Әйтмә! Каян өйрәнгәннәр диген, әй.

– Берсе хәтеремнән һаман да чыкмый. – Ахирәтеннән җавап сүзе ишетмәгәч, Гөлҗиһан әби тагын өстәп куйды: – Берсе хәтеремнән һаман да чыкмый. Күңелгә өмет салды да... – һәм яшел яулыгының почмагына күз яшьләрен сөртеп алды.

Фатыйма әби эндәшмәде. Авырткан җиренә кагылырмын, дип курыкты бугай.

– Чегәннәрен дә әйтерием. Күңелгә өмет салдылар да... Шуннан бирле күренмиләр.

...Сугыштан соңгы еллар иде бу. Кызу печән өсте.

Авылга чегәннәр якынлашуын малай-шалай әллә каян ук шәйләде: «Киләләр! Тегеләр!..»

Бу сүздә кызыксыну чагылса да, хәвефләнү дә бар иде. Ничек хәвефләнмисең инде. Чит-ят кеше ни кылмас. Ходай белсен. Нинди ният белән киләләрдер бит әле?.. Ярый ла бәла-казалы булмасалар. Моңа хәтле дә күренгәләгәннәре бар иде, анысы. Кайберләре өй борынча хәер сорашып йөриләр. Шунысы кызык: ипи сыныкларына да, бәрәңгегә дә, онга да – һәммәсенә аерым капчык тота андыйлары. Каян табып бетергәннәрдер шулхәтле капчыкны, ничек көчләре җитәдер күтәрергә. Урлап алмагач, рәхмәт инде. Кайсылары вак-төяк белән сату итә. Берсен дә гаепләрлек түгел – тамак туйдырырга кирәк бит. Нишләтәсең инде – тир түгәргә өйрәнмәгән халык шул. Бар белгәннәре җыр да бию, күңел ачу.

Болары нинди хикмәтләр күрсәтер тагын. Эшкә яраклы бөтен кеше болында. Авылда карт-коры, бала- чагадан гайре адәм заты да юк, ичмасам.

Чегәннәр килүен ишетүчеләр капка төбенә чыгып басты. Кулларын каш өстенә куйдылар да басу капкасы тарафын күзәтергә тотындылар.

– Күче белән киләләр.

– Ир-атлары юкмы?

– Әллә балаларын да иярткәннәр инде.

– Ир-атлары белән йөрми бит алар.

– Нигә икән?

– Үзләреннән сора, Мәхүбҗамал җиңги. – Монысын Чуар Рәис әйтте.

– Әйбер-фәләнгә кагылмыйлардыр бит?

– Соңыннан әйтермен, Мәхүбҗамал җиңги.

– Ходай сакласын...

Бу сүзләрне ишетүгә, малай-шалай җитдиләнеп китте. Алар хуҗа ич авылга! Бер-бер хәл була калса... Олылар күзне дә ачырмас. «Куркаклар икәнсез», – диярләр. «Сезгә моннан ары ышаныч бетте», – диярләр.

– Минем янга! – дип кычкырды арада бер башка калкурак Хәлим.

Малайлар гаярьләнделәр. Аннары, дәррәү кубып, басу капкасына элдерделәр.

– Кертмәскә кирәк аларны.

– Капканы бикләргә.

– Таш белән куабыз.

– Кире борылсыннар!

– Ә сиңа, – диде Хәлим Чуар Рәискә, – әләгер әле...

Ләкин малайларның планы барып чыкмады.

Тегеләр әкрен генә киләләр дә киләләр. Бер чегән малае бозау кадәрле эт җитәкләгән. Юк, мондый бурзайга каршы торырлык эт юк авылда. Торса, тегермәнче Микулайныкы гына каршы торыр. Әмма тегермәнче эте малайларның кан дошманы иде шул.

Ә чегәннәр әкрен генә якынаялар. Үзара сөйләшәләр.

Шулвакыт алгарак йөгереп чыккан кечкенә кызыйлары борыны белән юл тузанына капланмасынмы! Чуар Рәис, түзмәде, көлеп җибәрде. Көлүе – көчек ләңгелдәвемени... Бу авазга чегәннәр бурзае колагын шомрайтты һәм кинәт, хуҗасын өстерәп, малайларга ыргылды. Көчек бар дип белде, ахрысы.

Малайлардан җилләр исте.

Чегәннәр авылга озын итәкләре белән тузан туздырып килеп керделәр.

Аларның өй борынча йөрүен малайлар башта читтән генә карап тордылар. Бераздан кыюлыклары артты. Чегәннәр керәсе йортның ишегалдына кереп тулдылар да капканы бикләп куйдылар. Чиләкләргә, чүмечләргә су тутырып, койма янына барып бастылар.

– Өсләренә сибик, – дип сүз куештылар. Койма ярыгыннан карый-карый чегәннәрне көттеләр.

Менә өлкән генә бер чегән хатыны капка келәсен шакылдатып алды. Ул да булмады, койма өстендә малайларның башлары күренде. Бурзай, аларны күреп, буыла-буыла өрергә тотынды. Котлары очты малайларның, берәм-берәм җиргә сибелештеләр. Акырышкан, чиләк-чүмеч шалтыраган авазларны ишеткәч, чегәннәр, сукрана-сукрана, икенче йортка күчтеләр.

Гөлҗиһан апа печән җыюдан кайтып килә иде. Койма ярыгыннан әнисен күргәч, Хәлимгә җан керде.

– Әнкәй! – дип кычкырды ул.

– Кайда син? – дип, Гөлҗиһан апа башын боргалады. Койма өстеннән Хәлимнең башы калыкты.

– Нишләп йөрисең анда, чит кеше каралтысында?

– Чегәннәрдән качтык.

– Нигә качасың? Нигә куркасың? Алар кешегә тими бит.

– Тимәс! Бурзайларын гына кара син аларның.

– Әйдә, улым, кайтабыз.

Атаманнары киткәч, бүтән малайлар да әкрен генә таралыштылар.

Хәлим күргәннәрен энәсеннән җебенә чаклы әнисенә сөйләп бирде.

– Шул Чуар көлеп җибәрмәсә, – диде ул, – чегәннәр бурзае кумыйдырые да безне.

– Гомерләре озын булыр боларның. Әнә, безгә дә керәләр, – диде Гөлҗиһан апа.

Чынлап та, кап-кара чәчле, җәйге челлә булуга карамастан, шактый ук керләнгән калын яулык бәйләгән, чәчәкле озын күлмәк кигән бер чегән хатыны җилкапканы ишегалды ягыннан ябарга азаплана иде. Бу халыктан бик шикләнмәсә дә, Гөлҗиһан апа аны өйгә кертергә теләмәде – каршысына чыкты.

Чегән хатыны керешли авыз эченнән нидер мыгырдана, ялт-йолт тирә-ягына карангалый иде. Гөлҗиһан апаны күргәч, кулын сузды да аңлашылмаган телдә нидер сөйләргә тотынды. Гөлҗиһан апаның сәерсенеп торуын күргәч, татарчага күчте.

– Синең чәчең коела икән. Чәчеңне җыеп йөр. Бозганнар сине, коелган чәчеңне табып алып сихерләгәннәр.

Гөлҗиһан апа тораташ булды. Әйе шул, чәче коела. Каян белә ул аны?..

– Кара менә бу көзгегә, әйбәтләбрәк кара. Ике дошманың бар синең, шуларны күрерсең!

Монысын ук көтмәгән иде Гөлҗиһан апа. Чит кеше була торып, каян белә диген. Бигрәкләр туры китерә бит!

– Син курыкма, – дип тынычландырды чегән хатыны, – курыкма миннән. Мин сиңа бәхет юрыйм бит.

Гөлҗиһан апа чигенә-чигенә өйгә керде. Телен әйләндереп сыңар сүз әйтергә өлгермәде, чегән хатыны бөтен ипи сорап алды. Һәм ипигә тиз-тиз нимәрдер сызгаларга кереште.

– Ирең сугышта булган икән. Ул исән. Кайтачак. Аны дошманнарың бозган. Кабат чәчеңне җыеп йөр. Ныклабрак кара, әнә, ипи дә читлек күрсәтә, – дип сөйләнде чегән хатыны, үзе сызган аркылы-торкылы сызыкларга ишарәли-ишарәли. – Котылыр ирең. Тик ипи миндә булырга тиеш.

Аңлаштылар. Әллә нинди сызыклар сызгаласа да, мондый яхшы күңелле күрәзәчегә түгел, гап-гади хәерчегә дә бирерсең ипиеңне.

– Ал! – диде Гөлҗиһан апа. – Кайтсын гына берүк.

Чегән хатыны югалды.

Өмет калды.

Әлеге өмет һаман да сулмый, һаман да саргаймыйча яши бирә.

Кайтачак, кайтачак! Улы да көтә бит аны. Хәлим исемле улы барлыгын да белми бит әле этисе. Кайларда йөридер шул гомер?!

Гөлҗиһанның ире сугышта булуын, аның исән калуын каян белгән диген чегән хатыны? Дусларын, дошманнарын каян белгән?

Фатыйма әби сүзсез генә утырды. Гөлҗиһанның ире сугышка китүен дә, дусларын-дошманнарын да чегәннәргә ул сөйләгән иде... Фатыймадан сорашканнар иде. Әмма исән калуын берәү дә белми. Исән калуы – чегәннәр күңелгә салып киткән өметтә генә. Алар берәүгә дә начарны юрамый шул.

Гөлҗиһан әби чыгып китте. Фатыйма әби серне ачмады, өнсез генә карап калды. Өй каршындагы саргайган юкә агачы да Гөлҗиһан әбинең яшел яулыгына карап калды... Күпме күз яшьләре дә уңдыра алмаган, кайчандыр ире туй бүләге итеп биргән, иренең төсе буларак сакланган яшел яулык...

1978 ■

Безнең мирас №12 декабрь 2017

МӨСӘГЫЙТ ХӘБИБУЛЛИНГА – 90 ЯШЬ

ТОХАР ОНЫГЫ

Лəбиб Лерон

Үз халкыңның шанлы тарихына,
милләтеңнең казанышларына,
кылган мактаулы гамәлләренә кинәнеп яшәү,
халкың өчен горурлану –
менә нәрсә озын гомерле итә кешене.
Мөсәгыйт Хәбибуллин

1986 елның мае. Алмагачлар дәррәү чәчәк аткан вакыт. Шул матур көннәрнең берсендә мин – егерме биш яшьлек егет, СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры сыйфатында, Татарстан Язучылар берлегенә эшкә килдем. Мөсәгыйт абый Хәбибуллин белән ныклап танышуым нәкъ менә шул вакытта булды. Туфан Миңнуллин – берлек рәисе, Ризван Хәмид – рәис урынбасары, Мөсәгыйт абый исә оештыру эшләре буенча сәркатип вазыйфасын башкарган чак иде бу.

Эшнең асылына бераз төшенүгә, СССР Әдәби фонды җитәкчелегенә күренеп, үзара танышып кайту өчен, Мәскәүгә Мөсәгыйт абый белән бергә бардык.

Мәскәүлеләргә күчтәнәч-бүләккә дип, алдан заказлар биреп, Бауман урамындагы «Татар ашлары» йортыннан кап-кап чәкчәк алуыбыз һәм «Васильево пыяла заводы»нда эшләнгән чәйнекләр юнәтүебез, данлыклы «Татарстан» поездының халык телендә «СВ» дип кенә йөртелгән махсус вагон купесына алынган билетлар белән кичен юлга кузгалуыбыз, иртәгесен җитәкчелек белән күрешүебез турында артык сүз куертып тормыйм.

СССР Язучылар берлегендә эшләүче милләттәшебез – Г.Тукай, М.Җәлил, М.Гафури, Ә.Ерикәй шигырьләрен урысчага тәрҗемә иткән шагыйрь Вил Ганиев һәм «Мәктәп», «Мальчиш-Кибальчиш», «Тимур һәм аның командасы» дигән әсәрләре белән мәшһүр язучы Аркадий Гайдарның (1904-1941) улы, диңгезче Тимур Гайдар белән бергә ЦДЛ *(Центральный Дом Литераторов. –* **Л.Л.***)* ашханәсендә, әдәбият хәлләре турында сөйләшә-сөйләшә, төшке аш ашадык. Шул сөйләшү вакытында Вил абыйның заманында бик популяр булган шагыйрь Әхмәт Ерикәйнең (1902-1967) кияве икәнлеге ачыкланды.

Бөтен дөньяга атаклы Сергей Михалков белән бергә эшләгән Гәрәй Рәхимнең «башкалабыз Москва»дагы «киң күңелле», ялгызак фатирында төне буе гәпләшүебез, Казанга кайтыр алдыннан гына кибеткә кереп, ул заманда үтә дефицит саналган сгущенка урынына шундый ук калай савытлы, зәңгәр этикеткалы ун данә гап-гади сөт сатып алуыбыз һәм моны өйгә кайткач кына белүебез турында да бик кызыклы истәлек язып булыр иде.

Хәлбуки (Әмирхан ага Еники әйтмешли) исәбем фәкать Татарстанның халык язучысы Мөсәгыйт Хәбибуллин һәм аның иҗаты турында язу булганлыктан, алда бәян ителгән хәл-вакыйгаларны хикәяләүне бүтән вакытка калдырып, ниятләгән эшемә керешәм...

«1969-1972 елларда Таҗикстанның бер мәктәбендә тарих фәне укыткан чакта ук «Тарихы богауда булган халкым өчен нәрсә эшли алам?» дигән сорау һич тынгылык бирми иде. Мине иң рәнҗеткәне Союз дәрәҗәсендәге республикада бары тик Русия тарихын гына укыту булды. Көннәрдән беркөнне атаклы тарихчы Лев Николаевич Гумилевка киңәш сорап хат яздым. Ул миңа болай дип җавап бирде: ***«Үз тарихыгыз турында әдәби әсәрләр яз. Адәм баласы үз халкының тарихы белән, гадәттә, әдәби әсәрләр аша таныша. Дәреслекләрдәге коры саннар укучының зиһененә дә, акылына да тәэсир итә алмый – мәктәп бусагасыннан чыкканда ук төшеп кала»****. Әйе, бу чынлап та шулай бит?! Бала күңелендә аңа кирәк булган үтә зарури вә хаҗәт тормышка якын торган мисал-саннар гына кала. Тарих фәне бала күңеленнән еракта урнашкан, шуның өчен дә ул аның белән әллә ни кызыксынмый. Кызыксыну булганда гына бала теге яки бу фәнгә тартыла. Ә адәм баласында туа-туганнан бирле сәнгатькә, мәдәнияткә тартылу зарурияте бар, чөнки әдәбият – тормыш чагылышыдыр».*

Дөньякүләм танылу алган галим Л.Гумилевның әлеге фикер-киңәше егерме өч яшендә – 1951 елда – тәүге хикәясен яшьләр җыентыгында бастырган һәм 1969 елда, ягъни яше кырыкны узып барган чакта гына «Җиде юл чатында» дигән беренче китабын дөньяга чыгаруга ирешкән Мөсәгыйт Хәбибуллинны тагы да канатландырып җибәрә. Әмма халкыбызның данлы үткәне турындагы тарихи әсәрне алай тиз генә язып булмаслыгын, әүвәл ата-бабаларыбыз тормышын тирәнтен өйрәнергә кирәклеген аңлый-төшенә яшь әдип.

Тарихчы булырга җыенган кешегә иң элек үзеңнең кемлегеңне – нәсел-нәсәбеңне ачыклау лаземдер. Бер әңгәмәбез вакытында, әти-әнисен, ата-бабаларын искә төшереп,

Мөсәгыйт абый болай дип сөйләгән иде: *«Мин Оренбург өлкәсендәге Абдуллин районы Габдрахман авылында туганмын. Әтием Мөдәррис – гади игенче, тракторда эшләп, тырышлыгы аркасында медаль-бүләкләр алып хезмәт итте. Әнием Мөнәвәрә дә – авыл кешесе, әмма нәсел җебе Пенза өлкәсеннән чыккан борынгы Борһан бәккә, алпавытларга барып тоташа. Әнинең әтисен – минем Фәтхулла бабайны «Тохар» кушаматы белән йөртәләр иде. Бабайның бабаларының бабалары да тохарлар булган, дип әйтә иде әни. Төрки тохарларның нинди халык икәнлеген мин соңрак белдем, тарих белән кызыксына башлагач. Тохарларны җиңә алмаган Искәндәр-Александр Македонский тохарлар илбашының кызы Раушаниягә өйләнергә мәҗбүр була. Раушания даны гасырларга калган Искәндәргә углан бала таба. Атам ягыннан без кыпчаклар булганбыз, дип әйтә торган иде әтием. Ат яратыр иде әти, атта җилле йөрер иде. Ләкин колхозчыларга ат тотарга ярамады. Урамнан ат узган саен, әле дә хәтеремдә: «Их!» – дип куяр иде. Әле дә күз алдымда: утызынчы елны әтинең өч атын, гаҗәеп матур итеп эшләнгән тарантасын, сабан-тырмаларын алып чыгып киттеләр. Әти, капка ябылгач, кемнедер Аллаһ сүзе белән каргады. Әллә инде аның каргышы төште, колхозлар бетте, калганнары үзгә төс алды, тик әтием генә моны күрә алмады...»*

Сугыш вакытында – Магнитогорскида токарь, сугыштан соң Башкортстанның Октябрьск каласында – нефтьче-мастер, аннары туган авылы Габдрахманда – инженер-механик, агач эшкәртүче, Баулыда – шофер, автомеханик, электрик, район газетасы хезмәткәре булып эшләгән, Баулыдагы яшьлек елларында якташы, аяныч язмышлы шагыйрь Сирин *(Сирин Хәниф улы Батыршин (1896-1969), заманында аны «икенче Такташ» дип йөрткәннәр. –* **Л.Л.***)*, талантлы чордаш-каләмдәшләре Гамил Афзал һәм Гариф Ахуновның үтемле киңәшләрен тыңлап, бер-бер артлы «Гөлсәхрә», «Киселгән каен», «Туй балдагы», «Өченче вагон» исемле хикәяләр, «Унсигезенче яз» (1969), «Тау белән тау очрашмаса да...» (1970), «Хәтер ярлары» (1977) дигән повестьлар, «Чоңгыллар» (1973) һәм «Сулар үргә акса да» (1983) дип аталган романнар язган Мөсәгыйт Хәбибуллинның капылт тарихи әсәрләргә тотынуына, әлбәттә, остазы Лев Гумилевның гыйльми хезмәтләре белән беррәттән, әдипнең тохар һәм кыпчак нәселеннән булуы да зур йогынты ясагандыр.

Язучы Мөсәгыйт Хәбибуллинның дөнья галимнәре хезмәтләрен укып, өйрәнеп, шулар нигезендә 1981-1984 елларда иҗат ителгән тәүге зур күләмле әсәре – VI гасыр ахырларында Таман ярымутравын һәм Азов диңгезе буйларын биләп, бөек Болгар дәүләтен төзегән Кубрат хан турындагы романы, ниһаять, 1985 елда укучылар хөкеменә тапшырыла. Бу урында могтәбәр галимебез **Әбрар Кәримуллин**ның әлеге романга карата әйткән сүзләре искә төшерик: *«Кубрат хан турында Мөсәгыйт архивлардан һәм төрле чыганаклардан бик күп мәгълүмат җыя... Үзе хыялланган «Кубрат хан» романын язарга керешә. Әнә шунда аның күз алдына борынгы бабаларыбызның төс-йөзләре генә түгел, шөгыльләре, кием-салымнары, холык-фигыльләре, ни ашап, ни эчеп яшәүләре, ни белән кәсеп итеп, тереклек итүләре җанлана башлый. Әмма әле ул Кубрат ханнан ерак-карак китәргә кыймый, гәрчә төрки-татар бабаларыбызның бик борынгылары – гуннар, кыпчак-болгарлар хакында белсә дә. Чөнки Кубрат хан турында, төрки-татар бабаларыбыз хакында мәгълүматлар аз була. Мәгәр өйрәнә башлагач, моңа да ачкыч табыла. Миңа калса, татарлар турындагы мәгълүматлар буенча беренче урында, һичшиксез, Кытай чыганаклары тора. Икенче урында – фарсылар. Өченче урында – әрмән һәм Рим-Византия тарихчылары, дүртенче урында – гарәпләр, бишенче урында – руслар, алтынчы урын биреләдер татар галимнәренә. Әнә шуларның барысын да сөреп чыгып, чагыштыра-фаразлый алганда гына татар халкы турында хакыйкый тарихны язып була... Мөсәгыйт Хәбибуллин исә моңа әдәби образлар аша ирешеп ята».*

Татарстан Пен-клубы әгъзалары: Р.Гаташ, Р.Батулла, Р.Вәлиев, Г.Морат, М.Хәбибуллин, Р.Мөхәммәтшин, З.Мансуров, Ә.Мушинский, М.Вәлиев; чүгәләгәннәр – Р.Галиуллин, Л.Лерон, Р.Зәйдулла, Н.Камбеев. 2012 ел

Икенче бер мөхтәрәм галимебез, әдәби тәнкыйтьче **Рифат Сверигин**ның каләмдәш-аркадашы Ә.Кәримуллинны куәтләп әйткәне дә биредә бик урынлы кебек: *«Тарих сәхифәләрен эзлекле актара торгач, М.Хәбибуллин һәр татар кешесе өчен истәлекле һәм кадерле чорга – XII-XIII гасырның тарихи вакыйгаларына – Урта Идел-Чулман буйларында Болгар дәүләте яшәгән чорга килеп чыга...»*

Нәтиҗәдә, автор тарафыннан «Илчегә үлем юк» (1990), «Хан оныгы Хансөяр» (1997) һәм «Аллаһы бүләге» (1999) романнары иҗат ителә. Шул ук еллар аралыгында Мөсәгыйт Хәбибуллин Казан ханлыгы чорына караган әсәрләрен, әйтик, «Шайтан каласы» (1993), «Сөенбикә ханбикә һәм Иван Грозный» (1996) романнарын тәмам итеп, укучылар хозурына тапшыра.

Шактый еллар, аерым алганда 1991 елның ахырыннан алып 1999 елга кадәр «Мирас» журналы редакциясендә хезмәт куйган әдипнең, төп эшеннән аерылмыйча, берсеннән-берсе калынрак романнар иҗат итүенә сокланмый мөмкин түгел. Журналдагы вазыйфасыннан киткәч тә, «базда дары бетмәгәнен» дәлилләп, М.Хәбибуллин 2001 елда ике китаптан торган «Атилла» романын язып тәмамлый...

1970 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2003), Татарстан Республикасының халык язучысы (2008) Мөсәгыйт Мөдәррис улы Хәбибуллиннан бервакыт: «Әдәбиятыбызның бүгенгесе һәм киләчәге хакынданиләр уйлыйсың?» – дип сораган идем. Аксакал әдипнең җавабы мондый булды: ***«Татар әдәбиятының киләчәге – татар халкының дәүләтчелегендә. Дәүләте юк халыкның әдәбияты да кемгәдер бәйле була. Бәйсез дәүләт, бәйсез әдәбият – купләребезнең хыялы, теләге. Аллаһыбыз безгә шуларны насыйп әйләсә иде»***.

Күренекле әдипнең асыл сүзләренә кушылып, безгә «Амин!» диясе генә кала.

5 ноябрь, 2017 ел. ■

МИЛЛӘТНЕҢ ОЛУГ ГАЛИМӘСЕ

Бар шундый шәхесләр – алар белән якыннан таныш булмыйсың яисә очраклы рәвештә генә бер-ике күрешкән буласың, тик шулай да үзләрен күптәннән белгән кебек хис итәсең.

1979 елда Казанга килгәнемнән бирле Резеда апа Ганиева исемен ишетеп яшим. Университетның татар журналистикасы бүлегендә укуым сәбәпле, ни кызганыч, тирән белемле, таләпчән мөгаллимә Резеда Кадыйр кызыннан дәресләр алу насыйп булмады. Гомер дәверемдә аның белән үтешли генә бер-ике күрештек. Ләкин шуңа да карамастан, Резеда апаны әллә кайчаннан бирле һәм яхшы ук беләм сыман. Билгеле, үземне шулай хис итүемдә олпат галимәнең киңкырлы һәм саллы гыйльми һәм педагогик эшчәнлегенең күркәм йогынтысы әйтеп бетергесез зур.

Әйдәгез, бүгенге көндә киң танылу алган хөрмәтле галимәнең биографиясенә һәм фәнни эшчәнлегенә беркадәр күз йөгертеп алыйк әле.

Резеда Кадыйр кызы Ганиева Яшел Үзән районының Югары Шырдан авылында *(бай тарихы булган бу борынгы авыл дөньяга атаклы мәгърифәтче, галим һәм язучы Каюм Насыйрины (1825-1902) бирүе белән дә данлыклы. Мәшһүребез Ризаэддин Фәхреддиннең дә (1859-1936) нәсел җебе шушы авылга тоташкан, дигән фараз бар. –* **Л.Л.***)* туа. 1958 елда ул Казан дәүләт университетын тәмамлый һәм, Мәскәү университетының СССР халыклары әдәбияты кафедрасында аспирантурада укып кандидатлык диссертациясен әзерләгәч, 1963 елда үзе белем алып чыккан югары уку йортында студентларга дәрес бирә башлый. 1964 елда исә яшь мөгаллимә Тукай сатирасына нисбәтле кандидатлык диссертациясен яклый. Нәкъ менә шушы елдан галимә Резеда Ганиеваның чын мәгънәсендә гыйльми эшчәнлеге башлана да инде. Әлеге эшчәнлегенең күркәм нәтиҗәсе булган кайбер хезмәтләрне искә төшереп үтик: «Тукайның иҗат методы» (1972), «Төрки әдәбиятларда иҗат методы мәсьәләләре» (1979), «Наследие Тукая и тюркские литературы» (1979), «Шәркый Ренессанс һәм төрки әдәбиятларда аның традицияләре» (1992), «Шагыйрьнең рухи дөньясы» (2002), «Габдулла Тукайның башлангыч чор иҗатында Шәрык һәм Гареб

Унтугыз яшьлек Резеда кырык яшьлек әнисе Хәбирә һәм унөч яшьлек сеңлесе Тәскирә (ни кызганыч, инженер-химик белгечлеген һөнәр иткән Тәскирә, пенсия яшенә дә җитмичә, вафат була) белән. Казан. 18 август, 1951 ел

Мәскәү дәүләт университетының СССР халыклары әдәбияты кафедрасында аспирантурада укып, «Габдулла Тукай сатирасы» темасына кандидатлык диссертациясе язып йөргән көннәрдән бер истәлек. 1961 ел

Казанның Бутлеров урамындагы Галимнәр йортында оешкан Халык инструментлары ансамбле. Казан педагогия училищесының дүртенче курс студенты Резеда Ганиева (дүртенче рәттә сулдан беренче) мандолина белән. Казан. 14 февраль, 1951 ел

Яшь мөгаллимә (икенче рәттә уңнан беренче) Биектау районының Мулмә мәктәбе укытучылары арасында. 8 март, 1955 ел

традицияләре» (2002), «Традиции Восточного Ренессанса в тюркских литературах Средневековья и Нового времени» *(Казан: ТР ФА«Фән» нәшрияты, 2014. – 272 б. Җаваплы редакторы – филология фәннәре докторы, профессор З.З.Рәмиев)* ...

Бу урында могтәбәр галимә Р.К.Ганиеваның Кол Гали, Мәхтүм Колый, Габдерәхим Утыз Имәни, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Н.Думави, Ш.Камал, С.Рәмиев, С.Сүнчәләй, Ш.Бабич, Ф.Туйкин, Г.Монасыйп, Х.Кайбышев һәм шулай ук төрки дөньяда исемнәре киң билгеле Йосыф Баласагуни, Абай Кунанбаев, Мәхтүмколый, Мирза Шәфи Вазих, Нариман Нариманов, Мулла Панах Вагыйф, Михаил Сеспель кебек күренекле шәхесләрнең иҗатларын тирәнтен өйрәнеп язылган күп санлы мәкаләләрнең берсеннән – «XX гасыр башы татар модернистик әдәбияты һәм Фатих Әмирхан» дигән язмасыннан кечкенә бер өзек китерүне мәгъкуль күрәм: *«Татар халкы үзенең тарихи барышында ике мәртәбә Ренессанс баскычы аша үтте. Беренчесе – урта гасырларда, мөселман мәдәнияте, Коръән тәгълиматы белән берегеп яшәгән заманда. Бу – халкыбызның Идел буе Болгарстаны, Алтын Урда империясе, Казан ханлыгы кебек дәүләтләре булган чор. Өч йөз ел дәвамында колониаль бәйлелектә интеккәннән соң, XIX гасырның уртасыннан иҗтимагый һәм рухи төшенкелектән уяну, тернәкләнү, күтәрелү*

Сабан туе көнендә – табигать хозурында. Рәсемдә (сулдан уңга): халкыбызның могтәбәр галимнәре – Әнвәр Шәрипов, Альта Мәхмүтова, Резеда Ганиева, Зөфәр Рәмиев. 1975 нче еллар

Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә читтән торып укучы студентлар үзләренең укытучы-остазлары Резеда Ганиева (икенче рәттә сулдан икенче), Вахит Хаков (сулдан дүртенче), Флера Ганиева, Шәйхелислам Садретдинов, Флера Сафиуллина белән. Июнь, 1984

еллары башлана, ә инде XX гасыр башыннан аурупалашуга, җәдитләшүгә, милләткә хезмәт итүгә йөз тоткан, халкыбызның дини, сәяси, икътисади, мәдәни-әдәби үсешендә моңарчы һичкайчан күзәтелмәгән киң колачлы Икенче Яңарыш хәрәкәте мәйданга чыга.

Әдәбият мәйданына татар милләтенең бәхете өчен җанатар Габдулла Тукай һәм Гаяз Исхакый кебек даһилар, Галимҗан Ибраһимов, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Галиәсгар Камал, Шәриф Камал, Гафур Коләхмәтов кебек зур талантлар килә. Алар арасында «Җәдитчелек – Яңарыш» (Надир Дәүләт) әдәбиятына, аның алтын хәзинәсен тәшкил иткән төрледән-төрле модернистик алым, стиль-агым, юнәлешләргә юл ачкан күренекле җәмәгать эшлеклесе, публицист-журналист, прозаик, драматург, тәнкыйтьче, тәрҗемәче Фатих Әмирхан да (1886-1926) бар иде. Иң элек ул урта гасыр Шәрекъ, шул исәптән, татар әдәбиятларында озак гасырлар дәвамында яшәп килгән, әдәби иҗатта иҗтиһад итү мөмкинлекләрен чикләгән тәкълидчелек, канунчылык, дистәгә якын төре булган нәзыйрәчелекне Америка, Аурупа, рус әдәбиятларында киң кулланылышта булган акмеизм, аң агымы, импрессионизм, концептуализм, символизм, экзистенциализм, экспрессионизм, фрейдизм кебек модерн күренешләрен татар әдәбияты җирлегендә сынап карый, Шәрекъ классикасы казанышларын ауропачыл реализм һәм романтизм эстетикасы белән аерылгысыз бербөтен итеп синтезлап, бөек экспериментатор буларак чыгыш ясый һәм гамәлгә кертә».

Ирле-хатынлы Зөфәр Рәмиев һәм Резеда Ганиеваның Азия ягыннан Европа тарафына пароходта йөзеп барган мәлләре. Истанбул. Февраль, 2007

Янә галимәнең икенче бер язмасыннан – «Тукай иҗатын өйрәнү юлында» дип

Уфада узган «Идел-Урал регионында туган тел һәм әдәбиятларның яшәеше» исемле Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясендә катнашучылардан бер төркем: алгы рәттә сулдан икенче Суфиян Суфиянов, Сания Исмәгыйлова, Резеда Ганиева, Камил Дәүләтшин, Зөфәр Рәмиев, Фәнисә Гафурова һ.б. 13 май, 2008 ел

исемләнгән күләмле мәкаләсеннән бер өземтә китерү дә бу очракта урынлы булыр: *«Тукай шигъриятенең тамырлары бик тә тирәнгә – татар халкының фольклорына, борынгы төрки дәвергә, мөселман мәдәниятенең Яңарыш сәхифәләрен ачып җибәргән изге Коръәнгә, Алланың барлыгын һәм берлеген таныган, югары әхлак кагыйдәләренә өндәгән дини-суфичыл әдәбиятка, кешенең акылын һәм хисләрен олылаган дөньяви эчтәлекле Ренессанс әсәрләренә, аларның гасырлар дәвамында чарланып килгән сәнгатьчә фикерләү кануннарына барып тоташа. Элгәргедән – төрки нигездән һәм Шәрыктан килгән тамырларның нык булуы, аны Аурупа һәм рус әдәбиятлары йогынтысында яңа хасиятләр белән баетып җибәрү Тукайга XX гасыр башындагы татар Яңарыш әдәбиятының нигез ташларын салу, аны чын мәгънәсендә милли әдәбият итеп үстереп җибәрү өчен зур иҗади мөмкинлекләр ачты»*.

Алда китерелгән ике өземтәдән чыгып та, галимә Резеда Ганиеваның гыйльми эшчәнлеген беркадәр күзаллап булыр иде. Әйе, ул Фатих Әмирхан, Тукай, Кол Гали һәм Исхакый кебек фидакарь шәхесләребезнең саллы иҗатларына җентекле анализ аша татар халкын, татар әдәбиятен югары биеклеккә күтәрә.

Зур гыйльми эшчәнлегеннән тыш, күренекле галимәнең педагогик һәм фәнни алмаш әзерләүгә керткән бәяләп бетергесез өлешен дә билгеләп үтәргә кирәктер.

Ләбиб Лерон

РЕДАКЦИЯДӘН: *Форсаттан файдаланып, Резеда Кадыйр кызын гомер бәйрәме – олы юбилее белән ихластан котлап, аңа саулык-сәламәтлек, гаилә иминлеге, яңа фәнни табышлар, балалары һәм оныкларының игелек тәрбиясен күреп яшәвен теләп калабыз.*

Фотолар Резеда Ганиева һәм Зөфәр Рәмиевләрнең
гаилә архивыннан алынды. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2017

Безнең иң үткен һәм иң көчле корал

Әлфия Шамова

Карелия фронтында 1943 елның гыйнварыннан «Ватан өчен сугышка» исемле газета чыга башлый. Аның мөхәррир урынбасары – журналист Александр Герасимов, хәрби корреспондентлар – журналистлар Бари Корбанов, Минһаҗ Җамалиев, корректор – Каюм Иманкулов. Газета атнага ике тапкыр ике битле булып басыла.

1943 елның 24 февралендә Карелия фронтыннан язучы Габдрахман Әпсәләмов Казанга Гази Кашшафка болай яза:

«Безнең фронтта татар телендә газета чыга башлады. Миңа, мәкаләләр сорап, хат язганнар иде. Әлбәттә, язачакмын. Мин бу газетада эшләргә теләр идем, ләкин, русча әйткәндә, сиё не от меня зависит. Әгәр дә теләсә, Язучылар Союзы берникадәр ярдәм күрсәтә алыр иде, дип уйлыйм».

Татарстан Язучылар берлегенең идарә рәисе Хәсән Хәйри һәм «Совет әдәбияты» журналының мөхәррире Гази Кашшаф 1943 елның 20 мартында Карелия фронтындагы «В бой за Родину» газетасының мөхәрриренә түбәндәге хатны юллыйлар:

«Хәзерге вакытта иптәш Әпсәләмов Сезнең фронтта сугыша һәм Сез аны газетагызга чакыртып алсагыз иде».

1943, 11 июнь. Г.Әпсәләмов – Атилла Расихка:

«Минем үз тормышым соңгы вакытта берникадәр үзгәрде. Мине политуправлениегә чакыртып алып, безнең фронтта татар телендә чыга торган газета редакциясендә эшләргә җибәрделәр. Хәзер шунда «прикомандированный» булып, вакытлыча эшлим.

Мин килер алдыннан редакциядә зур үзгәрешләр булган. Элекке мөхәррир урынбасары Александр Герасимов белән хәбәрче Минһаҗ Җамалиев резервка күчеп киткәннәр. Соңыннан Герасимовның Кёнигсберг өчен барган сугышларда батырларча һәлак булганын ишетеп бик кайгырыштык. Җамалиев турында бернәрсә дә ишетелмәде. Сугыштан соң да тавыш-тыны чыкмады. Хәер, ул Татарстанныкы түгел иде шул.

Майор Бари Корбановны мөхәррир урынбасары итеп билгеләделәр. Хәбәрче булып политуправлениедән бик булдыклы һәм гаять кешелекле өлкән лейтенант Мөхәммәтша Сабельев килде. Каюм Иманкулов әүвәлгечә корректор булып калды, мин – гади сержант – редакциянең җаваплы сәркатибе итеп билгеләндем».

«Ватан өчен сугышка» газетасының бөтен хуҗалыгы бер тимер юл эшелонынннан

Ахыры. Башы журналның 9 нчы санында.
Хатлар, газеталардан алынган өземтәләрдә шул чор лексикасы һәм орфографиясе сакланды.

тора. Монда барысы да бар: редакция, хәреф җыю, линотип вагоны, цинкография, ротация һ.б. Биредә эш бик тыныч... Һәр аерым купе – үзе бер редакция.

Редакция поезды Акдиңгез (Беломорск), Кандалакша, Кола шәһәрләрендә тора, ә газетаның саннары, Ладога күленнән алып, бөтен Көньяк һәм Төньяк Карелия буйлап, Заполярье һәм Петсамо өлкәсе буйлап, Норвегиянең Киркенес шәһәренә кадәр тарала.

1943 ел, 4 июль. Г.Әпсәләмов – Афзал Шамовка:

«Мин һаман редакциядә. Штатка калдырдылар. Штат ягы бездә тулы, ләкин аны әзрәк үзгәрткәндә, зарар итмәс иде. Ф.Кәримне чакырту мәсьәләсен политуправление каршына куйдык. Исәп башта

Гитлерчы илбасарларны Германия территориясендә тар-мар итүче шанлы Кызыл Армия яшәсен! Бөек совет державасының сугышчылары! Алга, көнбатышка! Фашист ерткычны үз оясында кыйнап үтерик!

(БӨЕК ОКТЯБРЬ СОЦИАЛИСТИК РЕВОЛЮЦИЯСЕНЕҢ 27-нче ЕЛЛЫГЫНА ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ ЧАКЫРУЛАРЫННАН).

Немец оккупантларына үлем!

КАРЕЛИЯ ФРОНТЫНЫҢ КЫЗЫЛАРМЕЕЦ ГАЗЕТАСЫ
АТНАГА 2 ТАПКЫР ЧЫГА

ВАТАН ӨЧЕН СУГЫШКА

ЯКШӘМБЕ
5 НОЯБРЬ
1944 ел
№ 87 (189)

Красноармейская газета „В БОЙ ЗА РОДИНУ“ на татарском языке

ВЕРХОВНЫЙ БАШКОМАНДУЮЩИЙ ПРИКАЗЫ

Советлар Союзы Маршалы МЕРЕЦКОВКА

Адмирал ГОЛОВКОГА

КАРЕЛИЯ фронты гаскәрләре, ТӨНЬЯК ФЛОТ берләшмәләре һәм караблары белән берлектә хәрәкәт иткән хәлдә, Заполярьенын кыен шартларында һөҗүм итеп, бүген, 1 ноябрьда, ПЕЧЕНГА (ПЕТСАМО) өлкәсен немец илбасарлардан тулысынча азат итүне тәгәлләделәр.

ПЕЧЕНГА өлкәсен азат итү өчен сугышларда генерал-лейтенант ЩЕРБАКОВ, генерал-майор ӘПСӘЛӘМОВ, генерал-майор МИКУЛЬСКИЙ, генерал-майор КОРОТКОВ, генерал майор ЖУКОВ, полковник СОЛОВЬЕВ, полковник ГРЕБЕНКИН, генерал майор ПАНИН, полковник КАВЕРИН, полковник

танк гаскәрләре генерал-лейтенанты КОНОНОВ, полковник СОКОЛОВ, полковник ЮРЕНКОВ, подполковник СУЧКОВ, подполковник ТЕРЕНТЬЕВ, подполковник АРШИНЕВСКИЙ, подполковник ТАРЧИЛИН, подполковник ЛЕЩЕНКО, подполковник КОРШУНОВ танкистлары; авиация генерал-лейтенанты СОКОЛОВ, авиация генерал-майоры ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ, авиация генерал-майоры КИДАЛИНСКИЙ, авиация генерал-майоры ПЕТРУХИН, полковник ЖАТЬКОВ, полковник УДОНИН, полковник ЛАРЮШКИН, полковник ФИНОГЕНОВ, полковник КАЛУГИН, полковник МИНАЕВ, полковник

«Ватан өчен сугышка» газетасы редакциясе урнашкан поезд вагонында, урта рәттә, сулдан беренче – Г.Әпсәләмов

командировкага чакырту. Политуправление җавап биргәне юк әле. Шушы арада бирер, дип көтәбез».

1943 ел, 5 июль. Габдрахман Әпсәләмовның «Советлар Союзы Герое Илдар Маннанов» исемле очеркы басыла.

1943 ел, 29 август. *«Һәр адымда – дошманга үлем! Фашистларны төньякта да, данлы Харьков дивизияләренең сугышчылары кыйнаган кебек, оста кыйнарга!»* – дигән сүзләр астында шундый материаллар урнаша: «Сугышта бары алдагыларга гына тиңләшергә» исемле баш мәкалә, «Совет Информбюросыннан», гвардия ефрейторы Д.Корякинның «Дошман тылында», капитан-лейтенант В.Соловьёвның «Гитлерчыларның атакасы кире кайтарылды», снайпер Б.Мөхәммәтхановның «Юлбашчы приказы белән рухланып», лейтенант Г.Фроловның «Тигезсез бәрелештә», өлкән сержант И.Мокшинның «Мессершмидт-109» бәреп төшерелде» дигән мәкаләләре, кызылармеец Н.Сәмигуллинның «Москва салют бирә» дигән шигыре һәм И.Козьминскийның фотосы дөнья күрә.

1943 ел, 8 сентябрь. Г.Әпсәләмов – Г.Бәшировка:

«Передовойда, кая гына барып чыксаң да, татарча китаплар юкмы, дип сорыйлар. Кызганычка каршы, безнең үзебездә дә әдәбият юк. Бердәнбер «Совет әдәбияты» журналын бөтен фронт буйлап йөртәбез. Аны сугышчылар бик ярата».

Г.Әпсәләмовның «Тәвәккәл таш ярыр» (1943 ел, 29 октябрь), «Татар егете, Разия өчен, нәни Сафия өчен, барлык совет кешеләренең каны өчен фашистлардан үч ал!» (1944 ел, 20 февраль), «Сәүбән Зарифуллин» (1944 ел, 30 март), «Сержант Ильясов» (1944 ел, 9 апрель), «Казах егете» (1944 ел, 16 апрель) исемле язмалары басыла.

1944 елның язында ике фронт – Карелия һәм Волхов фронтлары идарәләре бергә кушыла, чөнки Волхов фронты үзенең тарихи яшәвен төгәлләгән була. Редакциядә дә үзгәрешләр барлыкка килә. 1944 елның мартында Волхов фронтының «Фронт правдасы» газетасыннан эшкә килгән майор Габделхәй Хәбиб мөхәррир урынбасары итеп билгеләнә. Өлкән лейтенант, шагыйрь Әхмәт Фәйзи – хәрби корреспондент, ә журналистлар Бари Корбанов һәм М.Сабельев резервка – Мәскәү карамагына китә.

«Әхмәт Фәйзи күзлек белән дә начар күрә иде. Беренче командировкасында ул, бер подразделениедән икенчесенә барышлый, ялгышлык белән, мина кырына килеп кергән. Билгеле инде, аны күреп кешеләрнең котлары очкан – менә-менә шартлавы ихтимал бит. Ләкин, бәхеткә, ул бөтен мина кыры аша узып та (үзе, әлбәттә, моны белмәгән) хәвеф-хәтәргә очрамаган. Шуннан командирлар аны туры редакциягә кайтарып җибәргәннәр... Шул ук көннеме, әллә икенчесендәме, Әхмәт Фәйзи Мәскәүгә, резервка китте», – дип яза ул көннәр хакында Г.Әпсәләмов үзенең истәлегендә.

Редакциягә хәрби корреспондент булып 7 нче Армиянең 114 нче укчы дивизиясенең 363 нче укчы полкы элемтә ротасының радиостанция башлыгы сержант Гыйззулла Габидуллин (татар шагыйре, аның әдәби тәхәллүсе – Гыйз-әл-Габид), ә корректор итеп сугышчы Мидхәт Яхин килә.

1944 ел, 8 июнь. Г.Әпсәләмов – А.Расихка:

«Мин яңарак кына «сәфәрдән» кайттым...Татар егетләре күп. Мин һәрвакыт үзем белән Такташны һәм «Совет әдәбияты» журналын сумкага салып йөрим. Землянкаларда бергәләшеп укыйбыз. Синең әйберләреңне, бигрәк тә «Якташлар»ыңны яраталар. Мин ул турыда фронтның төрле почмакларыннан отзывлар алам. Отзывлар җибәрүчеләр арасында гвардияче Кашшапов та бар. Ул үзе тел-әдәбият укытучысы булган, югары белемле кеше. Аның отзывының (шулай ук башкаларның да) төп фикере: синең хикәяләрең укучыда көчле тойгылар тудыра, аларны дулкынландыра, ашкындыра, көрәшкә өнди.

Әхмәт Фәйзи белән очраштык та, бер көннән аерылыштык та. Ул Москвага китте, аннан IV Украина фронтына җибәргәннәр дип ишеттем.

Озаклап сөйләшеп булмады».

Г.Әпсәләмовның «Ярсу күңел» (1944 ел, 2 июнь), «Биеклек» (1944 ел, 18 июнь) исемле очерклары басыла.

1944 ел, 2 ноябрь. Г.Әпсәләмов – А.Расихка:

«Хатыңны алып чиксез шатландым. Ул күптән инде килгән булган, ләкин мин «өйдә» юк идем. Хәзер бездә дә урак өсте бит. Заполярьены дошманнан тазартуны тәгәллибез. Әле яңа гына шуннан кайттым.

Соңгы вакытларда бик еш чыгып йөрергә туры килгәләде».

1944 ел, 5 ноябрь. Беренче биттә – Верховный Башкомандующий Приказы. Аннан өзек: *«Карелия фронты гаскәрләре, Төньяк флот берләшмәләре һәм кораблары белән берлектә хәрәкәт иткән хәлдә, Заполярьеның кыен шартларында һөҗүм итеп, бүген, 1 ноябрьдә, Печенга (Петсамо) өлкәсен немец илбасарлардан тулысынча азат итүне төгәлләде...*

Ирешелгән җиңүне истә калдыру теләге белән, Печенга өлкәсен азат итү өчен сугышларда үзләрен аеруча яхшы күрсәткән Карелия фронты берләшмәләрен һәм частьларын, шулай ук Төньяк флот берләшмәләрен һәм карабларын орденнар белән бүләкләүгә тәкъдим итәргә.

Печенга өлкәсен азат иткән Карелия фронтының батыр гаскарләренә һәм Төньяк флот диңгезчеләренә Ватаныбызның башкаласы Москва бүген, 1 ноябрьдә, 21 сәгатьтә, ике йөз егерме дүрт орудиедән егерме артиллерия залпы белән Ватан исеменнән салют бирә.

Печенга өлкәсен азат итү өчен сугышларда катнашкан Сезнең җитәкчелектәге гаскәрләргә, шулай ук Төньяк флот берләшмәләренә һәм карабларына бик яхшы сугыш хәрәкәтләре өчен рәхмәт белдерәм.

Ватаныбызның азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен сугышларда корбан булган геройларга мәңгелек дан!

Үлем немец илбасарларына!

Верховный Башкомандующий Советлар Союзы Маршалы И.Сталин.

1 ноябрь 1944 ел».

Шул ук биттә «Яңа җиңүләргә ашкындыручы чакырулар» һәм Г.Әпсәләмовның «Хат укыганда» дигән мәкаләләре басыла.

1944 елның 12 ноябрендә «Ватан өчен сугышка» редакциясенең поезды Мурманск тирәсендәге Кола дигән станциядә торганда, үзенең соңгы 89 нчы санын чыгара. Бу санда Г.Әпсәләмовның «Төньяк каһарманнары» дигән очеркы басыла.

Бари Корбанов үзенең истәлегендә Г.Әпсәләмов турында болай дип язып үтә: *«Бу тырыш каләм остасы, газетабызны номердан-номерга яхшырта бару өчен, аны күп меңләгән татар сугышчыларын явыз дошманны оста дөмбәсләүгә, тизрәк тар-мар итүгә туплаучы материал белән баетуга көчен, вакытын кызганмады».*

1944 ел, 20 ноябрь. Г.Әпсәләмов – А.Расихка:

«Ниһаять, биредә дошманның эшен бетердек. Хәзер язмыш кайсы фронтларга илтеп ташлар – билгесез».

1944 елның көзендә лейтенант курсларын тәмамлап, сержант Г.Әпсәләмов кече лейтенант хәрби званиесен ала.

Бу газета редакциясе 1944 елның ноябре ахырыннан 1945 елның маена кадәр резервта була, аннары Ерак Көнчыгышка җибәрелә. Анда 1945 елның маеннан ноябренә кадәр «Сталин сугышчысы» исеме астында чыга. ■

Узган гасырның утызынчы еллары азагы, һичшиксез, совет чорының иң кара, канлы сәхифәләреннән санала. Ул чакта милләтебезнең асыл угыл-кызлары, алтын генофонды вәхшиләрчә репрессия тегермәнендә тартыла, үзләре генә түгел, эзләре дә җир йөзеннән себереп түгелергә мәхкүм ителә. Әмма тираннарның һәр вакыйгага карата аерым мөнәсәбәте булган кебек, Тарих һәм Заман галиҗәнапларының да ул тираннарга һәм алар кылган кансыз гамәлләргә карата үз мөнәсәбәте бар. «Безнең мирас» битләрендә бу хакта язылды һәм тагын язылачак әле.

Бүген инкыйлаб вакыйгаларын баштан кичереп тә, бәхеткә, дип әйтергә кирәкме икән, утызынчы еллар кабахәтлекләрен күрергә өлгермичә бакыйлыкка күчкән каләм ияләрен яд итик.

СОЛТАН РАХМАНКОЛЫЙ (1888-1916)

Әдип, тәрҗемәче, сүзлекләр авторы, журналист Солтан Рахманколый (Солтан Габделмәннан улы Рахманкулов) иҗатының чәчәк атып килгән чагында – 1916 елның 8 апрелендә – үпкә авыруыннан Казанда вафат була.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.246.

ДАВЫТ ГОБӘЙДИ (1873-1919)

1911 елда патша самодержавиесенең жандармнары Буби мәдрәсәсенә погром ясый. Укытучылар белән бергә, элегрәк мәдрәсәне тәмамлап чыккан шәкертләр дә кулга алына. Алар арасында Давыт Гобәйди (Гобәйдуллин) дә була. Кулга алынучыларның

соңыннан гаепсез табылуына һәм азат ителүенә карамастан, аларны эзәрлекләү Февраль революциясенә кадәр туктамый.

1917 елда патша төшерелүне, аннан соңгы октябрь түнтәрелешен Давыт Гобәйди алкышлап каршы ала һәм үзенең «Хөррият», «Татар улына» исемле революцион эчтәлекле шигырьләрен язып чыга. Инкыйлабтан соң якташлары аны Сарсык-Омга волосте (хәзерге Әгерҗе районы) советына депутат итеп сайлыйлар. Анда ул волость башкарма комитеты рәисенең урынбасары, соңыннан мәгариф бүлеге мөдире булып эшли.

1919 елның апрель башларында Сарсык-Омга волостена Колчак гаскәрләре басып керә. Башка совет активистлары белән бергә, Давыт Гобәйдине дә кулга алалар һәм җәзалап үтерәләр.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.400.

ШАМУН ФИДАИ (1902-1920)

Гражданнар сугышы чорында революцион рухлы шигырьләре белән танылган Шамун Фидаи (Касыйм Мөхәммәтҗан улы Шакирҗанов) 1920 елда Уфа губернасының коммунистик яшьләр берлеге исеменнән комсомолның III Бөтенсоюз съездына делегат итеп сайлана. Ләкин аңа утырышларда катнашырга туры килми. Ул 1920 елның июнь урталарында яшьләр эше белән авылга командировкага барышлый юлда совет хакимиятенә каршы баш күтәргән крәстияннәр кулыннан һәлак була.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.517.

Безнең мирас №12 декабрь 2017

НӘҖИП ДУМАВИ (1883-1933)

Совет хөкүмәте игълан иткән НЭП (яңа икътисади сәясәт) нәтиҗәсендә әле яңа аякка баса башлаган баерак хосусый хуҗалыкларга («кулак хуҗалыклары»на) һәм бигрәк тә дин әһелләренә карата егерменче еллар уртасына таба күтәрә алмаслык салымнар кертелеп, сәяси бәйләнүләр дә көчәеп киткәч, Нәҗип Думави (Нәҗип Сибгатулла улы Тахтамышев) 1925 елда туган авылында (Аксубай районының Яңа Дума авылы) муллалык һәм мөхтәсиблек вазыйфаларыннан рәсми рәвештә баш тарта. «Партиянең хата сәясәте белән, атлы-сыерлы хуҗалыкларны кулак дип, руханиларны хөкүмәткә дошман хисаплап, каты җәберләү якыная башлады, бу хәл, гомумән, тормышның ләззәтен качырды», – дип аңлата ул үзенең бу адымын. Тиздән ул туган авылын бөтенләй ташлап китә. Әүвәл Дагыстанда берникадәр вакыт педагогика техникумында укытучы булып эшли, аннары, бөтен гаиләсен алып, Урта Азиягә юл тота. 1927-1933 елларда Сәмәрканд төбәгендәге төрле уку һәм мәдәни-агарту йортларында эшли, Сәмәрканд педагогика институтында лекцияләр укый, тәрҗемә эшләре белән шөгыльләнә.

Яшьтән үк үпкә авыруыннан һәм ревматизмнан җәфа чиккән Нәҗип Думави 1933 елның 5 маенда Сәмәркандтан ерак түгел Булунгур шифаханәсендә илле яше тулар-тулмас вафат була.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.481-482.

ЯРЛЫ КӘРИМ (1901-1937)

Ярлы Кәрим (Габдулла Әхмәтвәли улы Кәримов) – Фатих Кәримнең абыйсы 1926 елда, Гражданнар сугышында алган яралар һәм контузияләр нәтиҗәсендә каты авырып китеп, хастаханәгә эләгә һәм шул авыруыннан терелә алмыйча, 1937 елда Уфада вафат була.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б. 716.

***Рузәл Мөхәммәтша** әзерләде.* ■

ЯДКӘРЛӘРГӘ – БЕР ГАСЫР

Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондыннан

Почтада Яңа ел *

(Казан почта конторасында Яңа елны бәйрәм итү турында «Казанский телеграф» газетасында басылган язма)

Казан почта конторасында Казан шәһәренең барлык почта-телеграф учреждениеләре почтальон һәм курьерларының балалары өчен Чыршы бәйрәме уздырылды. Барлыгы 370 малай һәм кыз җыелды, шуларның 160ы – өлкәнрәкләр. Балаларны чәй, сохари һәм бутербродлар белән сыйладылар. Моннан тыш, аларга кыйммәт булмаган уенчыклар, шулай ук бер төенчек чикләвек, прәннек һәм конфетлар өләшенде. Күчтәнәчләр малайлар өчен 1812 елгы сугыш күренешләре төшерелгән, ә кызлар өчен хуҗалык-көнкүреш рәсемнәре ясалган кулъяулыкларга төрелгән иде. Балалар чыршы тирәли әйләнеп биеделәр, җырлар җырладылар һәм шигырьләр сөйләделәр. Өлкәнрәк балалар өчен өске катта концерт куелды, анда Л.Н.Степанов, Байрачный һәм Занков катнашты.

Чыршы бәйрәме тәмамланганда йөзләрчә бала халык гимнын башкарды. Хөрмәтен белдереп, кичәгә почта-телеграф округы башлыгы Н.Н.Введенский да килгән иде. Аның җәмәгате Н.К.Введенская исә балаларга бүләкләр өләште. Кичә тәмамлангач, почта конторасының кече күңелле хуҗасы И.И.Светозарский дәрәҗәле кунакларны, җаваплы оештыручыларны, кунакларны һәм кичәдә катнашучыларны чәй эчәргә һәм капкалап алырга чакырды.

Казан телеграфы. – 1913. – 5 гыйнвар. – 5899 нчы сан. – 3б.

Материалны басмага ТР Дәүләт архивы секторы мөдире ***Ольга Федотова*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №12 декабрь 2017

ЛАТӘКӘ

Морат Кәримов,
профессор

Латыйф Габделхәй улы Хәмиди 1906 елның 17 июлендә Казан губернасының Зөя өязе Кошман волостеның Буәле авылында (хәзер Кайбыч районына керә) дөньяга килә. Әтисе Габделхәй ага, эш эзләп, Россиянең төрле төбәкләренә чыгып китә, Кавказ, Урта Азия якларында була, Донбасс шахталарында күмер чаба. Ә 1913 елда исә, гаиләсен алып, Сәмәрканд тирәсендәге Кәттә Курган каласына барып төпләнә. Җиде яшьлек Латыйф мәктәпкә укырга керә. Ул аеруча җыр дәресләрен ярата. Аны мандолинада уйнарга өйрәткән беренче укытучысы Гыймади Тимербулатов була. Озакламый Кәттә Курганда балалар өчен музыка мәктәбе дә ачыла, Латыйф фортепиано һәм скрипка классларына йөри.

Латыйф Хәмиди 1926 елда Ташкенттагы азчылык төрки милләтләрнең мәгариф институтын тәмамлый. Уку дәверендә үзешчән сәнгатьтә актив катнаша, халык уен кораллары оркестрында мандолинада уйный. Биредә укыганда ул Муса Җәлил сүзләренә «Беренче вальс» («Уңыш җыры») һәм «Күңелле яшьләр» маршы кебек тәүге әсәрләрен иҗат итә. Аларның кыйммәте янә шунда: болар – татар музыка сәнгатендә иң беренче вальс һәм иң беренче марш! Иҗат эше белән канатланган егет, музыкаль белемен тирәнәйтү ниятеннән, башта Беренче Мәскәү музыка техникумының теория-композиторлык факультетын, аннары исә Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясен тәмамлый.

Болары – соңрак булган хәлләр. Хәзер исә Латыйф Хәмидинең, композитор Солтан Габәши киңәшен тотып, Казанга кайтуын бәян кыласым килә. Егетнең иң зур хыялы – композитор булу. Әмма Казан музыка училищесында композиторлык бүлеге юк икән. Ул училищеның виолончель классына укырга керә, шул ук вакытта педагогика техникумының үзешчән сәнгать түгәрәгендә, «Музыкаль салон»да җырчыларга көй уйный. Шундый әдәби-музыкаль кичәләрнең берсендә Латыйф Муса Җәлил белән таныша. Аларның дусларча аралашуы шагыйрь фронтка киткәнчегә кадәр дәвам итә...

Латыйф Хәмиди Казакъстан, казакъ музыкасы белән Казаннан Ташкентка килгәч, татар яшьләре «Зәңгәр күлмәк» ансамблен оештыргач таныша. Аңа ансамбльнең сәнгать җитәкчесе һәм пианист вазыйфасын тапшыралар. Ансамбльнең Казакъстанга гастрольләре вакытында Л.Хәмиди казакъ сәнгатенә, музыкасына гашыйк була, аның аһәңнәрен, үзенчәлекләрен җитди рәвештә өйрәнә, үзләштерә. Композиторның иҗаты

Казакъстанның Дәүләт гимнын язган татар улы Латыйф Хәмиди

киләчәктә күпкырлы вә күптөсмерле булып, казакъ һәм татар аһәңнәрен, пентатоникага нигезләнеп, чын, табигый тере образлар ярдәмендә үстерә барачак. Казакъстанга тәүге сәфәрләреннән алган тәэссоратлары аңа «Таң», «Курдай таулары» исемле әсәрләрен язарга илһам бирә.

***

Латыйф Хәмидине 1933 елда Алма-Атага Казакъ драма театрының музыка бүлеген җитәкләргә чакыралар. Биредә ул спектакльләргә көй яза. Думбыра һәм кубызда уйнау өчен әсәрләр иҗат итә. Бер үк вакытта радиокомитетта да эшли, оркестр һәм хор өчен музыкаль язмалар әзерли. Күренекле музыка белгече Александр Затаевичның «Казакъстан татарларының илле җыры» китабының фәнни мөхәррире була.

1936 елда Мәскәү консерваториясе каршында татар опера студиясе оештырыла һәм, югары музыкаль белем алу форсатын ычкындырмаска теләп, Латыйф Габделхәй улы Мәскәүгә юл тота. Әлеге студиядә укыганда ул Нәҗип Җиһанов белән таныша. Алар

Безнең мирас №12 декабрь 2017

Латыйф Хәмиди истәлегенә чыккан марка

бер-берсен бер күрүдә аңлыйлар, хөрмәт итә башлыйлар. Ләкин бу дуслык, минемчә, гаять үзенчәлекле була. Хикмәт аларның холкында гына түгел, ә бәлки... әсәрләренең «холкында», үзгәлегендәдер. Нәҗип ага зур күләмле, классик әсәрләр язуга тартыла. Ул опера, балет, симфонияләр (8 опера, 3 балет, 17 симфония, симфоник поэмалар, увертюралар, сюиталар, инструменталь камера әсәрләре, фортепиано өчен пьесалар һәм... бик аз җырлар) иҗат итә. Латыйф ага исә, «Абай»дан тыш, янә өч опера, 1 оперетта, 12 драма спектакленә көй, 5 кинофильмга көй, 20дән артык инструменталь әсәр һәм... татар, казакъ, башкорт вә үзбәк халкы өчен йөздән артык (!) җыр яза, бәгъзе композиторларның 200гә якын җырын музыкаль яктан эшкәртеп, камилләштереп бирә! Аның «Казакъ вальсы» (1940) белән «Былбыл» (1945) җыры гына да ни тора – кабатланмас моңлы вә аһәңле бу шаһәсәрләр төркиләр яшәгәндә гел яшәр!

***

...Шулай бер тапкыр мин Нәҗип агадан, мәшһүрлеген дә күз уңында тотып, җыр язуын үтендем. Агам* миңа болай дип җавап бирде: «Җыр белән опера – икесе ике төрле жанр. Мин исә опера һәм симфония язуны мәслихәт күрәм». «Нәҗип ага, ә менә Джузеппе Вердиның «Травиата» операсындагы герцог ариясе, үзе бер аерым җырга әверелеп, хәзер бөтен дөньяда җырлана лабаса, дистәләгән телләрдә! Евгений Брусиловскийның «Кыз җибек» операсы исә казакъ халык җырларыннан «тукылган», – дидем мин, Латыйф Хәмидинең «Абай» операсыннан Абай ариясен дә искә төшердем. – Ул арияне СССРның халык артистлары Ришат Абдуллин белән Ермәк Серкебаев башкаруында татары да, казагы да, урысы да рәхәтләнеп тыңлый, хәтта кушылып җырлыйлар да!» «Язсын җырларын, бәлки аларны опералларга да кертерләр... – диде Нәҗип ага. – Әмма мин Латыйфның, үз талантын әрәм итмичә, җитди темаларга күләмле әсәрләр язуын телим». Әлеге ике бөек шәхеснең бер-берсен аңламавында кеше-

*Морат Кәримов – Нәҗип Җиһановның якын туганы. – Ред.

лек мөнәсәбәтләре түгел, ә бәлки шушы иҗат хасияте ята иде, минемчә. Бу җәһәттән Латыйф ага белән бер очрашу вакыйгасын да искә төшереп китим инде. Шулай беркөнне мәктәптә укучы улым Искәндәр белән, алдан телефоннан шылтыратып килешеп, Латыйф агаларның өенә киттек. Аның хәләл җефете Хәдичә апа белән дә яхшы таныш, чөнки ул Беренче Алма-Ата инфекция клиник хастаханәсендә табибә булып эшли иде. Хуҗабикә безне табынга дәште. Чәй эчкән арада мин композитордан улымның музыкаль сәләтен ачыклавын үтендем, чөнки аны фортепиано буенча музыка классына бирергә ният бар иде. Малайның берничә аккорд уйнавыннан соң, ул: «Ай-һай, егеттән музыкант чыгармы икән...» – дигән сыманрак фикерен әйтте. Мин исә, кыюланып китеп, бер җыр җырладым:

«Әйлән-бәйлән килә матур кызлар,
Гармунчылар сыза гармунын.
Яшь егетләр өзеп сызгыралар,
Яңгыратып Идел буйларын».

Латыйф агай: «Морат, каян беләсең син бу җырны?!» – димәсенме. «Мәктәптә укыганда әни өйрәтте, – дим. – Ул бит татар мәктәбендә башта укытучы, аннары директор булып эшләде. Бөтен фәннәр дә татарча укытыла иде бит...» «Морат, бу бит – мин язган җыр, менә сиңа вәйт, казакъ җиренең бер районында татарча җыр дәресендә җырласыннар әле...» – диде ул, елмаеп. Әйе, композитор Латыйф Хәмидинең җырларын халык (татары, үзбәге, казагы) яратып тыңлый да, рәхәтләнеп җырлый да иде.

***

Казакъстанда яшәп иҗат итсә дә, Латыйф Хәмиди һәрдаим туган ягын, Казанын сагына, бер кайтырмын, дип хыяллана. Ниһаять, 1938 елның җәй башында, Мәскәү консерваториясен тәмамлагач та, ул Казанга юл ала. Инде чын мәгънәсендә һөнәри җитлеккән, җырлары белән дә дан казанган композиторны, ни кызганыч, Казан колач җәеп каршы алмый. Республиканың (ул чактагы ТАССР) Мәдәният министрлыгындагы (ул чактагы наркомат) бер чиновник кисәге белән мондый эчтәлектәге әңгәмә була:

– Син кем?

– Мин – композитор.

– Нигә килдең?

– Мәскәү консерваториясен тәмамладым. Туган ягымда эшлисем килә. Туган халкыма эшлисем килә.

– Гармунда уйный беләсеңме?

– Юк, уйный белмим. Мин – композитор.

– Гармунда да уйный белмәгәч, нигә килдең монда?!

Менә шулай итеп, Латыйф Хәмидинең Казанга юлы киселә. Югыйсә, «Казакъ вальсы»ның «Татар вальсы» булуы да бик ихтимал иде бит. 1945 елда Казакъстанның Дәүләт гимнын язачак гаять талантлы, хәтта бөек аһәңсазыбыз, әнә шулай, чит булмаса да, үзгә милләткә хезмәт итә башлый.

Латыйф ага Казакъстанны бик ярата иде. Хезмәтеңне, иҗатыңны, шәхес буларак үзеңне хөрмәтлиләр вә лаеклы бәя бирәләр икән, аларны ничек яратмыйсың, ди инде, йә?!

Казакъларда бик күркәм бер гадәт бар – хөрмәт иткән кешеңә олылап эндәшү гадәте ул. Мәсәлән, Солтанга – Солтәкә, Динмөхәмләткә – Динәкә, Габдерахманга – Габәкә һ.б. Латыйф ага Хәмидигә Казакъстанда һәммәсе дә – олысы да, кечесе дә Латәкә дип эндәшә иде. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2017

Имтихан яки Нефтьче язмалары

(Шул исемдәге әсәрдән өзек)

Лерон Фазлыев

Ахыры. Башы журналның 10 нче (2017) санында.

Сентябрь ае башында Сәлимҗан хезмәт иткән икенче рота солдатларын Поронай шәһәреннән Сахалин утравы ерак булмаган, Охота дингезе ярына урнашкан Вахрушев (1946 елга хәтле Кусунокима) бистәсенә эшкә җибәрделәр. Алар алдына куелган боерык бик кыска: шушы 1957 елның август аенда булып узган көчле давыл вакытында таралган салның дингез ярына чыгарып ташланган төз, озын, юан бүрәнәләрен, су кырыеннан утыз метрдан ким булмаган ераклыкка ташып, бер урынга өяргә! Ярда бүрәнәләр шулхәтле күп ки, аның хәтта очы-кырые күренми. Солдатларның кулларында бары тик бер корал, ул да булса – бер башы ыргаклы, озын агач саплы багор. Биш взводка яр биләмәләре бүленеп бирелгәннән соң, ниһаять, барысы да кодрәтләнеп эшкә кереште. Дүрт-биш кеше, дингезгә йөз белән карап, бүрәнә буйлап тезелеп баскач, арадан берсенең кискен тавышы яңгырады. Шулвакыт багор ыргаклары дәррәү бүрәнәгә кадалды. Әмма урыннарыннан кузгатырга күпме генә тырышсалар да, озак ятып дингез суын үзенә сеңдергән ул бүрәнәләр комдагы «оя»ларыннан чыгарга уйлап та карамады. Бүрәнәләрнең аскы өлешендә тирән чокырлар казып, шулар аша аркылы киртәләр уздырып чиләнә торгач, берничәсен чыгарып, тиешле урынга илтеп куя алдылар. Тик бу эш түгел, ә газапланып юкка вакыт уздыру гына иде. Башка взводларда да хәл нәкъ шундый булганлыктан, офицерлар пошаманга төште.

Шабыр тиргә баткан солдатларга карап, взвод командиры Владимир Кономенов: «Эшнең башка җайлырак ысулын тапмасак, бу бүрәнәләрне тартып чыгару өчен безгә тагын бер ел вакыт кирәк булачак!» – дип әйтеп куйды...

Иртүк уянган Сәлимҗан, чатырның түбәсе аша күккә сузылган тимер торбага карап, беравык уйланып ятты. Туктале, нишләп аның күзе бу торбага төште соң? Буровойда эшләгәндә тимер торбаларны башка урынга бик җайлы гына күчерәләр иде югыйсә. Бәй, бүрәнәләрне дә шулай күчереп була бит. Шушы урында аның уйлары бүленде. Чатырга взвод командиры килеп керде. Сәлимҗан җәһәт кенә торып басмакчы иде, әмма йокы капчыгының бавына абынып егылды. Владимир Кономенов, елмаеп, башка солдатларга ыгы-зыгы куптармаска кушты да, Сәлимҗанга карап, үзенә тиз арада частька кайтырга кирәклеге, бу хакта рация аша әле генә боерык алуы һәм үз урынына вакытлыча Сәлимҗанны калдыруы турында әйтте. Башка взвод командирларының да бу хакта белүен, кыенлыклар килеп чыкса, аларга мөрәҗәгать итәргә мөмкинлеген искәртеп, бик ашыгып чыгып та китте. Әле генә яңгыраган сүзләрнең мәгънәсен ныклап аңлап җиткермәгән Сәлимҗан авызын ачып калды. Иптәшләреннән берсе:

– Взвод командиры сиңа бу тәкъдимне, алга карап, акыл белән ясаган булырга тиеш. Әгәр дә дөрес бизмәнгә салып карасак, без барыбыз да татарлар, взводтагы берничә егетнең урыс булуын исәпкә алмаганда, әлбәттә. Шуны уйлап һәм син ике телне дә әйбәт белгәнгә күрә, Кономенов иртүк безнең чатырга килеп кергән, күрәсең, – дип әйтеп куйды.

Кулларына котелок тоткан дүрт солдат, көлешә-көлешә, төнлә яуган тәүге кар өстеннән ашханәгә юл тотты... Кояшлы салкынча, карлы һава егетләрнең кәефләрен күтәреп кенә җибәрде. Взвод солдатлары биш урында эшләгәнлектән, Сәлимҗан һәр төркемнән берәр солдатны алып, аларга бүрәнәләрне җайлы итеп илтүнең үз ысулын аңлатты. Барысы да Сәлимҗанның бу алымын хуплады. Алым исә бик гади: башта бүрәнәнең бер башын ломнар ярдәмендә күтәртеп һәм аның аскы урта бер өлешенә киртә кертеп, бүрәнәнең күтәртелгән башын аска таба басарга кирәк. Комнан арынган бүрәнәләр шуннан соң тигез җиргә үзе тәгәрәп китә. Кичә бер бүрәнәне алып куярга бер сәгать чамасы вакыт китсә, бүген исә шул эшне өч кеше ун минут эчендә башкарды. Сәлимҗан, шатлыктан, йодрыгын төйнәп, бер бүрәнәгә сугып алды...

Атна артыннан атна узды.Тирә-якны ак кар каплады.

Беркөнне иртән эшкә тотынуга, диңгез ярыннан бер баланың сызланып, үзәкләрне өзәрдәй итеп елаган тавышы ишетелде. Аны беренче булып ишеткән Кәшиф белән Сәлимҗан шул якка йөгерде. Килеп җитүгә, икесе дә аптырап калды: нерп дип аталган дингез җәнлеге баласының тәненә багорның очлы ыргагы кадалган. Җәнлек-балакай, елап-чинап, каз канатына охшаган нәни тәпиләре белән тыпырчынып, яр читендәге карлы дингез суында ята. Су кан төсенә кергән. Егетләр ыргакны тартып алуга, кан килү туктады, әмма җәнлек бик нык хәлсезләнгән булып чыкты. Аны бүрәнәләр өстенә салгач, җан иясе бераз селкенә башлады. Озын ап-ак бармаклары белән багор сабын кысып тоткан күрше взвод солдаты, куркудан һаман акылына килә алмаган кыяфәттә, сәер, хәрәкәтсез күз карашын дингез киңлегенә төбәп, су читендәге бүрәнәнең бер башында утыра. Эндәшкән сүзгә җавап бирми. Кәшиф, берничә мәртәбә карлы-бозлы диңгез суы алып килеп, селкенмичә утырган солдатның йөзенә сипте. Гаҗәп хәл, бераздан аның ачык күзләре нерп баласының йомры, зур күзләре хәтле булып киңәйде. Ул, як-ягына каранып алгач, бернәрсә булмагандай, урынында утыруын дәвам итте.

Эш болайрак булган. Иртән дингез ярына эшкә килгән бу бәндә нерп баласын күреп ала да, аның белән шаярырга уйлап, багор белән төрткәли башлый. Йокымсырап яткан җәнлек, кинәт уянып, очлы ыргакка үзеннән-үзе кадалган икән. Солдатның мыгырдавыннан шулайрак аңлашылды. Сәлимҗан моңа ышанмады:

– Ты поднял руку на самое святое, на дитя природы! – диде.

Ул арада бу хәлнең шаһиты булган бер солдат нерп баласын җәрәхәтләгән бәндәнең ияк астына йодрыгы белән кундырып та өлгерде...

Нерп баласының бәхете бар икән: шушы тирәдән үтеп баручы бер агай, үзем дәвалыйм, дип аны капчыкка салып, якындагы посёлокка алып китте...

Кичен Сәлимҗанны офицерлар яши торган чатырга чакырдылар. Көндезге вакыйгадан соң бик борчылган бригадир шунда юл тотты. Диңгез буенда алар белән калдырылган бердәнбер офицер Сәлимҗанны елмаеп каршы алды. Мондый очракларда тиз эреп китәргә ярамаганын белгән Сәлимҗан, хәрбиләрчә, тәртипле генә исәнләште. Өлкән лейтенант, йөзеннән елмаюын югалтмаска тырышып, дингез буенда булган хәл турында өстәгеләргә хәрбиләрчә кыска язма-хәбәр җибәрергә тиешлеге турында әйтте. Сәлимҗан уйлаган арада чатыр эчендә тынлык урнашты. Бераздан ул, үзенең әле яшь солдат курсларын узмаганлыгын нигезле сәбәп итеп, имзасын куймаячагын, аңлатма язудан баш тартуын әйтте. Әлбәттә, әйтелгән бу җөмләнең эчтәлеге килер алдыннан гына уйланылган иде. Чатыр хуҗасы, Кономеновның үзе урынына кемне калдырырга белгәнлеген мактап искә алганнан соң, түрдәге тимер урындыкка барып утырды, ә икенчесен Сәлимҗанга тәкъдим итте. «Гади солдатны бик зурлау түгелме соң бу?» – дип уйлап куйды Сәлимҗан. Ничек кенә булмасын, офицерның хәрбиләргә хас булмаган моңсу күз карашы, әңгәмә вакытында игътибар белән тыңлавы, боеру тонында сөйләшмәве – барсы да аңа карата хөрмәт тудыра. Бераз гәпләшкәннән соң, Сәлимҗан әлеге очрашуның ни өчен кирәклеген аңлый башлады. Аңламаслык та түгел иде шул: теге нерп баласын яралаган солдатның шушы өлкән лейтенант взводыннан булуы, өстәвенә, ул солдатны сугып еккан «боксер»ның да шул взводныкы икәнлеге ачыкланды. «Бу дуңгызлар минем хәрби киләчәгемне зур сорау астына куйды», – дип, өлкән лейтенант Сәлимҗанга текәлде. Инде ир буларак җитлегеп килгән, бер айдан егерме яшен тутырырга җыенган Сәлимҗан өлкән лейтенантның кичерешләрен аңлады кебек...

Чатырга кайтып кергәч тә Сәлимҗан дусты Кәшифкә иртәнге су буенда күргән «төшен» онытырга кушулары турында әйтте...

***

Озак вакыт узмады, бер ротада хезмәт иткән сержант Володя белән Сәлимҗанны шәһәрдә урнашкан хәрби сәяси бүлеккә чакырттылар. Аларны яшь, чибәр һәм озын буйлы полковник Аванесов бүлмәсендә кабул иттеләр. Ябык кына ак йөзле, кечкенә гәүдәле подполковникның да аның бүлмәсендә булуы алда бик мөһим әңгәмә көткәнлеген әйтеп тора иде.

Аванесов сүзне ерактан башлады. Ул үзе җитәкләгән сәяси бүлеккә берничә хәрби частьның буйсынуын, шулай булса да алда торган бик мактаулы вә җаваплы бурычны үтәүнең партия әгъзасына кандидат, ышанычлы сержант Вильдановка һәм комсомол әгъзасы Бутовка ышанып тапшырылуын җиткерде. Аннары боерыкның төп эчтәлегенә күчеп: «Сезгә икегезгә да сугыш-



Лерон Фазлыевка 21 яшь тулган көн. 7 ноябрь, 1958 ел

Ерак Көнчыгыш хәрби округының шоферлар һәм хәрби катер йөртүчеләрне әзерли торган мәктәп курсантлары – Тымытык районы егетләре: утырганнар (уңнан сулга) – Яссир Шәрәфиев (Чалпы), Лерон Фазлыев, Зөфәр Кәримов (Сарлы); басканнар: Кәшиф Сабирҗанов (Камышлы), Нәфис Шәйхразыев (Камышлы). Поронай. 1958 ел

чан патроннар белән тулыландырылган «АК» автоматы тапшырылачак. Хабаровск шәһәрендә урнашкан Ерак Көнчыгыш хәрби округының штабына иптәш подполковникны рәсми, яшерен кәгазьләр белән бергә саклап барачаксыз. Подполковникның фамилиясе вә яшерен кәгазьләр белән кызыксыну тыела. Башка бурычларыгызны исә майор Потапов күрше бүлмәдә аңлатыр. Боерыкны уңышлы үтәвегезгә ышанып калам», – диде.

Шулай итеп, частьның партия җыелышында гына күренгәләгән полковник Аванесов белән аның эш урынында танышу насыйп булды. Частька җәяү кайтырга булдылар. Урамга чыкканда Володяның чырае чөгендер кебек кызарган булуына игътибар иткән Сәлимҗан аптырап калды.

– Сиңа нәрсә булды?

– Бик куркыныч, җаваплы эш йөкләделәр бит.

– Комсомолда булмасаң, йөкләмәсләр иде.

– Анысы шулай да, тик бераз шөлләтә...

– Борчылма, тырышсак, барысы да әйбәт булыр. Син бит авылда үскән егет, сугыш вакытында әллә ниләр күргәнсеңдер әле?!

– Юк, ялгышасың... Мин – Мәскәү университетында укыткан профессор малае. Укырга керә алмагач, әти бер югары уку йортына лаборант итеп урнаштырды. Шуннан мине армиягә алдылар. Әти хәрби комиссариатка барып, күңеле белән әйбәт егет ул, дөнья күреп кайтсын әле, Мәскәүдән ераграк җибәрегез, дип үтенгән. Нәтиҗәдә, үзең күрәсең, мин – Сахалин утравында.

– Әллә әтиеңә үпкә-ачу тотасың инде?

– Әнинең йөрәгенә армиягә китүем көчле тәэсир иткәнлектән, әтигә карашымны башта үзгәрткән идем, әмма тора-бара аңа хөрмәтем кайтты. Беләсеңме, Сәлимҗан, мин, үскәндә, Мәскәү шәһәре белән Ялтаның ял йортларыннан башка нәрсә күрмәдем. Дөресен әйтәм, башкалада яшәгән кешеләр күпләрдән акыллырак, өстенрәк, дип уйлый идем. Ә менә армия кешеләргә, дөньяга карашымны үзгәртте. Тормыш таләпләре адәм баласына бөтенләй башкача икән бит.

– Әтиең дөрес әйткән, әйбәт күңелле егет син. Хәзер матур гына ял итеп, иртәгә тыныч кәеф белән юлга чыгуың минем өчен бик мөһим.

– Яхшы, аңладым.

Икенче көнне алар самолет белән Сахалин утравыннан Владивостокка очты. Шәһәрнең тимер юл вокзалыннан Хабаровск шәһәренә бара торган поездның махсус вагонына кереп утыргач, Сәлимҗан белән Володя сакта бер-берсен ике сәгать саен алыштырып торды. Пистолет таккан подполковник юлда алар белән бөтенләй сөйләшмәде. Кара чемоданга охшаган сумкасын баш астына салып, икенче каттагы киштәдә ятып барды. Ә егетләр астагы киштәләргә автоматлары белән бергә урнашты. Әле Поронай шәһәрендә үк, майор аларга барысын да энәсеннән җебенә хәтле аңлаткан иде. Утырганда, йоклап бара торган гади вагонга кердек, дип уйлаган сержантлар ялгышкан булып чыкты. Авыр ябыла торган вагон ишекләре, барлык тәрәзәләрнең дә кара пәрдәләр белән капланганлыгы, эчке диварлардан тимер салкыны бәреп торуы, чәйне мускуллары уйнап торган егетләрнең кертүе, утырып баручыларның үзара аралашмавы – болар барысы да сәер тоела иде. Алар, полковник Аванесовның әйткән сүзен истә тотып, бернәрсә белән дә кызыксынмадылар. Килеп җиткәч, егетләрнең кулларына Ерак Көнчыгыш хәрби штабына керү өчен мөһер сугылган рөхсәт кәгазен тоттырдылар. Анда, 27 августтан алып 1 сентябрьгә хәтле кулланырга ярый, дигән тамга салынган иде. Автоматларны тиешле урынга тапшырып, «фамилиясез» подполковник белән саубуллашкач, ишегалдына чыктылар. Шунда гына безнең ике сержантыбыз, тирән сулыш алып, кычкырып көлеп җибәрде...

Сәлимҗан белән Володя капкага таба юнәлгән генә иде, шулчак алар каршында бер генерал-майор пәйда булды. Чын генералны икесенең дә беренче күрүе иде бу. Егетләрнең аяклары бермәлгә камыр кебек йомшап төшсә дә, җәһәт кенә бер-берсенә карашып алгач, кул бармакларын чигәләренә ук кебек батырып, башларын генерал тарафына бераз чөебрәк, таш юлга бердәм баскан күн итек табанының тавышы астында үзләрен парадта хис иткәндәй уздылар. Капка янында торган сакчы тирәсенә килеп җиткәч кенә артларына борылып караган егетләр генералның да туктап, кызыксынып, үзләрен күзәтеп торуын шәйләп алдылар...

Кирәкле поездның кайчан китәсен алдан белгәнлектән, алар дөрес ашыккан икән.

Бераздан вагон сәндерәсендә тирән йокыга талган егетләрнең тигез итеп сулыш алганы гына ишетелә иде.

Частька кайтып кергәч тә, шундук штабка барып, йөкләнгән бурычны үтәп исән-сау әйләнеп кайтулары турында белдерделәр. Аларны тыңлаган капитан Веприков, часть командиры полковник Дымов исеменнән рәхмәтен әйтеп, икесенең дә кулын кысып, җилкәләрен өлкәннәрдә генә була торган җылылык белән кагып куйды.

Хәрби сәяси бүлеккә барып, полковник Аванесовка да аның боерыгын үтәүләрен хәбәр иткәч, егетләр, тынычлап, төп хезмәтләренә керешә.

Предъявить с удостоверением личности или паспортом
Временный пропуск № 1042
Документ 133075
Звание с-нт
Фамилия Фазлиев
И. О. Л. З.
Действит. с 27.08 по 1.09 1959 г.
Комендант

Ерак Көнчыгыш хәрби штабына керү өчен мөһер сугылган рөхсәт кәгазе

***

Армиядә хезмәт итү вакыты инде бер ай элек үк чыккан булса да, аларны өйләренә кайтарып җибәрмәделәр. Бүлек командирларын алыштырырга махсус мәктәп бетергән сержантлар килергә тиеш икән. Ә алар кайчан киләчәк? Монысы аларга караңгы. Хәер, Сәлимҗан бу турыда уйлап башын катырмады. Шулай кирәк, димәк, түзәргә генә кала!..

АВТОРДАН: Әгәр кышын Казан каласының үзәгендә урнашкан Максим Горький исемендәге ял бакчасына шугалакка барсагыз һәм анда спортчылар кебек киенгән 80 яшьләрдәге бер абзыйның тимераякта шуып йөргәнен күрсәгез, бу – Сәлимҗан бабагыз *(дөресрәге, бу язманың авторы **Лерон Зәки** улы **Фазлыев**. – Ред. искәрмәсе)* булыр.

Сәлимҗан-Лерон Фазлыев

РЕДАКЦИЯДӘН: Мөхтәрәм авторыбыз **Лерон ага Фазлыев** күптән түгел гомер бәйрәмен билгеләп үтте. Без аны юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек белән мөбарәк озын гомер һәм иҗат уңышлары теләп калабыз! Лерон Зәки улының бу әсәре киләчәктә тулысынча – аерым китап булып дөнья күрер, дигән өметтә калабыз. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2017

СКРИПКА ТАТАРНЫКЫМЫ?

Эльмира Каюмова

Эльмира Каюмова кулдан ясалган скрипка белән. Удмуртия Республикасының Кистем авылы. 2012 ел экспедициясе

Кыллы музыка кораллары сызгычлы һәм чиртмәле була. Сызгычлы уен коралларына килсәк, аларда уйнау, ни кызганыч, бетеп бара. Хәзерге вакытта скрипкада (әйтелеш вариантлары: скерипкә, эскрипкә һ.б.) халыкчан итеп башкаручылар юк диярлек. Академик стильдә уйнау – ул башка төрле. Күп кеше скрипка татарларга Европадан үтеп кергән, дип уйлыйдыр. Ә бу алай түгел! Дөрес, халык музыкантларының фабрикаларда җитештергән коралларда уйнавы шулай фикер йөртергә нигез бирә. Әмма дә мондый нәтиҗә ясарга ашыкмаска кирәк. Мәдәниятебез тарихына күз салыйк.

Элек скрипка татарлар арасында киң таралган булган. Хәтта шуңа нисбәтле фактлар рус җырларына да кергән. Түбән Новгород якларында А.С.Пушкин тарафыннан язып алынган мондый сүзләр бар:

Приведи-ка, матушка,
Татарина с скрыпкою,
Мордвина с волынкою.

Удмуртия Республикасының Паюра авылында гаҗәеп хәл турында сөйләделәр.

Кыл-кубыз һәм гармунда уйнау. «Шытыр-Шатыр» ансамбле, уңда – Гаяз Габдуллин. Төмән өлкәсе

Р.Якупов фотосы.

Безнең мирас №12 декабрь 2017

Җирле музыкант **Муса Касыймов**та (1939-2009) бөек **Амати**ларның скрипкасы булган икән! Ничек итеп бу кыйммәтле үрнәк XVI-XVII гасырларда Италиядән Русиянең аулак почмагына, татар уйнаучысы кулына эләккән – монысы сер булып кала.

Татарлар скрипканы чыршы һәм алмагачтан үзләре ясый торган булганнар. Мәсәлән, шундый осталарның берсе – **Госман Афзалов** (1923 елгы) Апас районының Чүри-Бураш авылында яшәгән. Заманында ул күренекле композитор һәм скрипкачы Заһид Хәбибуллин белән бергә уйнаган булган. Башкаручы-оста инде үзе исән түгел. Авылдашлары һәм туганнарының истәлекләре буенча, музыка коралының аерым кисәкләре – сыер сөягеннән, сызгычның таякчыгы – тал чыбыгыннан, кыллары – ат койрыгыннан, ә бер өлеше пластмассадан ясалган булган. Ә 1965 елда Г.Афзалов әзер скрипканы сатып алган. Репертуарын «Умырзая», «Зәңгәр күлмәк», «Әйдә, җаныем, су буена», «Алмагачлары», «Салкын чишмә», «Шөгер», «Шахта» һ.б. көйләр тәшкил иткән. Шулай ук ул аккош тавышын бик оста чыгара торган булган. Концертларда катнашып, мәҗлесләрдә, капка төбендә яшьләр җыелганда уйнаган, аңа башкалар кушылып җырлаганнар.

Халкыбызда скрипканы **«каз муен»** дип тә йөртәләр (андый атама миңа узган ел Татарстанның Тәтеш районына юнәлтелгән экспедиция барышында очраган иде).

Иң мөһиме шунда ки, әле XX гасыр урталарында традицион музыкантлар әлеге коралны иңбашына терәтеп түгел, ә тез башына куеп уйнаганнар! Ягъни татарлар скрипканы **кылкубыз** рәвешендә тотканнар.

Кыл-кубыз исә – скрипканың бабасы, төрки халыкларның сызгычлы уен коралы. Аны дастан сыман озын эпик әсәрләрне башкарганда кулланганнар. Ул әле бүген дә кардәш казакъ халкының музыкаль мәдәниятендә яшәп килә. Кыл-кубызда уйнаучыларны исә югары уку йортларында, мәсәлән, Кормангазы исемендәге Казакъ милли консерваториясендә әзерлиләр.

Кыл-кубызны кабат кайтару юнәлешендә себер татарларының **«Шытыр-Шатыр»** фольклор төркеме уңышлы адымнар ясый. Ансамбльнең җитәкчесе **Гаяз Габдуллин** борынгы, онытылып бара торган төрки-татар кыллы уен коралларын үзе җитештерә. Ул 1966 елда Башкортстан якларында туган, күп еллар буе Төмән өлкәсенең Чыкча авылында яши, иҗат итә. Гаяз Габдуллин һәм аның шәкертләре бу коралларда уйнау ысулларын яңарталар, ошбу милли мирасыбызга яңа сулыш өрәләр. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2017

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

ТӘВАФ ИТҮ, ТӘВАФ КЫЛУ – *Әйләнеп йөрү* (мәс., хаҗ вакытында Кәгъбә тирәсендә 7 тапкыр әйләнү). *Туваф кылу* язылышы да очрый. Хаҗ вакытында изге зиратларны да тәваф кылалар.

Тәваф кылуның төп кагыйдәләре 632 елда Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең *«хушлашу хаҗы»* вакытында бәян ителгән. Тәваф кылу өчен хаҗи әл-Мәсҗид әл-Харамга «Тынычлык капкасы» («Баб әс-сәлам») аша уң аяктан керергә, Кәгъбәнең төньяк-көнчыгыш



Дәвамы. 2014 елның 3 нче саныннан басылып килә.

почмагындагы «Кара таш» каршына килеп, аны үбәргә *(тәкбил)* яки аңа кулы белән кагылып, кулын иреннәренә тидерергә *(истилам)* тиеш (әгәр халык күп булып, таш янына килергә мөмкин булмаса, ташка кулны сузып, аннары аны үбәргә мөмкин). «Кара таш»ка баш игәннән соң, Кәгъбә тирәли җиде тапкыр әйләнәләр. Кәгъбә тирәсендә әйләнгәндә тәваф кагыйдәләрен белгән ихтыяри сәед җитәкчелек итә. Диварга якын килеп, сәгать йөрешенә каршы барырга кирәк *(кайбер чыганакларда, мәсәлән, рус телендәге «Ислам» энциклопедиясендә – 217 нче биттә – әйләнү юнәлеше нәкъ киресенчә күрсәтелгән, ләкин Насыйр-и Хосрәү, Кәгъбә тирәли әйләнгәндә, сул ягың һәрвакыт Кәгъбә тарафында булырга тиеш, дип яза. –* ***А.Т.****)*. Баштагы өч әйләнәдә кызу адымнар белән атлыйлар (рамал), калган әйләнүләрдә гадәттәгечә атлап барыла. Кәгъбә тирәли җиде тапкыр әйләнгәч, керү урыны янына килеп, диварга гәүдәң белән сыенырга, уң кулыңны керү урынына таба сузып, Аллаһыга, Пәйгамбәргә (с.г.в.) рәхмәт әйтергә һәм гөнаһларыңны ярлыкауны сорарга кирәк. Ахырда ике рәкәгатьле намаз укыла, беренчесе вакытында «Сүрәи әл-Кяфирин»не (109), икенчесе вакытында «Сүрәи әл-Ихлас»ны (112) укыйлар.

Кече хаҗ (гомрә) кылганда тәваф бер тапкыр, ә тулы хаҗ вакытында ике тапкыр – Мәккәгә кергәндә *(тәваф әт-тәхийә)* һәм хаҗ йоласын тәмам иткәндә *(тәваф әл-вәдаг)* кылына. Хаҗга беренче тапкыр килгән кешенең тәвафы *тәваф-и кодум*, ягъни «кавышу (ирешү) тәвафы» дип атала.

Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең хушлашу хаҗы вакытында иң ахырда зөлхиҗҗәнең 14 нче көнендә төнлә Бәйтулланы тәваф итүен дә *саубуллашу тәвафы* диләр ***(Сөнгатулла Бикбулат)***. Шул ук көнне ул Мәдинәгә кайтып киткән.

Чыганакларда *тәваф әл-ифадә* төшенчәсе очрый, аңа хаҗ вакытында, Минәдән кайткач, хаҗиларның Кәгъбә тирәли әйләнүе дип гомуми аңлатма бирелә. Монда *ифадә* сүзе *файда* мәгънәсендә килә булса кирәк.

Татарстанның мөстәкыйльлеге өчен көрәшү көннәрендә (XX гасырның 90 нчы еллары) митингка җыелган халыкның Казанда элекке КПСС Өлкә комитеты бинасын тәваф кылганын хәтерлибез. Ислам принциплары күзлегеннән карaганда, мондый гамәл акланмый, чөнки бу бәдбәхет бина изге түгел (яңа булса да, ун елдан соң сүтеп үк ташланды).

Гомумән, изге урыннарда тәваф кылуның бер Исламга гына хас түгеллеген әйтергә кирәк. Мондый йола христиан дөньясында да билгеле (христианнар кайчагында теге яки бу изге урын тирәли артка таба чигенә-чигенә әйләнеп йөриләр), борынгы гыйбранилар да Иисус Навин җитәкчелегендә Иерихон шәһәре тирәсен әйләнеп чыккач, шәһәр диварлары җимерелеп төшкән, имеш. Менә шушында КПССның Татарстан Өлкә комитеты бинасын җимертү факты искә килеп төшә... ■

Безнең мирас №12 декабрь 2017

БОРЫНГЫ ТАТАР ЙОЛАЛАРЫ

(Ерак чорларга гомуми караш)

Рабит Батулла

ТӘҢРЕ

Безнең борынгы бабаларның табынган «алласы» Күк Тәңре булган. Зәңгәр Күктә кызыл Кояш. Татарлар (төркләр) иртәнге якта Кояшка баш органнар, кичке шәфәкъта Айга иелгәннәр. Игътибар итсәгез, бүгенге татар йорт-капкаларының байтагында өчәр, дүртәр кояш балкый. Әнә каян килә ул архитектура бизәге! Тәңречелек чорыннан! Әүвәлге сугышчыларның калканнарыннан да Кояш елмайган. Бабаларыбыз Кояшны Тәңре итеп күргән.

АШ-СУ

Нинди ырудан, нинди кабиләдән чыгуына карамастан, дала халыкларының көнкүреше бик охшаш булган. Монголлар, татарлар, кыргызлар, казакълар, башкортлар, нугайлар – һәммәсенең тормышы ат-җылкы, дөя, ишәк кебек хайваннар арасында узган. Бүген: «Кымыз, җылкы ите, корот, казы, әйрән, пылау, буза, далачәй (тозлы, майлы куе чәй), тутырылган куй түшкәсе – кайсы халыкның милли ашы?» – дип сорау мәгънәсезлек булыр иде. Барлык дала халыкларының бу тәгамнәрне үз милли ризыгы санарга хакы бар.

Татар беркайчан да үзен яудан исән алып чыккан сугыш атын суеп ашамаган. Татар беркайчан да җир сөргән алашаны чалмаган. Татар беркайчан да ярышта катнашкан чабышкыны суеп ашамаган. Ханнар, падишаһлар, бәкләр, морзалар, гомумән, хәлле татар җылкы ите (җылкы – җигелмәгән, ияр салынмаган, айгыр алмаган, ике яшьлек махсус симертелгән бия), куй ите, дөя ите, сыгыр-бозау ите, кәҗә ите, кош ите, балык ашаган.

Татарларның иң затлы эчемлеге – кымыз, аннан кала – буза, аннан кала – бал булган.

МОТРИБ

«Мотриб» – уен коралы дигән сүз. «Мотрибчы» – музыкант.

Борынгы төрк халыкларының милли музыка уен коралларында да охшашлык күп – кубыз, кылкубыз, курай, сорнай (зурна), саз, гөслә, думбыра, быргы, барабаннар: чыңгырак (көмеш шөлдерле кул барабаны), дөңгер, дум-думбак, гауга барабаны (куркыныч турында кисәтү коралы), дандалай (ачык тавышлы, тиз кагыла торган бию барабаны һ.б.)

Барабаннарны гадәттә песи, арыслан, юлбарыс кебек мәче токымлы җанварларның тиресеннән тарттырганнар. Андый тире яңгыравыклы тавышлы, чыдам булган.

Мөгез сорнай, көй чыгару белән бер-

Ахыры. Башы журналның 11 нче (2017) санында.

гә, «сугыш коралы» да булып торган. Сорнайның тавышы елга буенда 10 чакрым, урманда 5-6 чакрым ераклыкка ишетелгән. Чигенергә кирәктә, быргычы-сорнайчы аерым бер көй кычкырткан, дошман өстенә ябырылыр өчен, аерым бер көй чыгарган.

Сугышлар тынып торганда сорнай-быргы аучыларга хәбәр җиткерүче булган. Адашканнарны, артык ерак киткәннәрне бергә туплаучы, барлаучы вазыйфасын үтәгән.

Тирмә тирәли кичке уеннарда бу кораллар кыз-егетләрне биеткән, җырлаткан, туйлар уздырган.

Казанда Мөхәммәт Әмин хан сараенда кыллы, барабанлы, тынлы уен коралларыннан торган оркестр булган, диләр. Сарай «театры» репертуарын «Сак-Сок», «Йосыф-Зөләйха», «Ләйлә-Мәҗнүн» кебек музыкаль әсәрләр тәшкил иткәндер, мөгаен.

ТОРАК

Борынгы төркләр кече чатырларда, тирмәләрдә гомер кичергән. Бер гаиләдә (ягъни бер киез йортта) ун-егерме кеше яшәгән. «Йорт» («юрта») сүзе ике мәгънә белдергән. Беренчесе – киез, тула, тире белән тышланган өй. Икенчесе – ил, ватан.

Киез йортны икенче төрле «тирмә» дип атарга мөмкин. Урысның «терем-теремок» сүзе шуңа барып тоташа. «Төрмә» сүзе дә.

Шаңгырак – төнлекнең түгәрәк, тәгәрмәчкә охшаш «агачы».

Төнлек – чатыр түбәсендә төтен чыгару өчен калдырылган ачыклык.

Кирәгә (киерге) – чатырның «кабыргасы» (сөлдәсе, каркасы).

Киез йортта җәйге кызу көндә салкынча температура сакланган. Салкын вакытта, киресенчә, йортта бик җылы булган.

Берничә йөз ел артка чигенеп, әйдә, хөрмәтле укучым, тирмә корып карыйк...

Иң башта киез йортның сөлдәсен җыябыз.

Киез йортның киергеләре (терәкләре) нечкә каен яисә тал ботагыннан ясала. Киергенең юанрак башы туфракка кадала. Нечкә башы өскә карап кала.

Киергеләрне нечкә бау белән үзара беркетәбез. Алар түбәдә бергә җыела, ләкин кушылмый. Килеп чыккан корылманың иң очына шаңгырак урнаштырыла. Шаңгырак үзе түгәрәк, аның аркылы-торкылы тоташкан киги-тырнаклары була. Болай караганда ул бик тә арба тәгәрмәченә охшап тора.

Шаңгырак беркетелгәннән соң, «ча-



Татар күчмә тирмәсе. XIX гасыр гравюрасы

тыр» ите ашалып беткән зур балыкны хәтерләтә башлый. Сөлдә әзер.

Хәзер сөлдәне киез белән каплыйбыз, озын-озын арканнар белән урап алабыз, ныгытып бәйлибез, аннан соң тире ябабыз. Шаңгыракны, төнлек юлын ачык калдырабыз. Шулай да, төнлекне каплау-ачу мөмкин булсын өчен, каплавыч беркетәбез, бу эшкә ярдәм итсенгә, эчке-тышкы яктан бау сузабыз. Агач яисә келәм-палас ишек куябыз. Идәнгә киезләр, келәмнәр, паласлар җәелә, сандыклар кертелә, алар өстенә мендәрләр өелә, уртада учак урыны калдырыла.

Киез йортның бер читенә баз казыла. Ул базда кымыз, сөт, ит сакланачак.

Чатырның шаңгырагы атадан – балага, баладан оныкка күчә бара. Ул – нәсел тамгасы, ил-йортның, ватанның, гаиләнең нигезе.

«Шаңгырагын чапкалап ташлау» гыйбарәсе «нәселен корыту»га бәрабәр.

КИЕМ-САЛЫМ ҮРНӘКЛӘРЕ

Бикасап – буй-буй ефәк тукыма.

Бишмәт – мамык, чүпрәктән сырган калын өс киеме.

Бөркә – бурка, тире тун.

Кандагай – тиредән тегелгән ыштан (ботны, аякларны кылычтан саклаган).

Җилән – юка туладан тегелгән өс киеме.

Җөббә – киез чапан.

Толга – тимер баш киеме, очлым. Җөмләдән, «очлым» сүзеннән «шлем» килеп чыккан.

Хөллә – сырып тегелгән җиңел өс киеме.

Чапан – яңгырдан, тузаннан саклану өчен бөркәвеч.

ЯЗУ-СЫЗУ

Тузга язмаганны дөрес булса да сөйләмә, дигән гыйбарә бар. Димәк, безнең борынгы бабаларыбыз каен тузына язган?! Алайса, нигә тузга язылган бер генә татарча артефактның да табылганы юк соң? Урысларда «берестяная грамота» дигәне сирәк булса да очрап тора. Билгеле, күренеш үзе булмаса, тиктомалдан төшенчә (яисә, бу очракта – гыйбарә) дә туа алмый. Шуңа күрә, баягы гыйбарәне раслар өчен булса да татарча-төркчә язылган каен тузы табылыр әле, Аллаһ боерса.

Аның каравы, безнең борынгы бабаларыбыз ташка язган. Таш янмый да, ватылмый да. Заманында Күлтәгин язмалары дөньяны таң калдырган иде. Ташка язар өчен кулай хәрефләр кирәк булган, билгеле. Һәм ул хәрефләрне уйлап тапканнар да: аларны тарихчылар хәзер «рун язуы» дип атый.

Ары таба, мәгълүм булганча, бабаларыбыз каурый, камыш, сөяк, тимер каләмнәр ярдәмендә яхшы иләнгән тирегә, кәгазьгә гарәп хәрефләре белән язуга күчкән.

Кара савытлары балчыктан, бронзадан, тимердән ясалган. Кара төстәге караны корымнан ясаганнар, башка төстәгеләрен төрле-төрле үләннәр катнашмасыннан барлыкка китергәннәр.

XIII йөздә яшәгән атаклы хаттат (каллиграф) Яхут Моставый болай язып калдырган: *«Каләмнең башы төерле вә йомшак булса хуп. Кәгазьгә куеп яза башлаганда шыгырдау тавышы чыгарса, каләм яхшы булыр. Каләм әзер булганнан соң, нокта ясап карарга кирәк: әгәр нокта матур, ачык чыкса, каләм һәйбәт ясалган булыр».*

АКЧА, СӘҮДӘ

Сәхабәләр заманында шәригатьчә чүкелгән бер тәңкә (дирһәм) 7 мыскал алтын авырлыгында булган (бер мыскал 4,25 граммга тигез).

Дала халыклары Себер, котып тарафында яшәүче боланчылар, аучылар белән сәүдә иткәндә акча кулланмаган. Төньяк халкы дала кешеләренә затлы-затлы тиреләр китергән. Дала «хуҗалары» исә алмашка җылкы, сыер, үгез, савыт-саба, комач-ефәк, мал-туар тәкъдим иткән.

Бирерәк чорларга карасак, урыс ягыннан – тоз, җитен, постау, киндер, балта, пычкы, энә, Казаннан – балык, балык мае, мех, тире-яры, Нугайдан – яхшы

атлар, Кавказдан – йөзем, шәраб, корыч, иярләр, авызлык, дирбия, тимер кораллар, фарсы ягыннан – ефәк, мамык, кәгазь, ситсы, комач, бизәнү әсбаплары килүен күрербез.

АТЫҢ КЕМ?

Ислам динен кабул иткәч, борынгы бабаларыбыз, үзләренең буыннан-буынга күчеп килгән исемнәрен ташлап, балаларына гарәп исемнәрен куша башлаган. Асылыбызга кайтуда исем-атның зур мәгънәгә ия булуын аңлаган хәлдә, милләтебезгә озын гомер һәм бөек киләчәк теләп, сезнең игътибарга онытылган яки онытыла язган үз исемнәребезне тәкъдим итәбез:

Абруй
Азамат
Айзирәк
Акбүре
Алпамша
Алпар – алып ир, батыр ир
Армай – сакчы, аяусыз сугышчы
Байсунгар
Байморат
Байраш
Байтар – ат белгече, мал-туар белгече
Байхан
Бар(ы)сбәк – барс кебек көчле бәк
Биктархан
Буртас
Бүре
Ватан
Гөлбәдран – Бабур солтанның апасының исеме
Гөлбикә
Гөлзирәк
Гөлизар – чәчәк аланы
Гөлрух
Гөлстан – гөл бакчасы
Гөлсирин
Гөлтаҗи
Гөлчәһрә (Гөлчирә) – гөл чырайлы
Гүзәлтаң
Дастан – батырлыкны мактау җыры
Дулат
Елгыр
Җиһангир – җиһанны яулап алучы
Җәйлан – кыз исеме
Җәйран – кыз исеме
Зөбәрҗәт
Зурлан – зур олан
Илбарс
Илтабар
Инзар
Ират
Кадербай
Кайрак
Кафия
Кифая
Котлыбай
Котлый
Кочарбәк
Кучкар
Мирас
Мират
Мирза
Нәүруз
Нуркалфак
Нуркоя
Нурсибәр
Нурлан – нурлы олан
Очарби
Сайра
Сайран (Сәйран, Сирин)
Саклан – сак олан
Санай
Саргөл – сары гөл
Салия – кыз исеме
Сорур – кыз исеме
Субай
Таймас – таймыйча алга баручы
Талмас – армый-талмый торган, куәтле ир-егет
Таңгүзәл
Тараш
Тәбриз
Туйра – яшь имән
Туктар
Туктамыш
Тунар
Тунтар
Туран
Тургай
Уктай – ук кебек җитез
Ханнан
Чалу
Шәрхан – арыслан хан
Ширин
Шоңкар – ау кошының бер төре
Яугир
Яшенташ ■

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

2000 елда патент бүлегендә электрон уку залы ачылды, документларны электрон юл белән алдыру хезмәте күрсәтелә башлады. Укучылар телекоммуникация элемтәсе аша ерактагы бүтән китапханә фондларыннан документларны соратып алдыра алалар. Мисалга: Россия дәүләт китапханәсе, Россия милли китапханәсе, Дәүләт тарихи җәмәгать китапханәсе, Җәмгыять фәннәре буенча фәнни мәгълүмат институты һ.б. белән тыгыз элемтә урнаштырылды. 2000-2001 елларда чит телләрдәге әдәбият бүлегендә мультимедиа мәгълүмат үзәге; АКШ илчелеге теләге буенча оештырылган Америка үзәге; Гёте исемендәге алман мәдәни үзәге белән берлектә гамәлгә куелган Алман залы ачылды.

Мәгълүматны җиңел, теләгәнчә алу өчен, фондның гадәти каталог-картотекаларыннан һәм сайтка кертелгән электрон мәгълүмат байлыгыннан файдаланырга мөмкин. Милли китапханә уникаль мәгълүмат базаларын төзи, социаль-гуманитар теманы эченә алган тулы текстлы коллекцияләр туплый, белешмә-энциклопедик һәм библиографик эчтәлекле дөньяви күпкырлы мәгълүмат чыганакларын алдыртып, бер кулга җыя бара.

Китапханәнең 2000 елда ясалган веб-сайтында (адресы: http://kitaphane.tatarstan.ru) башка беркайда кабатланмаган мәгълүмат тупланмасы урын алды. Веб-сайтта урын алган төп мәгълүмати бүлекчәләр: яңалыклар, китапханә тарихы, бүгенге эшчәнлеге, китапханә структурасы, мәгълүмат ресурслары, күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге, документларны электрон юл белән алдыру мөмкинлекләре, китапханәнең дуслары, кунаклар кенәгәсе. Мөрәҗәгать итүчеләрнең саны елдан-ел арта бару бу сайтның елдан-ел киңрәк танылуын раслый. Веб-сайтка шулай ук читтән дә, исемләп атаганда, Бөекбритания, Франция, Төркия, Кытай, Швейцария, Япония кебек илләрдән дә мөрәҗәгать итәләр.

Бу сайтның электрон китапханәсендә «Меңьеллык Казан», «Татар электрон китапханәсе», «Татарстан Республикасы мәдәнияте һәм сәнгатенең мәшһүр затлары: белешмәлекләр», «Библиографик басмалар», «Яңа кергән басмалар», «Сценарийларның тулы нөсхәләре» дигән электрон коллекцияләр бар.

«Меңьеллык Казан» электрон коллекциясе 2002 елдан туплана башлады. Анда

*Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.

XVII-XIX гасырларда һәм XX гасыр башында иҗат ителеп, Казанның һәм Татарстанның тарихын, архитектурасын чагылдырган, зур кыйммәткә ия татарча һәм русча уникаль әсәрләр-хезмәтләр кертелгән. «Татар электрон китапханәсе» коллекциясенә йөз татар әдибенең (классиклар һәм бүгенгеләр) милли телдәге әсәрләре тупланды. «Татарстан Республикасы мәдәнияте һәм сәнгатенең мәшһүр затлары: белешмәлекләр» коллекциясе әдәбият-сәнгать дөньясындагы атаклы шәхесләрнең юбилейларына багышланган. Монда «Габдулла Тукай», «Муса Җәлил», «Сара Садыйкова», «Кәрим Тинчурин», «Галимҗан Ибраһимов», «Фатих Хөсни», «Әмирхан Еники» һәм башка сәхифәләр урын алган.

2009 елда «Электрон Татарстан» дигән республикакүләм максатчан программаны тормышка ашыру юнәлешендә Милли китапханә документларны, Татарстанның мәдәни мирасын электрон формага күчереп, алар белән танышуны җиңеләйтү өчен, китапханә һәм мәгълүмат технологияләре дигән бүлек ачты. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2009 елның 31 августында кабул иткән 592 нче Карар белән «2009–2014 елларга һәм 2020 елга кадәр Татарстан Республикасында китапханәләр эшенең үсеше» дигән озак вакытка исәпләнгән максатчан программа расланды. 2010 елдан башлап Милли китапханә әлеге Карардагы «Китапханәчелек өлкәсендә мәгълүмат-арадашчылык технологиясен нәтиҗәле үстерү» дигән бүлектәге бурычларны гамәлгә ашыра башлады. Бу инде Татарстан Республикасында китапханәләр челтәренең бердәм мәгълүмат кырын (мәйданын) булдыру максатына ирешү дигән сүз.

Милли китапханә автоматлаштырылган «РУСЛАН» китапханә-мәгълүмат системасын үзләштерде, «Татарстан Республикасы китапханәләренең җыелма электрон каталогы» мәгълүмат системасына катнашып китте, алай гына да түгел, ул аның әйдәп баручысы булды. Шул рәвешчә, Татарстан китапханәләренең 600 мең библиографик язмасы тупланган каталогтан файдалану мөмкинлеге туды. Бу мәгълүмати система Татарстан Республикасының гамәлдәге электрон китапханәсе порталында тормышка ашырылды. Аның сәхифәләрендә республика китапханәләре һәм муниципаль китапханәләр фондларында сакланачы документлар хакында библиографик мәгълүмат һәм документларның тулы текстларының электрон күчермәсе урнаштырылган.

Мәгърифәтчелек эше Милли китапханәгә йөрүчеләргә һәрьяклап уңай шартлар тудыруда чагыла; эшчеме ул, ял итүчеме, галимме ул, иҗат кешесеме – һәммәсенең мәнфәгатен канәгатьләндерергә мөмкинлек тудырылган. Китапханә хезмәткәрләре әдәби-музыкаль кичәләр оештыралар, «Опера дөньясына сәяхәт» («Путешествие в мир оперы») видеосалоны, «Музыкаль кунакханә», «Театр кунакханәсе» утырышлары уздырыла; инглиз һәм алман телләрендә аралашу клубларында инглиз һәм алман әдәбиятын яратучылар кызыклы очрашулар үткәрәләр.

Милли китапханә эшчәнлегендә киң үсеш алган тармак-юнәлешләрнең берсе – ул төрле бүлекләр тарафыннан әзерләнгән төрле исемдәге күргәзмәләр оештыру. Күргәзмәләр һәм мәдәни программалар бүлеге китапханәгә килгән яңа басмаларны бергә туплап күрсәтә, алар укучыларда зур кызыксыну тудыру сәбәпле, бу күргәзмәне әледән-әле яңартып тора, шулай ук, истәлекле даталарга һәм мөһим вакыйгаларга туры китереп, үзенчәлекле тематик күргәзмәләр дә куя. Шундыйларның кайберләрен генә искә төшерик:

– «Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын» дип аталган күргәзмә Республиканың Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә башлауның 55 еллыгына багышланды;

– «Спорт калейдоскобы» 2013 елгы Универсиада белән таныштырды;

– «Халыкның рухи таянычы», Чыңгыз Айтматовның 85 еллыгына багышланып,

Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин

Миркасыйм Габделәхәт улы Госманов

Кыргызстан вәкилләре катнашында үткәрелде.

Милли китапханә фәнни-тикшеренү үзәге буларак та актив үсә. Моңа Гыйльми шура (1997) һәм Химаячеләр шурасы (2000) оештырылу зур этәреш бирде. Башкалабыз Казан һәм республика китапханәләренең тарихын өйрәнү, эзләнүләр алып бару эзлекле җайга салынган, мондый эшчәнлек кысаларында китапханәләр һәм китапханәчелек турында яңа материаллар табыла тора, алар профессиональ, үзәк һәм җирле матбугат битләрендә чагылыш таба.

«Һәр халыкның үзенә генә хас бер сыйфаты була, диләр. Аның ерак һәм якын узганын, бүгенгесен, хәтта киләчәген дә билгели торган төп сыйфаты – милли сыйфаты. Безнең халыкның шундый төп үзенчәлеге нәрсәдән гыйбарәт соң? Халкымның башка күп яхшы гадәтләрен истә тоткан хәлдә, аның милли йөзен, рухи кыяфәтен билгели торган төп үзенчәлеге дип, иң элек бер сыйфатны әйтер идем. Ул бер сүзгә сыеп бетә: «Китаплылык...»

Миркасыйм Госманов

Китапханәнең фәнни киңәшчесе, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, язучы Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин татар китабын тарихи катламнардан күтәреп алуда искиткеч зур тырышлык куйды. Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хезмәткәрләре аның җитәкчелегендә «Татар иске басма китабының җыелма каталогы»н (1722-1917 еллар) төзергә керештеләр. Бу эш бүген дә алып барыла. Тарихчы, археограф, тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Миркасыйм Габделәхәт улы Госманов та китапханәнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре иде.

Көндәлек эш барышына ярдәм итә торган социологик эзләнү-сораштырулар да китапханә тормышын күпкә мәгънәлерәк итә. Менә аларның кайберләре: «Татарстан Милли китапханәсе хезмәткәрләренең китап укуы» (2007), «Татарстан Милли китапханәсендә уздырылган күргәзмәләрнең тәэсир-йогынтысы» (2008),

Фәнни-гамәли «Китапханә хәбәрләре» журналы

Хәзинәләрнең гаҗәеп олысы – яхшы китапханә.

Виссарион Белинский

«Ачык мәгълүмати җәмгыять формалашып килү җәһәтеннән Татарстан Милли китапханәсе» (2010), «Укучы китапханәче хакында: китапханәдә аралашу җәһәтеннән» (2013), «Укучы укучы хакында: китапханәдә аралашу җәһәтеннән» (2014).

1997 елдан бирле, махсус Нигезләмәгә таянып, Милли китапханә хезмәткәрләренең китапханә хезмәтенә, библиография һәм китап белеменә багышлап язылган фәнни эшләренә бәйгеләр үткәрелә. 1996 елда Милли китапханә «Китапханә хәбәрләре» дип исемләнгән фәнни-гамәли журнал чыгара башлады. Монда республикадагы фәнни, югары уку йортларына караган, академик китапханәләр, яшүсмерләр һәм балалар китапханәләре эшчәнлеге киң яктыртыла. Журнал битләрендә күбрәк китапханә рухын эчтән тоеп, үз тәҗрибәсе аша үткәрүчеләр, китапханә һәм китап белеме өлкәсендә азу ярган белгечләр катнаша. 2009 елда «Китапханә хәбәрләре» төбәкләрдәге вакытлы матбугат басмалары арасында үткәрелгән, «Библиопресса-регион – 2009» дип аталган III Бөтенроссия конкурсында «Журналлар» номинациясендә Диплом яулады.

Үзара килешеп, фикерләшеп эшләү үзәге буларак, Милли китапханә республика җирлегендә урнашкан барлык төр китапханәләр эшчәнлеген фәнни һәм методик җәһәттән тәэмин итә. Республиканың Мәдәният министрлыгы бүләгенә үткәрелә торган, китапханә хезмәткәрләренең иҗади активлыгын үстерүгә, һөнәри камиллеккә, яңалыкка омтылышын үсендерүгә юнәлтелгән «Әйдәп баручы» һәм «Иҗади эзләнү» бәйгеләрен ул 2000 елдан башлап оештырып килә.

Татарстанның Милли китапханәсе халыкара абруйга ия, ул – Россия китапханәләре ассоциациясенең тулы хокуклы әгъзасы. Шулай ук Халыкара китапханәләр ассоциацияләре һәм учреждениеләре федерациясе (ИФЛА) әгъзасы буларак, киңәшмәләрдә, конгрессларда катнаша. Милли китапханә арадашчылык мөнәсәбәтләрен елдан-ел ныгыта бара: китап алмашу буенча чит илләрнең, Россия Федерациясенең һәм Татарстанның йөздән артык китапханәсе белән хезмәттәшлек итә. Чит ил китапханәләре белән максатлы хезмәттәшлек уртак проектларны гамәлгә ашыруны, тәҗрибә уртаклашуны, белгечләр хәзерләүне, заманча күргәзмәләр оештыруны һәм башка шундый чараларны күздә тотып эшләнә.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе эшчәнлегенең заманча юнәлешләре, аның бөтен дөньядагы китап укучылар һәм мәгълүмат кулланучылар тарафыннан сорала торган кабатланмас мәгълүмат байлыклары, киңкүләм иҗтимагый-мәгърифәтчелек эше милли мәдәният, фән, мәгариф хәзинәләрен саклауга һәм үстерүгә мөһим өлеш кертүе хакында сөйли.

Китапханәдә «Театр кунакханәсе» мәҗлесе

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1917 елның декабрь ае

Сәхифәне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Казанда татар ханлыгы ясарга телиләр...

Бу көннәрдә, һәркөн дип әйтерлек, Казанга читтән мөселман гаскәрләре килә. Өченче көн бер эскадрон атлы гаскәр, кичә 500 кадәр җәяүле гаскәр килде. Бу гаскәрләр, казармалар тәмам хәзерләнгәнчегә кадәр, мөселман арасындагы хосусый йортларда урнаштырыла.

Шәһәрдәге русларның Алладан тынычлык кына сорап гомер итә торганнары татар солдатларының килүләренә үзләренчә мәгънәләр бирәләр. Мөселман атлы гаскәрләре килгән вакытта Воскресенски урамнан яшел әләмнәр белән татарча җырлап килүләре төрлесендә төрлечә тәэсир калдырган. Кайсыберсе, Казанда татар ханлыгы ясарга телиләр икән, дигән фикергә килгәннәр. Русиянең хәзерге хәлендә тәмам өмидсез хәлгә килгәннәре, татарлар шәһәрдә тәртип сакларга килгәннәр, дип уйлаганнар. Ичмасам, татарлар тизрәк тәртип кертеп, безне үз химаяләренә алсыннар иде, диләр икән!

Кояш. – 1917. – №1188. – 5 декабрь.

Хәрби оешмаларның кушма мәҗлесе

4 декабрьдә Казан округ хәрби мөселман комитетының тәшәббесе [инициативасы] белән Казандагы мөселман хәрби вә ротный комитетның кушма мәҗлесе булды. Мәҗлесетә, солдатски секциядә 95 нче полкны мөселманлаштыру мәсьәләсен караганда, хәрби оешмалардан йибәрелгән вәкилләрнең докладлары тыңланыла.

Секциядә 95 нче полкны мөселманнарга бирергә руслар каршы килгәннәр вә күп мөзакәрәдән [фикер алышу] соң, мөселманнарга аерым полк төзергә, дигән карар чыгарганнар, ләкин бу полкны булдыру эшендә аерым комиссия төзеп, шул комиссиягә күбрәк русларны кертмәкче булганнар. Мөселманнар, моңа разый булмыйча, байтак сөйләсәләр дә, аларның сүзләре игътибарга алынмагач, мәҗлесне ташлап китәргә мәҗбүр булганнар. Бу хакта күп мөзакәрәләрдән соң, руслар тарафыннан сайланган комиссиягә кеше кертмәенчә, биш кешедән торган комиссия сайланып, бу көннән үк эшкә керешергә булды вә шул ук комиссиягә мөселманнарның ни өчен руслар тарафыннан төзелгән комиссиядә катнашмауларын мәгълүм итү тапшырылды. Мәҗлесне ябар алдыннан 95 нче полк солдатларының, зур митинг ясап, 95 нче полкны мөселманнарга бирергә, дип карар биргәнлекләре беленде.

Кояш. – 1917. – №1189. – 8 декабрь.

Балалар кичәсе

13 декабрь мәүлед бәйрәме булу мөнәсәбәте илә, «Новый» клуб залында Казан мөслимәләр җәмгыяте тарафыннан бик киң программа белән балалар кичәсе ясалачак. Кичәдә «Чәчәкләр арасында» дигән 2 пәрдәлек пьеса куелып, декламацияләр башкарылачак. Елның гадәттән тыш кыйммәтлегенә карамыйча, билет бәһаләре гаять арзан куелды (3 сум 50 тиен). Бу ел һичбер йирдән һичнәрсә табу мөмкин булмадыктан,

---

Даталар иске стиль белән бирелә.

балаларга һәдия [бүләк] бирелми. Елда бер генә була торган бу кичәгә һәр ата-ана балаларын йибәрерләр, дип ышанамыз. Билетлар хәзердән «Гасыр» китапханәсендә сатыла башлады.

Кояш. – 1917. – №1190. – 10 декабрь.

Казанда гаскәри көчемезне оештыру

Бу көннәрдә төрле йирләрдәге вак-вак татар гаскәри фиркаләрне Казанга тарту башланды. Гаскәри гаммәмездән [масса] тиз арада, милли бер дисциплина астында, милли гаскәр тәшкил итәчәгенә гаять зур өмид баглыйбыз. Хәрби шурамыз самими, милли юл белән бер дә тәрәддед [икеләнү] вә шөбһәсез барса, гаскәри гаммәмез озакламый үзе өчен табигый, рухы өчен якын шул юлга керәчәк вә шул юл белән китәчәктер. Моннан соң инде гаскәремез рус «товарищлар»дан аерым яши башлап, алар даирәсендәге башбаштаклыкның тәэсиреннән ераклашкач, алар арасында милли вә мәдәни хезмәт итү, аларны хулиганлыктан саклап, чын татар-мөселман гражданины дәрәҗәсенә күтәрү күпкә җиңеләячәктер. Фәкать самимият, халкымызны сөю, халкымызның хулиган түгел, бәлки эшче бер демократиядән гыйбарәт икәненә ышану кирәктер. Гаскәри зыялыларымызда бу ышану вә бу иманның барлыгында без шөбһә итмимез. Казанымызда милли полк төзи торган гаскәри кардәшләремезгә өмид һәм ышанычлы сәламнәремне йибәрәмез! Милләт сезгә күзләрен теккән хәлдә, бөтен милли таләпләремезгә терәк булуыгызны сездән таләп итә вә кирәк вакытта сезнең милли хезмәтләргә хәзер булачагыңызга ышана!

Шәрык кичәсе

18 декабрьдә «Новый» клубта укучы яшьләрнең оешмасы «Берек» тарафыннан нәфис вә күңел ачкыч номерлар белән тулы программада «Шәрык кичәсе» ясалачактыр. Кичәнең тулы вә матур чыгуы өчен җитди хәзерлекләр барадыр. «Берек» идарәсе.

«Кояш». – 1917. – №1191. – 12 декабрь.

Гаскәри парад

Мәүлед бәйрәме булу мөнәсәбәте илә, Казан губернасындагы бөтен мөселман гаскәриләре зур бер парад ясады. Көннең салкынлыгына карамыйча, иртәдән Юнысовлар мәйданына парадны карар өчен халык җыела башлаган иде. Сәгать унбергә таба саф-саф булып гаскәри фиркаләр җыела башладылар. Яңа килгән атлы гаскәрләр дә катыштылар. Халык җыелып беткәч, Габдулла Апанаев тарафыннан Коръән укылып, дога кылынды. Коръән укылганнан соң, гаскәри музыка тавышлары илә берсе артыннан берсе уза башладылар. Парадка Казанда булган Хәрби шура, Казан округы хәрби комитеты һәм Казан хәрби комитетының әгъзалары – һәммәсе килгән иде. Парадны полковник Якубовский кабул итте.

Кояш. – 1917. – №1192. – 17 декабрь.

Зур янгын

16 декабрьдә, кич сәгать 5ләрдә Крестовниковның гаскәри химический заводы янды. Шуның янында ук агулы газ заводы да булганлыктан, бөтен көч шуны сакларга сарыф ителде, чөнки әгәр анда ут капса, күлнең сул ягы, ягъни шәһәрнең мөселман кыйсемендәге [өлешендәге] бөтен халыкның ис белән һәлак булуы ихтимал иде. Белгечләр әйтүенчә, гәрчә мондый газ сугыш мәйданына йибәреп кулланыр өчен гамәлгә ашарлык булмаса да, Казан халкын гына үтереп бетерергә йитәрлек икән.

Кояш. – 1917. – №1193. – 19 декабрь. ■

ДЕКАБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Питрәч районының Шәле урта гомуми белем бирү мәктәбенә 100 ел тулды. Әлеге белем йортын тәмамлаучылар арасында Россиянең Европа өлеше мөселманнары диния нәзарәте һәм Мөфтиләр шурасы рәисе, мөфти шәех Равил хәзрәт Гайнетдин, генерал-лейтенант Габбас Зәйнуллин, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы генераль директоры Шамил Садыйков, язучы-сатирик Камил Кәримов, Г.Кариев театрының баш режиссеры Ренат Әюпов, К.Тинчурин театры артисты Ренат Шәмсетдинов, журналист-язучы Мәгъсүм Гәраев һәм мәрхүмә журналист Алсу Хәсәнова кебек танылган шәхесләр бар.

● 1 ноябрьдә Казанның Яңа Татар зиратында мәшһүребез – Татарстанның халык артисты (1970), Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Сара Садыйкова (1906-1986) каберенә чәчәк салу чарасы узды.

● 2 ноябрьдә Арчаның Г.Тукай исемендәге педагогика көллиятендә «Туган тел, гореф-гадәтләр: киләчәккә караш» исемле «түгәрәк өстәл» утырышы узды. Утырышта Арча муниципаль районы хакимияте башлыгы Илшат Нуриев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт, күренекле галим Рүзәл Юсупов, Татарстанның халык артисты Шамил Әхмәтҗанов, шагыйрьләр һәм галимнәр Хәнәфи Бәдигый, Рифат Җамал, язучы Вакыйф Нуриев, журналист Риман Гыйлемханов, «Безнең мирас» журналы хезмәткәре Ленар Гобәйдуллин һ.б. катнашты.

● Әгерҗе районы Кырынды авылында яшәп иҗат итүче өлкән язучыбыз – 90 яшьлек Габдулла ага Галиевнең «Мәхәббәт һәм мәкер» исемле яңа китабы дөнья күрде.

● Әлмәтнең Гагарин урамындагы 10 нчы йорт диварына Татарстан Республикасының беренче Премьер-министры Мөхәммәт Галләм улы Сабиров (1932-2015) истәлегенә таштакта беркетелде.

● Язучы Мирсәй Гарифның бөек шагыйребез Габдулла Тукай белән Зәйтүнә Мәүлүдовага нисбәтле «Мәңгелек мәхәббәт» китабы Төркия кибетләрендә сатуга чыкты. Әсәрне татарчадан төрекчәгә Төркиянең Кавказ университеты галимәсе, шагыйрә Чулпан Зариф-Четин һәм Мугла университеты галиме Хәяти Йылмаз тәрҗемә иткән. Китапның мөхәррире – Евразия Язучылар берлеге рәисе Якуп Өмәроглы.

● Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты һәм Бөтенроссия Татар авыллары иҗтимагый оешмасы («Безнең мирас» журналы белән бергә) игълан иткән «Минем авы-

лым» бәйгесенә эшләр кабул итү 2017 елның 25 декабренә кадәр дәвам итә. Конкурсның нәтиҗәләре 2018 елның мартында игълан ителәчәк.

● Татарстан китап нәшрияты күренекле язучы Мәхмүт Хәсәновның (1927-1990) алты томлык сайланма әсәрләреннән ике томын бастырып чыгарды.

● 15 ноябрьдә Казанның Дәрвишләр бистәсендәге Төзелеш көллиятендә татар халкының күренекле шагыйре Зөлфәтнең (1947-2007) тууына 70 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Кичәдә Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ, Татарстанның халык артисты, язучы Хәлим Җәләй, Башкортстанда яшәп иҗат итүче шагыйрә Халисә Мөдәррисова, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Ләбиб Лерон чыгыш ясады.

● 15 ноябрьдә Киров өлкәсенең Нократ Аланы районы Иске Пенәгәр авылында «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары оешмасының (җитәчесе Кадрия Идрисова) күчмә утырышы узды. Чарада «Безнең мирас» журналы хезмәткәре Ленар Гобәйдуллин катнашты.

● 15 ноябрьдә Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә Татар Пен-клубының (президенты Разил Вәлиев) чираттагы утырышы булды.

● 16 ноябрьдә Татарстан Фәннәр академиясендә «Глобализация шартларында татар халкының этно-дини тәңгәллеге» дип аталган фәнни-гамәли конференция узды. Конференциянең пленар утырышында Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты, академик Дания Заһидуллина, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисенең беренче урынбасары Данис Шакиров, Татарстан Диния нәзарәте рәисе урынбасары Мансур хәзрәт Җәләлетдин һәм Екатеринбург, Омск, Бишкәк, Минск шәһәрләреннән килгән галимнәр чыгыш ясады. ■

Мирасворд

Әнәс Галиев романы

Жәйдак аягын куйсын өчен, иярнең ике ягындагы каеш очына тагылган җәйлама

Әхмәтҗанов, Ваһапов, Гәрәй

Мәшһүр ат карагы

Казакъларда, татарларның кайбер этник төркемнәрендә: сюжетлы җыр

Халык ... иҗаты

Гарәп язуында тартыктан соң сузык авазның булмавын күрсәтүче билге

Нәҗми, Латыйп

Крепость корылмасы

Мисыр мифологиясендә җир Алласы

Татарстанның халык шагыйре

Сәгыйди, Кәримуллин

Борынгы Русьта: эре җирбиләүче

Борынгы Мисыр каласы

Сәяхәтчеләр, сәүдәгәрләргә юл күрсәтүче, кәрваннарны озатучы (бор.)

... - баба йоласы

Балавыз (иск.)

Морза, түрә

Казандагы мәчет

Итле, яшелчәле ризык

Киемгә теген бизәк төшерү өчен кулланылучы ефәк шнур

Мисыр мифологиясендә кояш Алласы

Япон драма театры

Шәриф Камал хикәясе

... - лейтенант

Ир уңган булса, хатын ... була

Эт токымы

Кипкән тирене кысага тартып, аңа шөлдерләр таккан уен коралы

Әрмән стан акчасы

Кристиан ... (француз модельеры)

Әрмән таулыгындагы борынгы дәүләт

Мөсәгыйт Хәбибуллин романы

XVIII йөз төрекмән шагыйре

Африкадагы ил

Сугарга диган кенәләрне кипрү корылмасы



... Суручану (молдаван җырчысы)

Алман микробиологы

Дымлы штукатурка өстенә махсус буяу белән төшерелгән бизәк

Нота

Нәкый Исәнбәт комедиясе

11 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: турсык, Камю, Саар, Бәшири, Расих, лыбы, рад, Җик, кереш, ясавыл, Фәндәс, Рим, «Уен», Ника, Гали, әр, Бакиров, кельт, икс, «Ася», әлиф, шор, иләт, Мар.
Өстән аска: феникс, Әминә, Ләке, Кәлилә, «Тәмсил», «Ядкарь», ит, арыш, «Каиб», Ясриб, Суар, ила, «Кармак», Ключарев, Гидаш, сары, сом, Иделле, «Яра», «Нева».

Рәис Габдулла төзеде.

«Хөсәения» мәдрәсәсе. XX гасыр башы

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЕЛЪЯЗМАСЫ / ДЕКАБРЬ

• 635 ел элек (1382)

Мәскәүне яулап алганнан соң, Туктамыш хан җитәкчелегендәге Алтын Урда гаскәре төркем-төркем булып төрле якка таралыша һәм урыс калаларын «йөреп» чыга. Шул рәвешле, Владимир, Переяславль, Юрьев, Звенигород, Можайск, Боровск, Руза, Дмитров шәһәрләре вә бихисап авыллар кабаттан Сарай хакимияте карамагына күчә.

• 180 ел элек (1837)

Сәүдәгәр, җәмәгать эшлеклесе, хәйрияче, мәшһүр «Хөсәения» мәдрәсәсенә нигез салучыларның берсе Әхмәт Гали улы Хөсәенов (1837-1906) Оренбург губернасының Каргалы бистәсендә дөньяга килә.

• 155 ел элек (1862)

Күренекле галим, төрки дөнья белгече Василий Радлов (Фридрих Вильгельм Радлов (1837-1918) Голҗа каласына (хәзер Кытай Халык Республикасына керә) сәяхәт кыла. Ул, ошбу сәяхәтен тасвирлаганда, биредә татарларның күп булуын, байтагының сәүдә эшендә уңыш казануын, аларның башка милләтләр белән тату яшәвен, Русиягә караганда, үзләрен монда шактый дәрәҗәдә иркен вә азат сизүләрен ассызыклый.

• 100 ел элек (1917)

Мәскәүдә татар яшьләренең «Ташкын» исемле музыка һәм драма түгәрәге оештырыла.

• 95 ел элек (1922)

Милләтләр Халык Комиссариаты каршында «Мәркәз шәрык нәшрияты» ачыла.

• 80 ел элек (1937)

25 декабрьдә Татарстан Советларының Гадәттән тыш IX съезды ТАССРның яңа Конституциясен кабул итә.

• 75 ел элек (1942)

Фатих Кәрим фронтта «Разведчик язмалары» повестен язып бетерә.

22 декабрьдә Шәриф Камал (1884-1942) вафат була.

• 65 ел элек (1952)

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Нәкый Исәнбәт пьесасы буенча «Хуҗа Насретдин» спектакле куела.

• 55 ел элек (1962)

20-26 декабрьдә Казанда казакъ сәнгате һәм әдәбияты атналыгы уздырыла.

*Журналга **Марат Закир** әзерләде.* ■

Безнен мирас №12 декабрь 2017

Декабрь 2017

Историческое наследие: «Образование ведет к истине». Р.Марданов; «Пока ты оседлаешь коня...» Л.Мухаметзянова; «Чура батыр». Р.Баязит; «Пусть наше дело станет основой...» Р.Шарафиева; «Драгоценный клад»; «Имя твоё и суть твоя». А.Сибгатуллина; «Душевное богатство». Э.Шарифуллина; «Фазыл Туйка»; «Свадебные обряды крещеных татар».

Тюркский мир: «Языковой вопрос». Г.Тирешкави.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Религиозные праздники и памятные даты 2018 года».

В глубине памяти: «Новый год на почте»; «Латака». М.Каримов.

Художественное наследие: «Принадлежит ли скрипка татарам?» Э.Каюмова.

Слово – украшение языка: «Словарь национальных терминов». А.Тимергалин; «Древние татарские обычаи». Р.Батулла.

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

December 2017

Historic heritage: «The education leads to the proper way» by R.Mardanov; «The enemy won't be waiting for your having saddled the horse...» by L.Mukhammatzyanova; «Chura batyr» by R. Bayazit; «Let this our deal become basement...» by R.Sharafieva; «The precious hoard»; «Your name and your inner world» by A.Sibgatullina; «Mental wealth» by E.Sharifullina; «Fazyl Tuyka»; «The wedding customs of baptized Tatars».

Turkic world: «Language policy» by G.Tireshkavi.

Religious heritage: «The Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov; «The religious holidays and remarkable dates of 2018».

From the deepest storage of memory: «New Year is in the post-office», «Lataka» by M.Karimov.

Artistic heritage: « Violins belong to Tatars?» by E.Kayumova.

Word is a language's decoration: «Dictionary of national terms» by A.Timergalin; «The ancient Tatar customs» by R.Batulla.

On the guard of the memory: «National library of the Republic of Tatarstan».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

Рәссам Диләрә Ленар кызы Нәүрүзова 1970 елның 27 декабрендә Казан шәһәрендә дөньяга килә.

1990 елда Н.Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесын, 2000 елда И.Федоров исемендәге Мәскәү Дәүләт полиграфия университетын тәмамлый.

2002 елдан – Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы. Рәссамның әсәрләре Россия күләмендәге күргәзмәләрдә катнаша, кайбер хезмәтләре Татарстан Дәүләт сынлы сәнгать музеенда урын алган.

Диләрә Ленар кызы нигездә китап графикасы өлкәсендә эшли. Казанда яшәп иҗат итә.

Диләрә Нәүрүзова

Р.Бохараевның «Аксак Тимер күләгәсе» поэмасына иллюстрация. Кәгазь, тушь, акварель. 2016 ел

Р.Бохараевның «Сөйли торган капчык яки түбәдәге ишәк» әкият-пьесасына иллюстрация. Кәгазь, тушь, акварель. 2016 ел

Л.Керролның «Алиса могҗизалар илендә» әкиятенә иллюстрация. Кәгазь, тушь, акварель. 2000 ел

«Нурсолтан».
Р.Шәмсетдинов рәсеме

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Нурсолтан. **Ольга Иванова**
Насретдин әүлия. **Ленар Гобәйдуллин**
Каһарман Катыйл. **Нәҗип Нәккаш тупламасыннан**
Төркиядәге татар авыллары. **Айзирәк Гәрәева**
Хәлфә бабай. **Госман Гомәр**
Локаф. **Мирсәй Әмир**
Сукыр Сибгат. **Габдулла Галиев**
Кем ул Хәмит Кави? **Равилә Мөбарәкшина**
Шагыйрь Зөлфәтнең табылдык шигыре. **Р.Зәкиева**

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»* *журналына башкача язылу:
• *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
• *редакциядә*
• *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» *журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*